# Образование


## Нижнекамского муниципального района

2016

# ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНДА МИЛЛИ МӘГАРИФ ТОРЫШЫ
# 2015-2016 НЧЫ УКУ ЕЛЫ

***Сабирова Гөлүсә Мөхәмәтхәсән кызы, Исмәгыйлева Резедә Рәиф кызы,***
*мәгариф идарәсенең укыту-методик яктан тәэмин итү бүлеге методистлары*





Туган телсез туган ил булмый, туган илсез туган тел булмый. Бер тел юкка чыкса, тулы бер мәдәният, дөнья, цивилизация юкка чыга дигән сүз. Шуңа да һәр милләт үз телен саклап калу, үстерү өчен бар көчен куя.

Телне белү һәм телне өйрәтү Түбән Кама муниципаль районы мәктәпләрендә ничек куелган соң?

Татарстан Республикасының дәүләт телләре турындагы Закон нигезендә татар теле һәм әдәбияты дәресләре муниципаль районның барлык мәктәпләрендә дә укытыла.

Муниципаль районда барлык уку йортлары татар теле һәм әдәбияты укытучылары белән тәэмин ителгән. Татар теле һәм әдәбияты белгечләре - 313. Укытучыларның 75 % ы - беренче һәм югары категорияле белгечләр.

**Татар теле һәм әдәбияты укытучылары турында мәгълүмат**

| Уку елы | Барлыгы | Югары кв. категорияле | I кв. категорияле | II кв. категорияле |
|---|---|---|---|---|
| 2013/2014 | 326 | 37(11,3%) | 162 (50%) | 51 (16%) |
| 2014/2015 | 332 | 43(13%) | 174 (52,2%) | 115 (34%) |
| 2015/2016 | 313 | 44 (14%) | 192 (61,3%) | 77 (24%) |

Түбән Кама муниципаль районында 7 татар мәктәбе эшләп килә. Рус һәм татар мәктәпләре, гимназияләрдә укучы татар милләтеннән булган 9800 укучының 3087се татар сыйныфларында белем ала, туган телдә укыту 31,3% тәшкил итә. Әйтергә кирәк, соңгы елларда татар сыйныфларын ачу өстендә максатчан эш алып барыла: балалар бакчаларының чыгарылыш төркемнәре җыелышларында татар теле укытучылары чыгышлар ясыйлар, видеодәресләр, мастер-класслар үткәрәләр. Максат бер: татар сыйныфларына укучыларны юнәлтү. Шулай да проблемалар юк түгел, татар гаиләләрендә туган телдә аралашмау, катнаш гаиләләрнең артуы төп мәсьәләләрдән санала. Шуңа да карамастан, соңгы елларда зур тырышлык белән күрсәткечне киметмәү өстендә байтак эш башкарылды. 2013 нче елдан әлеге күрсәткечнең артуын түбәндәге таблицадан күрергә мөмкин.

**1 нче татар сыйныфлары турында мәгълүмат**

| Уку елы / Сан | 2013-2014 | 2014-2015 | 2015-2016 |
|---|---|---|---|
| Татар сыйныфларының саны | 18 | 19 | 23 |
| Укучылар саны | 371 | 414 | 512 |

1999 елдан башлап,Түбән Кама шәһәрендә чуваш гимназиясе эшләп килә. 2015-2016 нчы уку елында гимназиядә 234 укучы чуаш телен туган тел буларакөйрәнә. Әлеге гимназиядә ел саен регионара, республикакүләм чаралар үткәрелеп тора.

Түбән Кама муниципаль районы мәгариф идарәсе “Яр Чаллы социаль-педагогик технологияләр һәм ресурслар” институты, Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты белән тыгыз элемтәдә тора. 2014-2015 нче уку елында республика күләмендә татар теле һәм әдәбияты укытучылары өчен - 4 семинар, 2015-2016 нчы уку елында 4 семинар үткәрелде.

**2014-2015, 2015-2016 нчы уку елларында үткәрелгән республикакүләм семинарлар**

| № | ББУ | Тема | Үткәрү вакыты |
|---|---|---|---|
| 1 | 21 нче мәктәп | “Дәүләт белем бирү стандартлары таләпләренә нигезләнеп, рус телле укучыларда коммуникатив компетенция формалаштыру юллары” | 2015 нче ел, гыйнвар |
| 2 | 8 нче мәктәп | “Татар теле һәм әдәбияты укытуда регулятив, танып-белү, коммуникатив универсаль укугамәлләре формалаштыру” | 2015 нче ел, февраль |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 3 | 9 нчы мәктәп | “ФДБСка күчү шартларында татар теле һәм әдәбияты укытуга таләпләр“ | 2015 нче ел, февраль |
| 4 | 22 нче гимназия | “9 нчы сыйныф укучыларын татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә бердәм республика тест эшенә әзерләү” | 2015 нче ел, март |
| 5 | 35 нче лицей | “Бердәм республика тестына әзерлек: таләпләр һәм яңалыклар” | 2015 нче ел, октябрь |
| 6 | 27 нче мәктәп | “ФДББС шартларында татар теле һәм әдәбияты дәресләрен укыту үзенчәлекләре” | 2015 нче ел, декабрь |
| 7 | Б.Урманче исемендәге 2 нче гимназия | “Төп гомуми белем бирүдә федераль белем бирү стандартын кертү тәҗрибәсе: проблемалар һәм киләчәк” | 2015 нче ел, декабрь |
| 8 | 32 нче гимназия | “ФДБСны тормышка ашыру кысаларында татар теле һәм әдәбияты укытучыларының һөнәри компетенциясен камилләштерүдә ресурс буларак Сингапур системасының структураларын куллану” | 2016 нчы ел, февраль |

Түбән Кама муниципаль районы мәгариф идарәсе планы буенча ай саен милли эшләр буенча директор урынбасарлары семинар-киңәшмәләре оештырыла. Яңа формада үткән киңәшмәләрдә татар теле һәм әдәбияты укытучыларының эшчәнлекләренә бәя бирелә, семинарда укытучыларның чыгышлары тыңлана, мастер-класслар тәкъдим ителә.

**2014-2015, 2015-2016 нчы уку елларында үткәрелгән милли эшләр буенча директор урынбасарлары киңәшмәләре**

| № | ББУ | Тема | Үткәрү вакыты |
|---|---|---|---|
| 1 | 3 нче мәктәп | “Татар теле һәм әдәбияты укытучыларының инновацион эшчәнлекләрен оештыру” | 2014 нче ел, ноябрь |
| 2 | 5 нче мәктәп | “Татар теле һәм әдәбияты фәннәрен өйрәнүгә теләк тудыруның нәтиҗәле чаралары” | 2014 нче ел, декабрь |
| 3 | 7 нче мәктәп | “Татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә яңа технологияләр куллану” | 2015 нче ел, март |
| 4 | 10 нчы мәктәп | “Рустелле балаларга татартеле һәм әдәбияты укытуда коммуникатив универсаль уку гамәлләрен формалаштыру” | апрель |
| 5 | 12 нче мәктәп | “Татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә шәхси, метапредмет һәм предмет нәтиҗәләрне бәяләү” | 2015 нче ел, май |
| 6 | 13 нче гимназия | “Милли мәгариф торышы” | 2015 нче ел, ноябрь |
| 7 | 33 нче мәктәп | “Милли мәгариф торышы” | 2016 нч ел, февраль |
| 8 | 16 нчы мәктәп | “Татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә сөйләм теле күнекмәләрен формалаштыруны контрольдә тоту системасын оештыру. БРТ эшләрендә кыенлыклар кичерүче укучылар белән индивидуаль эшләү алымнары” | 2016 нчы ел, апрель |
| 9 | 19 нчы мәктәп | “Татар теле, әдәбияты дәресләренең һәм дәрестән тыш чараларның шәхес тәрбияләүдәге роле” | 2016 нчы ел, май |

2013-2014 нче уку елыннан Татарстан Республикасында белем алучы барлык укучы мәҗбүри рәвештә татар теленнән Бердәм республика тестын тапшырды. Әлеге сынау укучыларда, аларның ата-аналарында татар телен өйрәнүгә җитди караш формалаштырырга ярдәм итте. Укучыларның белемнәрен тирәнәйтү, педагогларның осталыкларын үстерү максатыннан, әлеге юнәлештә дә байтак эш башкарылды. 2015-2016 нчы уку елында татар теле укытучыларының педагогик остаханәсе нәкъ менә Бердәм республика тестын уңышлы тапшыру, ягъни укучыларның белемнәрен тирәнәйтү йөзеннән оештырылды. Әлеге төркемдә югары һәм беренче квалификацион категорияле укытучылар 8 нче, 9 нчы сыйныфларда белем бирүче педагогларга методик ярдәм күрсәтте, Бердәм республика тестына әзерлек буенча төпле киңәшләр бирелде.

Татар теле һәм әдәбияты укытучыларының күпчелеге матбугат аркылы белемнәрен күтәрү өстендә актив эш алып баралар: матбугат битләрендә эш тәҗрибәләре белән уртаклашалар. Педагогларның тырышлыгын билгеләп үтү максатыннан, “Мәгариф” журналы редакциясеннән Түбән Кама муниципаль районы мәгариф идарәсенә Рәхмәт хаты ирештерелде. Эчтәлегендә күрсәтелгәнчә, шәһәребез укытучылары, башка районнар белән чагыштырганда, язылучылар арасында иң алдынгылардан санала, журнал эчтәлеген баетуда да зур активлык күрсәтә.

Бәйгеләрдә, конференцияләрдә, семинарларда катнашу укытучының үз эшенә бәя бирү өчен зур файда булып тора, тәҗрибә белән уртаклашу, профессиональ үсеш тәэмин итүдә мөһим урын ала.

Сәләтле балалар үсешен булдыру юнәлешендә укучылар өчен төрле дәрәҗәдәге олимпиадалар

оештырыла. Әлеге юнәлештә татар теле укытучыларының максатчан эшчәнлекләре укучыларның уңышлары белән билгеләнә. 2009-2010 нчы уку елында милли олимпиадаларда 5 призлы урын булса, 2015-2016 нчы уку елында 20 укучы призлы урынга лаек булды.

**Республикакүләм һәм регионара олимпиада күрсәткечләре**

| Уку елы | Призлы урыннар саны | Белем бирү учреждениесе |
|---|---|---|
| 2013/2014 | 13 | 34 нче гимназия (чуваш теле), 1нче гимназия, Каенлы мәктәбе, 2нче гимназия (гарәб теле), лицей-интернат №24 (төрек теле), 9нчы мәктәп, 27нче мәктәп, 32нче, 13нче гимназияләр |
| 2014/2015 | 15 | 34 нче гимназия, 1 нче гимназия, Каенлы мәктәбе, 5 нче мәктәп (2), 32 нче гимназия (2), 27 нче мәктәп, 29 нчы мәктәп, Кама Аланы №1 мәктәбе, 22 нче гимназия, 13 нче гимназия, 24 нче лицей (3) |
| 2015-2016 | 20 | 1 нче гимназия(3), 2 нче гимназия (2), 5 нче мәктәп (1), 35 нче лицей (5), 32 нче гимназия (3), 12 нче мәктәп (1), 13 нче гимназия (1), 33 нче мәктәп (1), Кама Аланы 2 нче мәктәбе (1), Каенлы (2) |

2015 нче елның 20 нче апрелендә Казан шәһәрендә татар теленнән III Халыкара олимпиадага йомгак ясалды. Олимпиаданың беренче туры дистанцион рәвештә үткәрелде. Барлыгы Рәсәй Федерациясенең 34 регионыннан, 12 чит илдән 11 мең 606 укучы һәм студент катнашты. Финал сынавына Түбән Кама муниципаль районыннан 21 укучы чакырылды. Бәйге нәтиҗәләре буенча районыныбыздан 3 укучы III дәрәҗәле Диплом белән бүләкләнде. Шулай уку 2014-2015 нче уку елында Татарстан тарихыннан I Республикакүләм олимпиада да 3 укучы призлы урын яулады.

**Татар теленнән III Халыкара олимпиада күрсәткечләре**

| | ББУ | Укучының фамилиясе, исеме | Призлы урын | Җитәкче |
|---|---|---|---|---|
| | 7 нче мәктәп | Мөхәммәтҗанова Алия | III | Хәмизова В.Т. |
| | Каенлы | Минеязова Айзилә | III | Гарипова Л.Р. |
| | Кама Аланы №2 | Павлова Христина | III | Әлтапова М.Җ. |

2016 нчы елның 22 нче апрелендә Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театрында татар теле һәм әдәбияты буенча IV Халыкара олимпиада җиңүчеләрен бүләкләү тантанасы булды.Әлеге чарада ТР Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Римма Ратникова, ТР Премьер-министры урынбасары - ТР мәгариф һәм фән министры Энгель Фәттахов, республика парламентының мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр буенча комитеты җитәкчесе Разил Вәлиев, Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты рәисе Ринат Закиров, КФУның филология һәм мәдәниятара коммуникацияләр институты директоры Рәдиф Җамалетдинов һ.б. рәсми затлар катнашты.

Түбән Кама муниципаль районы мәктәпләреннән йомгаклау турына 26 укучы чакырылды. Бәйге нәтиҗәләре буенча Б. Урманче исемендәге 2 нче гимназия укучылары Сабирова Ләйсән (8 нче сыйныф) һәм Хәсәншина Ләйлә (9 нчы сыйныф) призлы урыннарга лаек булдылар.

**Татар теленнән IV Халыкара олимпиада күрсәткечләре**

| | ББУ | Укучының фамилиясе, исеме | Призлы урын | Җитәкче |
|---|---|---|---|---|
| | 2 нче гимназия | Хәсәншина Ләйлә | II | Зарипова Ә.Г. |
| | 2 нче гимназия | Сабирова Ләйсән | III | Шәймөхәммәтова Ф.М. |

**Татарстан тарихыннан I Республикакүләм олимпиада нәтиҗәләре**

| Уку елы | Призлы урыннар | Белем бирү учреждениесе |
|---|---|---|
| 2014/2015 | 3 | 34 нче гимназия, 35 нче лицей, Каенлы мәктәбе |

Түбән Кама муниципаль районында милли тәрбия бирү юнәлешендә дә шактый эшләр башкарыла. Татар теленә хөрмәт, кызыксыну хисләре тәрбияләү, телне үзләштерүгә теләк булдыру өстендә шәһәребез укытучылары җитди эш алып бара. Башка милләт укучылары соңгы елларда телне өйрәнүгә аерым караш, кызыксыну белдерәләр. Шул максаттан, Түбән Кама шәһәрендә “Мин татарча сөйләшәм” акциясе берничә ел дәвамында уңышлы оештырыла. 2013-2014 нче уку елында 13 нче гимназия-интернат коллективы Республика күләмендә II урынга лаек булды, “Татар-дозор” уены нәтиҗәләре буенча I урынны яулады. 2014-2015 нче уку елында 15 нче мәктәп III урын яулау бәхетенә иреште.

Түбән Кама муниципаль районында Халыкара туган тел көненә багышланган әдәби-музыкаль кичә ел саен үткәрелеп килә. Әлеге чара шәһәребездә эшләп килүче 11 милли оешма катнашында уза. Кичә барышында тамашачылар игътибарына татар, рус, башкорт, керәшен, чуаш, әзербәйҗан, әрмән, үзбәк, таджик, немец, украин милләтләренең сәнгате, мәдәнияте тәкъдим ителә: җырлар яңгырый,

шигырьләр укыла, биюләр башкарыла. Бәйрәмдә кунак булып “Аксакаллар” шурасы әгъзалары, “Кама таңнары” әдәби берләшмәсе вәкилләре катнаша.

Әдәбият өлкәсендә яшь талантларны үстерү, аларга беренче адымнарын ясарга ярдәм итү - милли мәгарифнең бурычы. Шул максаттан, шәһәребездә 1998 нче елдан бирле Р.И. Вәлиев премиясенә яшь язучылар бәйгесе үткәрелеп килә. 18 ел эчендә каләм тибрәтүчеләр бәйгесендә 1678 укучы катнашты. 2014-2015 нче уку елында жюри әгъзалары игътибарына 52 эш кабул ителде. Катнашучылардан 13 укучының эше югары дип бәяләнде. Яшь язучылар бәйгесендә катнашкан һәрбер укучыга Р.И. Вәлиев тарафыннан бүләкләр тапшырылды, җиңүчеләр тантаналы рәвештә билгеләп үтелде. 2015-2016 нчы уку елында каләм тибрәтүчеләр бәйгесендә шулай ук 52 укучы катнашты. Шулар арасыннан 21эш иң уңышлы дип табылды.

Татар халык, классик, заман җырларын популярлаштыру, сәләтле балаларны ачыклау һәм аларның үсеше өчен шартлар тудыру, татар теленә, татар халкының композиторларына, шагыйрьләренә һәм аларның әсәрләренә карата мәхәббәт тәрбияләү максатыннан, ел саен шәһәребездә Бөтендөнья татар конгрессы ярдәме белән “Көйле, моңлы татар җыры” бәйгесе үткәрелә. Җыр бәйгесендә һәр ел меңнән артык бала катнаша. Сайлап алу турында уңай нәтиҗәләргә ирешкән хор коллективлары, ансамбльләр йомгаклау кичәсенә чакырыла, Бөтендөнья татар конгрессының Түбән Кама бүлеге рәисе Р.М. Ганиев тарафыннан тантаналы рәвештә бүләкләнә. Әйтергә кирәк, “Көйле, моңлы татар җыры” бәйгесендә катнашу белем бирү оешмалары өчен зур стимул булып тора. Җиңү бәхетенә ирешкән мәктәпләр акчалата бирелгән премия хисабына милли костюмнар тектерә. Алар, мәктәп күләмендә генә түгел, муниципаль дәрәҗәдә үткәрелә торган чараларның йөзе булып тора.

Укучылар концертларга, спектакльләргә дә бик теләп йөриләр. Яшь тамашачылар игътибарына ТР фольклор музыкасы, дәүләт ансамбле кичәләре, “Әкият” курчак театры, К. Тинчурин исемендәге татар дәүләт драма театры, Т. Миңнуллин исемендәге татар драма театры үз тамашаларын тәгъдим итәләр.

Йомгак ясап, шуны әйтәсе килә: Түбән Кама муниципаль районы мәгариф идарәсе милли мәгариф торышын үстерүгә зур җаваплык белән карый. Туган телебезнең торышы, аны саклап калу һәм үстерү, халкыбызның иң күркәм сыйфатларын кулланып, балаларга тәрбия бирүдә максатчан тырышлык күрсәтә.

## БЕРДӘМ РЕСПУБЛИКА ТЕСТЫНА ӘЗЕРЛӘНЕП...

***Габдуллина К.Т.,***
*27 нче мәктәп, татар теле һәм әдәбияты укытучысы*



Татар теле һәм әдәбиятын уңышлы укытуның торышы имтихан нәтиҗәләрендә күренә. 9 нчы сыйныфларда эксперимент рәвешендә татар теленнән имтихан 2011-2012 нче һәм 2012-2013 нче уку елларында үткәрелде. Анда татар сыйныфлары, татар һәм рус төркемнәрендә белем алучы укучылар, үзләре теләп, белемнәрен сынап карадылар. 2013-2014 нче уку елыннан Бердәм республика тестын барлык 9 нчы сыйныф укучысы да тапшыра башлады.

Мәгариф өлкәсендәге һәр яңалык укучы балалар һәм ата-аналар тарафыннан каршылыклы хисләр белән кабул ителә. Ни өчен татар теленнән имтихан тапшырырга кирәк, төп белем бирү турында аттестатка аның йогынтысы булачакмы? Татар төркемендә укучы балалар өчен сочинение язу авырлыклар тудырмасмы?


Мәктәпләрдә бу яңалык укучыларга әйтелгәннән соң, ата-аналар белән дә эшлекле сөйләшүләр алып барылды. Укытучылар алдына да зур бурыч куелды: 100 % укучыны имтиханга әзерләү җаваплылык, осталык, тәҗрибә, сабырлык таләп итә. Уку елы дәвамында предмет буенча максатчан эш алып барыла, өйрәнелгән материал җентекләп кабатлана. Шәһәр мәктәбендә укучы балаларның сөйләм теле бай түгел, шуңа күрә аларга сочинение язар өчен кыенлыклар да бар.




2015-2016 нчы уку елында, шәһәр Мәгариф идарәсе җитәкчелеге белән мәктәпләрдә Бердәм республика тестларына әзерләнү буенча күп эш башкарылды. Уку елы башында ук эш планы төзелде, БРТга әзерләнү буенча ачык дәресләр үткәрү өчен аерым мәктәпләр сайлап алынды, тәҗрибәле укытучылардан педагогик остаханә оештырылды, тест биремнәре кулланмаларын сатып алыр өчен китап кибетләре һәм "Гыйлем" нәшрияты белән турыдан-туры бәйләнеш булдырылды.

Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк: 22 нче октябрьдә татар теле һәм әдәбияты укытучылары белән БРТга әзерләнү өчен кулланмалар төзүче авторларның берсе КФУның татар теле һәм аны укыту методикасы кафедрасы доценты, филология фәннәре кандидаты Йосыпов Айрат Фаик улы эшлекле сөйләшү үткәрде. Ул тест үткәрүдә булган кайбер үзгәрешләрне әйтте, статистик мәгълүмат белән таныштырды, укучылар җибәргән типик хаталарга тукталды, укытучыларның күп санлы сорауларына җавап бирде.

Шәһәр Мәгариф идарәсе методистлары тәкъдиме белән, татар теле һәм әдәбияты укытучыларына ярдәм йөзеннән, Бердәм Республика Тестларына әзерләнү буенча педагогик остаханә оештырылды.

Аерым мәктәпләрдә шәһәр һәм авыл мәктәпләре укытучылары өчен ачык дәресләр күрсәтү планлаштырылды. Иң башта тәҗрибәле татар теле һәм әдәбияты укытучыларыннан торган иҗади төркем ачык дәреснең проектын төзү өчен чакырылды. Аннары ачык дәрескә әзерләнүче укытучыга методик яктан ярдәм күрсәтелеп, дәреснең план-конспекты төзелде. 21 нче, 1 нче, 11 нче, 31 нче мәктәпләрдә һәм 1 нче татар гимназиясендә муниципаль район мәктәпләре укытучылары өчен ачык дәресләр күрсәтелде.

Барлык дәресләр дә югары дәрәҗәдә әзерләнеп, һәр бирем уйланып төзелгән иде. 1 нче, 11 нче, 31 нче мәктәпләрдә дәресләргә максат итеп тест биремнәрен дөрес эшләү күнекмәләрен булдыру куелса, 21 нче мәктәптә сочинение язу буенча әзерлек эшләре алып барылды. Укытучы Фәүзия Шаһинур кызы әдәбият программасына кертелгән "Буранда" (Ш.Камал) хикәясеннән алынган өзек өстендә укучылар белән эшләде. Укучылар өзекнең темасын һәм проблемасын табып, Ана образын ачар өчен төрле сурәтләү чаралары кулланып, сочинение язар өчен бай материал туплады.




Ачык дәресләр караганнан соң, укытучылар өчен түгәрәк өстәл янында эшлекле сөйләшүләр дә оештырылды. Сочинение язуда әгәр укучы тексттагы репликаларны кулланып, аларны үзгәртә ала икән, димәк, ул материалның эчтәлеген аңлаган. Кереш сүзләрне дә урынлы кулланырга кирәк, дәлилләр дә дөрес булырга тиеш. Сочинение язганда җөмлә төзелешенә, тыныш билгеләре куелышына аеруча игътибарлы булырга кирәк.

10 нчы февральдә муниципаль район мәктәпләрендә БРТ сынап карау булды. Анда барлыгы 2378 укучы катнашты.



БРТ тапшыру – зур сынау, укучылардан системалы белем, осталык һәм сабырлык сорый. Икенчедән, мәктәпләрдә мәҗбүри БРТ язу татар теле фәненең абруен күтәрә, укучылар һәм укытучылар тарафыннан җитди әзерләнүне таләп итә.

Йомгаклап шуны әйтәсе килә: агымдагы уку елында БРТ күрсәткечләрен үстерү өстендә зур эш алып барылды, нәтиҗәсе барыбыз - укучылар, ата-аналар һәм укытучылар өчен дә сөенечле булыр, дип ышанасы килә.

## БЕРДӘМ РЕСПУБЛИКА ТЕСТЫНА ӘЗЕРЛӘНГӘНДӘ

***Насыйбуллина Дифинур Фәвәзис кызы,***
***Нуриева Рәмзия Фәрваз кызы,***
*8 нче гомуми урта белем бирү мәктәбенең татар теле һәм әдәбияты укытучылары*




Рус телле балалар өчен татар теле – мәктәптә өйрәнелә торган фәннәрнең берсе, димәк, укыту-белем бирүнең гомуми дидактик максатлары бу фән өчен дә үз көчендә. Рус телле балаларны татар теленә өйрәтү өчен, иң беренче чиратта, фәнне өйрәнүгә карата укучыларда уңай мотивация тудырырга кирәк. Предметка карата уңай мотивация укучы татар телен һәм әдәбиятын өйрәнүнең гамәли нәтиҗәсен күргәндә, ягъни татар телендә нәрсәдер әйтә, аңлый, башкаларга үз фикерен җиткерә, укый, укыганын аңлый алганда туа. Укытучының төп бурычы – шушы мотивацияне булдыру һәм саклау, белем бирү процессында үз фәнен шәхескә мәдәни-әхлакый тәрбия бирү, шәхси мөмкинлекләрен үстерү чарасы буларак файдалану.

Татар телен һәм әдәбиятын укытуның төп максаты – рус телле укучыны татар телендә аралашуга чыгару. Һәр дәрес тибы, дәреснең һәр этабы шушы максатны тормышка ашырырлык итеп оештырылырга тиеш. Укучы һәр дәрестән, өйрәнелгән лексик һәм грамматик берәмлекләрне кулланып, программада күрсәтелгән темалар буенча аралаша алып, диалогик һәм монологик сөйләм оештырып чыгарга тиеш.

Укыту процессының уңышлылыгына тәэсир итә торган әһәмиятле факторларның берсе – укучыларның белемен контрольгә алу. Билгеле булганча, контроль укыту процессын регулярлаштыра, ягъни, укытучы, контроль төренә карап, үз эшен оештыра. Димәк, рус телле балаларга татар теле укытуны тиешле югарылыкка куйыйк дисәк, рус телендә сөйләшүче балаларның татар теле буенча белемнәрен контрольгә алуны фәнни дәрәҗәдә оештыру зарур. Контрольнең төп объекты булып укучыларның татарча сөйләшә белү күнекмәләре тора. Төп гомуми белем бирү мәктәбен тәмамлаучыларның коммуникатив эшчәнлеген һәм тел белү дәрәҗәсен билгеләү өчен, бердәм республика тесты кулланыла. Йомгаклау-тикшерү тестларындагы биремнәр рус телендә төп гомуми белем бирү мәктәбен тәмамлаучы укучыларның татар теленнән коммуникатив күнекмәләрен объектив рәвештә бәяләргә, эшнең нәтиҗәлелеген күзалларга мөмкинлек бирә.

Тестлар хәзерге вакытта иң эффектив дидактик үлчәү берәмлекләренең берсе булып тора. Рус телле укучылар өчен БРТ 4 бүлектән тора. Татар теленнән БРТ вакытында тәңгәллек урнаштыруга караган 3 бирем, тәкъдим ителгән җавапларның берсен сайлап алу мөмкинлеге булган 8 бирем, 3 җавапның берсен сайлап алуны таләп иткән 6 бирем, кыска җавап бирүне таләп иткән 15 бирем, сөйләм ситуацияләренә караган 5 бирем һәм киңәйтелгән җавап язуны таләп иткән ачык типтагы 1 бирем

тәкъдим ителә. Барлыгы 38 бирем башкарып, укучы масималь 65 балл җыя ала. Бәяләү нормалары түбәндәгечә:

**0 – 18 балл – “2”;**
**19 – 38 балл – “3”;**
**39 – 53 балл – “4”;**
**54 – 65 балл – “5”.**

Бердәм республика тестында түбәндәге темаларга караган материал кулланыла:

1. Мәктәп тормышы. Дәресләр, түгәрәкләр, спорт секцияләре. Сыйныфташлар белән аралашу.
2. Гаилә. Туганлык мөнәсәбәтләре.
3. Көндәлек тормыш. Буш вакыт. Вакытны файдалы һәм файдасыз үткәрү.
4. Минем дусларым.
5. Кешенең тышкы кыяфәте һәм холкы. Әдәплелек кагыйдәләре.
6. Туган шәһәрем (авылым). Йорт, фатир.
7. Бәйрәмнәр. Татарстанда яшәүче халыкларның бәйрәмнәре һәм йолалары. Котлаулар.
8. Минем яраткан шөгыльләрем. Интернет. Спорт уеннары.
9. Һөнәрләр дөньясында. Миңа нинди һөнәр ошый? Һөнәр сайлау.
10. Өлкәннәр һәм кечкенәләр. Зурлар һәм кечкенәләр арасында мөнәсәбәтләр.
11. Туган як табигате. Табигать һәм кеше. Ел фасыллары. Экология проблемалары.
12. Татарстан Республикасы. Татарстанның башкаласы, халкы, истәлекле урыннары.
13. Татартсанның сәнәгате.
14. Татарстанның мәдәнияте һәм сәнгате. Татар халкының күренекле шәхесләре.
15. Илләр һәм шәһәрләр. Сәяхәт итү. Җәйге, кышкы яллар.

**Беренче бүлек** биремнәре укучыларның **тыңлап аңлау күнекмәләрен бәяләү** өчен тәкъдим ителә. Биремнәрне аудиоязмада тел белгече укый. **Беренче биремдә** укучы 4 кыска диалог тыңлый һәм диалогта сөйләнгән вакыйганың кайда барганын билгели. Һәр диалогта вакыйга урынына ишарәли торган сүзләр бар. Мәсәлән, “билет, партер, урын, рәт” сүзләре вакыйганың театрда барганлыгын күрсәтә. Ризык исемнәрен ишеткәч, укучы кафе яки ашханә җавабын сайлый. Биремнәрне дөрес эшләп, укучы 4 балл җыя. **Икенче биремдә** укучыларга биш монологик текст тәкъдим ителә. Бу бирем укучыларның гомуми эчтәлекне аңлавын, татар сәнәгате, әдәбияты, мәдәнияте турында мәгълүматлы булуын, гомуми эрудициясен тикшерә. Биремне дөрс эшләп, укучы 5 балл җыя ала. **3-8 нче биремнәрне** үтәү өчен, укучылар бер озын диалог (180-200 сүз) тыңларга тиеш булалар. Диалог көндәлек сөйләшү, аралашу гыйбәрәләреннән тора. Укучылар, ишетелгән тексттан чыгып, бирелгән 3 җавап арасыннан дөресен табарга тиеш. Шулай итеп, аудирование биремнәре буенча укучы 15 балл җыя.

**Икенче бүлектәге** биремнәр укылган текстка нигезләнеп башкарыла. **9-16 нчы биремнәрне** үтәү өчен, текстны игътибар белән укып чыгарга һәм эчтәлеген аңларга кирәк. Текстны укып чыккач, укучы бирелгән раслауларның текст эчтәлегенә туры килү-килмәвен билгели. Тексттагы җөмлә раслауда сөйләмдә еш кулланыла торган синонимнар, охшаш грамматик формалар ярдәмендә үзгәртелеп бирелә. Мәсәлән, текстта: “Беркөнне ул урманда гөмбә җыеп йөргән”, - дигән җөмлә бар, ә раслауда: “Керпе урманда җиләк җыйган” – дип бирелә. Димәк, бу раслау текст эчтәлегенә туры килми. **17 нче биремдә** 7 өлешкә бүленгән бәйләнешле тексттагы һәр микротеманың эчтәлеген аңлау һәм аларның дөрес исемен дөрес билгеләү сорала. Сайлап алу өчен 8 исем тәкъдим ителә, димәк, аларның берсе артык. Икенче бүлектә укучы барлыгы 15 балл җыя ала.

**Өченче бүлектәге** биремнәр укучыларның татар грамматикасын һәм лексикасын ни дәрәҗәдә белүен бәяләргә мөмкинлек бирә. Җавап вариантлары тәкъдим ителми. **18-25 нче биремнәрдә** укучы бирелгән сүзләрне тиешле грамматик формага куярга тиеш. Биремне дөрес башкару өчен, килеш, зат, сан кушымчаларын, фигыльнең заман, зат-сан кушымчаларын, сыйфатларның дәрәҗә кушымчаларын, сан төркемчәләре турында кагыйдәләрне белү сорала. Бирелгән сүзне дөрес формада кую янәшәдә торган сүзләргә дә бәйле. Кайбер кагыйдәләрне карап китик.

1. **Бирелгән сүз - исем**.

- Җөмләнең хәбәреннән чыгып, бу исемгә сорау куябыз. Сорау буенча килешен билгелибез, кирәкле кушымчаны ялгыйбыз (*Алар бергә УРАМ+ДА (кайда?) уйнадылар*).
- Әгәр җөмләдә исемнәр тиңдәш кисәкләр булып килә икән, бер исем икенчесенә кушымчаны дөрес куярга ярдәм итә (*Һәркемнең туган йорт**ы**, туган ГАИЛӘ+СЕ була*).
- “Исем+ исем” сүзтезмәсендә беренче исемне дөрес формада куярга кирәк булса, аны иялек килешендә (-ның/ нең) куярга кирәк, ә икенче исемдә 3 нче зат тартым кушымчасы (-ы/е, -сы/се) булырга тиеш (*Карда ҖӘНЛЕК+ЛӘР+НЕҢ эзләрен укып була*).

- Әгәр исем җөмләнең иясе яки хәбәре булса, бу исемгә зат кушымчасы яки күплек сан кушымчасы ялгана, моны хәбәр буенча ачыклап була (*ӘНИ+ЛӘР – иң кадерле кешеләр*).
- Исем бәйлекләр алдыннан кулланылган. Бу бәйлекнең кайсы килешне таләп итүен искә төшерергә кирәк *(ДӘРЕС+ТӘН соң музыка мәктәбенә йөрим*).

2. **Бирелгән сүз – фигыль.** Ул инфинитив формасында куелган**.** Фигыль белән эшләү өчен, аның нигезен дөрес билгеләргә кирәк.

- Фигыль җөмлә ахырында, димәк, ул – хәбәр. Бу фигыльне үткән яки хәзерге заманда куярга кирәк. Тексттагы янәшә җөмләдәге фигыльләрнең заманы нинди булса, бу фигыль дә шул заманда кулланыла (*Ял көнендә мин чаңгы алам һәм урманга АШЫГ+А+М .).*
- Фигыль башка фигыльалдынннанкулланылган. Бирелгән фигыль хәл фигыль формасында була (*Менә көз дә КИЛ+ЕП җитте*).
- **Башлый, ала, белә** фигыльләре алдыннан фигыльне хәзерге заманда кулланырга кирәк (*Күп тырышсаң гына, балет артисты БУЛ+А аласың*).
- Фигыль исем алдыннан килсә, аны сыйфат фигыль формасына куябыз (Республикабыз мәктәпләрендә күпме ТАНЫЛ+ГАН шәхесләр укыган!)

*3.* **Бирелгән сүз – сыйфат яки рәвеш**. Татар телендә сыйфат - төрләнми торган сүз төркеме, аңа бары тик чагыштыру дәрәҗәсе кушымчасы гына ялгана (*Ул тагын да МАТУР+РАК булып күренде).*

*4.* **Бирелгән сүз – сан.** Сан күп очракта тәртип саны була**(***БЕР+ЕНЧЕбулып килде)***.** Сан **"артык"** сүзе беләнкулланылса, чыгыш килеш кушымчасын (*ЙӨЗ+ДӘН артык – более ста)***, "якын"** сүзе кулланылса, юнәлеш килеш кушымчасын *(УТЫЗ+ГА якын – около тридцати*) ялгарга кирәк. Вакытны белдерергә кирәк булганда, "*сәгать УН+ДА"* төзелмәсе кулланыла.

*5.* **Алмашлыкларга** килеш кушымчалары ялгана**. Шунда, монда, анда** формаларын истә тотарга кирәк.

**26-32 нче биремнәр** сүз тамырыннан яңа сүз ясап, аны тиешле грамматик формада куллануны сорый, шуңа күрә бу сүзләргә берничә кушымча ялгарга кирәк булуы мөмкин.

Биремнәрне дөрес башкару өчен, иң актив сүз ясагыч кушымчаларны яттан белергә кирәк. Шулай ук җөмлә төзелешеннән нинди сүз төркеме ясарга кирәк икәнен дә ачыкларга кирәк. **Исем алдыннан** күп очракта **сыйфат** кулланыла, бу очракта күбрәк –лы/ле кушымчаларын ялгыйбыз ( *Койрыклары сары, озын САП+ЛЫ кашыкка охшаган*). Вакытка карый торган сыйфатлар –гы/ге, -кы/ке кушымчалары ярдәмендә ясала (*ЯЗ+ГЫ көннәр күңелне сөендерә).*Сүз җөмлә ахырында булса, бу – җөмләнең хәбәре, ул фигыль була (*Алар бик тиз ДУС+ЛАШ+ТЫ+ЛАР*), әгәр ия белән хәбәр арасында сызык куелса – исем ( *Укытучы бит ул – ТӘРБИЯ+ЧЕ дә). 26-32 нче биремнәрне башкарганда.* Тиңдәш кисәкләргә дә игътибар итәргә кирәк, алар кирәкле кушымчаларны куярга ярдәм итәләр. Өченче бүлектәге биремнәр 15 балл җыярга мөмкинлек бирә.

**4 нче бүлектәге биремнәр** ирекле формада языла торган җаваплардан гыйбәрәт**.** Аларны 2 нче номерлы бланкларда язарга кирәк. **33-37 нче биремнәр** бирелгән сөйләм ситуациясен хәл итүне сорый. Һәр реплика эндәш сүздән башлана. Татар телендә башка кешегә исеме белән генә эндәшмиләр, туганлыкны, үзара мөнәсәбәтләрне белдерүче сүзләр дә кулланырга мөмкин. (Әтием, әнием, абый,апа, дустым, энем, укытучы апа һ.б.). Чит кешегә мөрәҗәгать иткәндә, "Гафу итегез", "әйтегез әле" төзелмәләрен кулланырга кирәк. Язма сөйләмне дөрес төзүдә җөмләне башта русча язу бик яхшы булыша.

**Үрнәк**: Поинтересуйтесь у нового друга, на кого из родителей он похож. Андрей, на кого из родителй ты похож? *– **Андрей, син кемгә охшагансың: әтиеңәме, әниеңәме***?

Дөрес язылган һәр җөмләгә, 1-2 тупас булмаган хәреф хатасы булса да, 2 балл куела. 5 репликага – 10 балл.

**38 нче бирем - шәхси хат язу**. Хатның структурасын дөрес оештыру бик мөһим. Хатны исәнләшү белән башларга, хат өчен рәхмәт әйтергә кирәк. Бу хатның башлану өлешен тәшкил итә. Төп өлештә өч сорауга да дөрес җавап бирергә кирәк. Җавап биргәндә, сорауларны игътибар белән уку, үзгәртергә кирәк кушымчаларны билгеләп кую бик отышлы. Килгән хаттан бирелгән өзектән дә мәгълүмат алып була.Сорауларга җавап биргәч, йомгаклау өлешенә күчәбез. Бу өлештә дустыңның хәлен белергә, үзең дә аңа сораулар бирергә мөмкин. Хат ахырында хатны кем язуын, язу датасын күрсәтергә кирәк.Хатның структурасы дөрес булмаса, хатка балл куелмый. Шулай ук укучы хатта үз исемен, адресын күрсәтсә, хат тикшерелми. Хат 80 сүздән торырга тиеш. Хат адресатына татар исеме белән эндәшергә онытмагыз. Татарча да, русча да җиңел языла торган исем сайлау отышлы. Дөрес язылган хат өчен укучы 10 балл ала.

**Хат үрнәге.**

*... Сыйныфташым Илдар авырып китте. Үзенә генә күңелсез булмасын өчен, аның янына көн дә барып йөрдем. Бергә дәресләрне әзерләдек, телевизор карадык. Хәзер без – иң якын дуслар.*

***... Ә синең якын дустың кем исемле? Сез бер-беребезгә ничек ярдәм итәсез? Бергәләп кайларга йөрисез?***

**Җавап хаты.**

*Исәнме, дустым Алсу! Сиңа сәлам белән дустың Артем хат яза. Әти-әниеңә, дусларыңа, Сашага миннән сәлам әйт.*

*Алсу, мин синең хатыңны алдым, бик зур рәхмәт. Хатың бик кызыклы, мин аны рәхәтләнеп укыдым.*

*Алсу, син "Ә синең якын дустың кем исемле? – дип сорыйсың. Минем дусларым бик күп. Ә иң якын дустым ... исемле. Без ... белән бер мәктәптә укыйбыз. Ул – бик матур, акыллы, тәрбияле кыз (егет). Без бер-беребезгә һәрвакыт ярдәм итәбез.* Бергәләп *мәктәпкә, киного, түгәрәккә йөрибез, телевизор карыйбыз, музыка тыңлыйбыз. Минемчә, ... – чын дус.*

*Алсу, синең хәлләрең ничек? Авырмыйсыңмы? Әти-әниең исән-саумы? Нинди яңалыкларың бар? Ничек укыйсың? Имтиханнарга ничек әзерләнәсең? Шулар турында хат яз, көтәм.*

*Сәлам белән, дустың Артем. 16 нчы март, 2016 нчы ел (**112 сүз)***

Әлбәттә, бердәм республика тестына әзерлекне башлангыч сыйныфларда ук башларга мөмкин. Аудирование күнегүләрен дәрес саен тыңлау, текст белән танышкач, бирелгән раслауларның текст эчтәлегенә туры килү-килмәвен билгеләүне 3-4 нче сыйныфларда ук кулланып була. Шулай ук, БРТга әзерләнү йөзеннән, рус телле укучыларының белемнәрен контрольгә алуны БРТ калыпларына салынган биремнәр аша тикшерү дә әзерлекнең бер төре булып тора. Бу биремнәрне укытучы үзе төзи ала.

## 7 нче сыйныф

### Яхшы уку кагыйдәләре.

**Прочитайте предложения и определите, какие выражения соответсвуют теме (1 - текстка туры килә), какие- не соответствуют (2- текстка туры килми).**

1. 1 нче сентябрь – күңелле көн, җырлы көн.
   **1) текстка туры килә 2) текстка туры килми.**
2. 1 нче сентябрьдә сумка бик җиңел, чөнки анда дәреслекләр юк.
   1) **текстка туры килә 2) текстка туры килми**.
3. Яхшы уку өчен, көндәлеккә өй эшләрен язарга кирәкми.
   **1) текстка туры килә 2) текстка туры килми.**
4. Галимов Илнарның көндәлеге бик яхшы, анда өй эшләре, расписание язылган.
   **1) текстка туры килә 2) текстка туры килми.**
5. Безнең көндәлекләребезне сыйныф җитәкчесе атна саен тикшерә.
   **1) текстка туры килә 2) текстка туры килми.**

**Төшеп калган сүзләрне дөрес формада куеп яз.**

| | | |
|---|---|---|
| 6 | _____ сентябрь – Белем бәйрәме. | **бер** |
| 7 | Без кичә _______ контроль эш эшләдек. | **математика** |
| 8 | Син мәсьәләне дөрес _______? | **чишәргә** |
| 9 | Көндәлек – документ, көндәлек – укучының ______. | **күзге** |
| 10 | Әни, Оля бүген безгә ______ әле. | **килергә** |
| 11 | Мин бишле алдым, чөнки диктантны ______ яздым. | **хата** |
| 12 | Самат китапны _______ тотмаган. | **сакларга** |

**Репликаларны яз.**

13. Дай совет другу не бросать учебники куда попало.
14. Спроси у друга, какие оценки есть у него в дневнике.
15. Сообщи маме, что ты по математике получил "5", потому что примеры решил без ошибок.
16. Скажи другу, что тебе надо приготовить уроки, поэтому ты не выйдешь на улицу.
17. Посоветуй однокласснику внимательно слушать учителя на уроке.

Текст белән эшне дә БРТ формасында оештырырга мөмкин.

## 8 нче сыйныф.

**"Җиңәсем килде" текстын (43-44 нче бит)укыгыз һәм биремнәрне эшләгез.**

**I. Дөрес җавапны билгелә.**

1. Беседкада .... шахмат уйныйлар. **1) абыйлар 2) карт кешеләр 3) һәвәскәрләр**
2. Илгизнең ... шахматлары бар. **1) хрусталь 2) агач 3) кечкенә**
3. Илгиз таныш түгел ... уйнарга чакырды. **1) апаны 2) малайны 3) абыйны**
4. Абый бик ... уйный иде. **1) яхшы 2) төгәл 3) начар**
5. Илгиз, абыйның бер ... алып, учына яшерде**. 1) атын 2) фигурасын 3) ладьясын**

**6.** Абый кулы белән шахматны эзләде, ләкин **... 1) тапмады 2) карамады 3) күрмәде**

**II. Определите, какие из приведённых утверждений 7-14 соответствуют содержанию текста (1 – текстка туры килә), какие не соответствуют (2 – текстка туры килми).**

7. Бакчада шахматчылар шахмат уйный. **1 – текстка туры килә 2 – текстка туры килми**
8. Илгиз кайбер уйнаучыларны белә**. 1 – текстка туры килә 2 – текстка туры килми**
9. Абыйның күзләре күрми иде. **1 – текстка туры килә 2 – текстка туры килми**
10. Абый бик яхшы уйный, әйтерсең, аның күзләре күрә**. 1 – текстка туры килә 2 – текстка туры килми**
11. Илгизнең бу абыйны җиңәсе килде. **1 – текстка туры килә 2 – текстка туры килми**
12. Ул тиз генә абыйның уртада торган бер фигурасын алды һәм кесәсенә яшерде. **1 – текстка туры килә 2 – текстка туры килми**
13. Абый башка фигура белән йөрде һәм малайга мат куйды**. 1 – текстка туры килә 2 – текстка туры килми**
14. Шахматчылар янына Илгизнең дусты Андрей килеп басты**. 1 – текстка туры килә 2 – текстка туры килми**

**III. Преобразуйте слова, написанные заглавными буквами в конце строк, обозначенных номерами 15 – 22 так, чтобы они грамматически соответствовали содержанию текста. Заполните пропуски полученными словами.**

| | | |
|---|---|---|
| 5 | Беседкалар янында һәвәскәр ________ шахмат уйныйлар | **шахматчы** |
| 6 | Алар янында кулына шахмат тактасы _____ бер абый басып тора. | **тотарга** |
| 7 | Бүген ________ хрусталь шахматлар бүләк иттеләр | **Илгиз** |
| 8. | Илгизнең шахмат уенында ______ килде. | **җиңәргә** |
| 9 | Ул тактада торган бер _____алып, учына яшерде. | **ладья** |
| 10 | Сукыр абый _____ фигурасын алды. | **ике** |
| 11 | Алар _____ Зөлфия килеп басты. | **яны** |
| 12 | Илгиз кып-кызыл булды,________ бик оят иде. | **ул** |

**В заданиях 23-27 необходимо написать реплики в соответсвии с заданной речевой задачей.**

23. Предложи своему другу поиграть в шахматы.
24. Попроси папу купить тебе новую шахматную доску.
25. Сделай комплимент однокласснице, что она очень мило улыбается.
26. Спроси у друга, знает ли он правила шахматной игры.
27. Сообщи папе, что ты занял первое место в соревнованиях по шахмату.

**28. Сез татар дустыгыздан хат алдыгыз. Сорауларга җавап биреп, дустыгызга хат языгыз. Язма эшегез 80 сүздән торырга тиеш.**

| |
|---|
| **... Безнең мәктәптә бүген шахмат ярышы булды. Без дустым Андрей белән ярышта катнаштык. Андрей беренче урынны алды. Мин аның өчен бик шатландым. Ул чынлап та бик яхшы шахматчы.** ... Син нинди уеннар уйнарга яратасың? Кемнәр белән уйныйсың? Нинди ярышларда катнашканың бар? |

## “ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДА УКЫТУ СЫЙФАТЫН КАМИЛЛӘШТЕРҮ” ПРОЕКТЫН ТОРМЫШКА АШЫРУДА 32 НЧЕ ГИМНАЗИЯ УКЫТУЧЫЛАРЫ ЭШЧӘНЛЕГЕ

*32 нче гимназиянең татар теле һәм әдәбияты укытучылары төркеме*



МГББУ “32 нче гимназия” инде берничә ел ТРның Мәгариф һәм фән министрлыгы һәм «Эдьюкэа интернэшнл консалтэнси кооперэйтив лимитед» сингапур компаниесе белән берлектә “ТРда укыту сыйфатын камилләштерү” дигән проект өстендә эш алып бара.

Проект республикада укытуны яхшырту юнәлешендә бөтен, озакка сузылган һәм ныклы булышлыкка юнәлдерелгән. Укыту укучыларның Хезмәттәшлек, Коммуникация, Критик һәм Креатив фикер йөртү күнекмәләрен үстерү өчен укытучыларның инновацион методикаларны үзләштерүгә корылган. Сингапур мәктәпләрендә кулланылучы кооператив укыту методы командаларда эшләү формасына нигезләнгән. Аның максаты – укучылар өчен психологик уңай мөхит булдыру, коллективны берләштерү.

Гимназиянең педагогик коллективы тарафыннан укучылар һәм ата-аналар белән берлектә сингапур укыту моделенең мәктәпнең Миссиясе, Видениесе һәм Кыйммәтләре кебек элементлары эшләнелде һәм кулланылышка кертелде.



*Гимназиянең миссиясе*

Йөрәккә кагылырга, акылны җәлеп итәргә, дөньяны үзгәртергә.

*Гимназиянең күрүчәнлеге*

Һәр укытучы – кайгыртучан укытучы!

Һәр укучы – эшкә җәлеп ителгән укучы!

Һәр ата-ана – ярдәм итүче дус!

*Гимназиянең кыйммәтләре*

«Кайгыртучанлык, хөрмәт, сүзендә нык торучанлык, хезмәттәшлек, намуслылык, креативлык». Гимназиянең барлык методик, уку, тәрбияви чаралары педагогик һәм укучылар коллективы тормышына алда әйтеп кителгән кыйммәти ориентирларны кертүгә юнәлдерелгән.

Гимназиянең барлык укытучылары "Фикерләү культурасын үстерү" дип аталган беркөнлек тренингта укуларда булдылар. Әлеге укулар барышында алар катлаулырак дәрәҗәдәге яңа укыту структураларын һәм фикерләү алымнарын кулланырга өйрәнделәр. Каникуллар вакытында өстәмә укыту структуралары һәм фикерләү алымнары укытучылар тарафыннан җентекләп, аларны дәреснең конкрет этапларында куллану үрнәкләре белән төркемнәрдә практикага юнәлдерелгән тренинглар үттеләр. Уку елы дәвамында мәктәпнең эчке контроле методик коучингын үткәрү кысаларында гимназия администрациясе тарафыннан укытучыларның әлеге методиканы куллануларын тикшерү һәм аларга методик ярдәм күрсәтү максаты белән дәресләргә йөрелде. Шушы ук максат белән гимназиядә ТРда проект җитәкчесе Лилия Мөхәммәтшина белән очрашу оештырылды. Ул үзе караган дәресләргә югары бәя бирде.

Шулай ук 2014 нче елның гыйнварыннан безнең гимназия югарыда әйтелгән бердәм проектның "ТРда Өстенлекле мәктәпләр" дип аталган тагын бер юнәлешен тормышка ашыру өстендә эшли. Программаның асылы шунда: республиканың һәрбер муниципаль районында инновацион мәктәп укытучылары челтәре командасы формалаштыру, алдынгы укыту практикасын кертү һәм укыту сыйфатын үстерү, республика районнары һәм мәктәпләре арасында хезмәттәшлек атмосферасын булдыру һәм тәҗрибә белән уртаклашу максаты белән бер мәктәп билгеләнгән.



Гимназия Өстенлекле мәктәп программасының 5 юнәлешенең бер тармагы буенча эшли – ул Баетылган программа (ЕС). Баетылган программа гамәлдәге мәктәп программасын халыкара танылган программаларның алдынгы тәҗрибәләре ярдәмендә киңәйтүгә юнәлдерелгән. (Diploma Programme дәрәҗәсендәге элементларларның IB - Халыкара бакалавриат программалары).

Проектны тормышка ашырудан көтелгән нәтиҗәләр:

1. Укыту стандартларына җавап бирүче һәм шәхси-юнәлдерелгән укытуны тәэмин итүче Diploma Programme дәрәҗәсендәге элементларларның IB - Халыкара бакалавриат программаларын тормышка ашыру.

2. Укучыларның уку сыйфаты, йомгаклау аттестациясе нәтиҗәләре яхшыру.

3. Укучыларның шәхси потенциалын ачу өчен максималь уңай шартлар булдыру, аларның үзүсеше һәм үзлектән белем алу дәрәҗәләрен арттыру.



4. "Киңәйтелгән эссе", "Танып белү теориясе", "Иҗат, хәрәкәт, хезмәт" программаларын тормышка ашыру аша укучыларның һәм укытучыларның продуктив эзләнү һәм проект эшчәнлегененең формаларын үстерү.

Методик ярдәм күрсәтү максатыннан, Эдьюкэа компаниесе тренерлары тарафыннан "Киңәйтелгән эссе" һәм "Танып белү теориясе" юнәлешләре буенча гимназиядә беркөнлек укыту тренингы, Яр Чаллы шәһәренең 77 нче гимназиясе базасында өчкөнлек республикакүләм семинар-тренинг һәм шулай ук методик һәм контроль

коучингларүткәрелде. Укытучылар уку процессына уңышлы рәвештә Танып белү теориясе юнәлешен тормышка ашыру һәм укучыларны Киңәйтелгән эссе язарга өйрәтү буенча махсус элементлар кертә башладылар.

2014 – 2015 нче уку елында 10 нчы сыйныф укучылары беренче тапкыр үзләре сайлаган төрле фәннәр буенча шундый эшләр язып карадылар, шул ук вакытта эссе темалары төрле, уку программасына туры килмәгән, ә укучыларның күзаллауларын киңәйтә торган иде. 10 нчы сыйныф укытучылары тафыннан нәтиҗәдә барлык укучылар май аенда укытучылар һәм сыйныфташларының сорауларына җавап биргән ачык укуларда катнашырлык итеп әзерлек эше алып барылды.

<u>*PLC - профессиональукыту берләшмәләре*</u>

Профессиональ укыту берләшмәләре эше – гимназиянең методик эшендә яңа форма булып тора. PLC әгъзалары гомуми максатка ирешү өчен үзара бәйләнештә эшләгән хезмәттәшлек итүче командалардан тора.



PLCга хас:

1) 3 мөһим идея:

- укучыларны укытуны тәэмин итү,
- хезмәттәшлек культурасын төзү,
- нәтиҗәләрне бер ноктага туплау;

2) 4 критик сорау:

- без укучыларны нәрсәгә өйрәтергә телибез? (мөһим, гарантияләнгән, укыту эчтәлегенең максатчанлыгы),
- аларның укуларына ничек ышанырга? (администрация тарафыннан тикшерелүче хезмәтт әшлектә команда оештырган формалаштыручы бәяләү),
- әгәр алар укыйлар икән, без ничек кабул итәрбез? (заманча, юнәлдерелгән, системалы якын килү),
- әгәр алар инде беләләр икән, без ничек җавап бирербез? (заманча баету һәм киңәйтү);

3) 6 характерлы үзенчәлеге:

- мәктәпнең күрүчәнлеге, миссиясе, кыйммәтләре һәм максатлары,
- хәрәкәткә һәм экспериментлыкка ориентлашканлык,
- укуның һәм белемгә омтылуның көчле культурасы,
- бердәм һәм булышлыклы лидерлык,
- ышаныч һәм бирелгәнлеккә нигезләнгән киңәшмә,
- булышлык күрсәтүче шартлар.

Уку елы дәвамында һәрбер методик берләшмә кысаларында PLC формасында эш үткәрелә. Бу чара нәтиҗәсендә укучыларның төрле фәннәр һәм темалар буенча уку нәтиҗәләре яхшырды.

## Ә.З. РӘХИМОВНЫҢ ИҖАДИ ҮСЕШ ТЕХНОЛОГИЯСЕ (ИҮТ) ЗАМАН БЕЛӘН БЕРГӘ АТЛЫЙ

***Р.Ә. Шәйхетдинова*** - *Түбән Кама шәһәренең "Аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнүле 31 нче гомуми урта белем бирү мәктәбе"нең югары категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы, укытучы-технолог;*

***Л.Х. Садыйкова*** - *Түбән Кама шәһәренең "Аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнүле 31 нче гомуми урта белем бирү мәктәбе" директорының урынбасары, югары категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы*




Федераль Дәүләт белем стандартларында (ФДБС) белем бирү системасының төп үсеш юнәлеше **системалы-эшчәнлекле юнәлеш** дип билгеләнде. Үзләштерү процессының **эшчәнлекле характерда** булуы турында тәгълимат Д.Б. Эльконин, В.В. Давыдовлар тарафыннан үткән гасырның 30 нчы елларында бәян ителсә дә, киң куллалынышка керә алмады. П.Я. Гальпериннең фикерләү гамәлләрен этаплап үстерү теориясенә таянып, иҗади үсеш технологиясен Ә.З. Рәхимов эшли.

Укыту ысулларының нәтиҗәлелеге турында кытайның үтемле әйтеме бар: "Ишетәм-онытам; күрәм-аңлыйм;эшлим-истә калдырам". Яңа стандартларның иң мөһим таләбе-белемнәрне үзләштерү процессын укучыларның үз эшчәнлекләре нигезендә оештыру, ягъни «укучы үз алдына максат куярга һәм аны тормышка ашыру юлларын үзе таба алу дәрәҗәсенә күтәрелергә тиеш». Бу – яңа стандартта

**эшлекле белем** дип атала. **Эшлекле белем – стандарт керткән яңалыкның әһәмиятле эчтәлеген ачып бирүче иң гомуми төшенчә**.

Иҗади үсеш технологиясе укытучыга дәрестә балаларның уку эшчәнлеген оештыру өчен зур мөмкинлекләр бирә. Уку эшчәнлегендә рефлексив фикер йөртү механизмның беренче адымы булып төшенчә кертелә. Төшенчә – белемнең бер формасы. Төшенчәне укучы эшчәнлегенә кертү өчен иң мөһиме – мәсьәләне (төшенчәне) өлешләргә бүлү, максатын, шарталарын билгеләү

ИҮТ үзенең максатлары, эчтәлеге, уку-укыту методлары, формалары, уку-укыту процессында катнашучыларның үзара мөнәсәбәтләре буенча шактый үзенчәлекле . Укучы, уку эшчәнлегенә өйрәнер өчен укуның сыйфат ягыннан мөһим 3 этабын үтә.

Түбән Кама шәһәренең “Аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнүле 31 нче гомуми урта белем бирү мәктәбе” 2010 нчы елдан элеге технологиягә йөз белән борылып, үз дәресләрендә актив куллана башлады, ә инде 2011нче елның 14 декабрендә “Укыту эшчәнлеген формалаштыру аша укучыларның иҗади фикерләү сәләтләрен үстерү” темасына иҗади үсеш технологиясе авторы Ә.З. Рәхимов һәм В.С.Казыйхановлар катнашында ике көнлек регионара семинар-практикум үткәрде. Хөрмәтле укытучылар, сезнең игътибарга шул семинарда күрсәтелгән, барлык этаплары сакланып төзелгән дәрес эшкәртмәләре тәкъдим итәбез, алар үрнәгендә сез үз дәресләрегезне планлаштыра аласыз. Уңышлар сезгә!

## ТЕМА: ТУКАЙ ШИГЫРЕНӘ ИЛЛЮСТРАЦИЯ

*2 нче сыйныф, татар төркеме, Шәйхетдинова Рәфидә Әслах кызы, 31 нче мәктәпнең югары квалификацион категорияле татар теле һәм укыту методикасы буенча укытучы-технолог*



**Максатлар:**

**Белем бирү (предмет нәтиҗәсе):**“Бишек”, “Гаилә - бишек” төшенчәләрен аңлау;

**Үстерү максаты (метапредмет нәтиҗә):** иҗади фикер йөртергә өйрәнү;

**Тәрбия бирү максаты (шәхескә юнәлдерелгән нәтиҗә):** халкыбызның гореф-гадәтләренә, традицияләренә аңлы мөнәсәбәт тәрбияләү.

**Технология:** Ә.З. Рәхимовның иҗади үсеш технологиясе.

**Метод, алымнар**: проблемалы ситуация, төркемнәрдә эш, иҗади эш, эзләнү, модельләштерү, рефлексия.

**Дәрес тибы:**Уку мәсьәләсен кую һәм чишү.

**Материал:**

1) Ягъфәрова Р.Х. Уку китабы: Дүртьеллык башлангыч рус мәкт. 2 нче сыйныф дәреслеге-Казан: Мәгариф,2009-143 б.

2) Шәймәрданов Р.Х., Сибгатуллин Р.Г. Татар милли педагогикасы.- Казан: “Матбугат йорты”нәшрияты,2004,374 б.

3) Татар теленең аңлатмалы сүзлеге, 3 томда

**Җиһазлау:** Т.Хаҗиәхмәтов “Бишек җыры”- иллюстрация

Г.Тукайның “Бишек җыры” шигыре,халык көе аудиоязмасы (CD форматта), мәкаль-әйтемнәр, гаилә моделе.

**Дәрес барышы**

**I. Ориентлаштыру-мотивлаштыру этабы**

*Тема буенча йомгаклау дәресе булганлыктан үтелгән материал системага салына, белемнәр тигезләнә. Тактага гаилә моделе элenә.*

**1. Өй эшен тикшерү** (модель буенча)

- Бу сүзләрне бер сүз белән атап буламы? -

**ГАИЛӘ**

Бабай Әби Әти Әни Балалар - Димәк, гаилә темасы буенча белемнәрне тикшерәбез

**Блиц-турнир:**

- Бабай сүзен шигырьдә Нурдидә нинди сүз белән алыштыра? (*“Дәү әти”)*

- Бу юллар кайсы хикәядән?.. “Бу юлы бигрәк матур итеп киенеп килгән ул. Аякларында – атлаган саен шыгыр – шыгыр итеп торган йомшак читекләр”(“*Дәү әни”Р.Вәлиева*)

-“..Тал чыбыктан шомартып,
Бергә кәрзин үрәбез”- юллары кайсы шигырьдән алынган?(*“Әтием белән бергә”)*
“Әни” сүзен таптарга ярамый икәнлеген кайсы автордан белдек?
(*З.Туфайлова*)
- Әти, әни сүзләрен иркәләп, кечрәйтеп әйтеп карыйк (*Төркемнәрдә*)
- Әти-әнинең үзеңнеке икәнен сүз белән күрсәт (*Әтием,әнием*)

**Үзбәя.**

**2. Белемнәрне тигезләү**. Гаилә темасына караган мәкаль–әйтемнәрне уен аша кабатлау.

Уен барышы: Балалар төркемнәрдә эшлиләр. Алып баручының кулында төйнәлгән кулъяулык “Мин - мәкаль әйтүче, ди ул, мәкальнең беренче яртысы - минем телемдә, икенче яртысы-шушы төендә. Мин сезгә мәкальнең яртысын әйтермен, сез икенче яртысын миңа әйтерсез. Әйтә алган кеше мәкаль төенен чишкән була”.

**Мәкальләр:**

- Иркә бала *(ир булмас)*
- Ата –анасын хурлаган *(үзен хурлаган)*
- Ата-анасын тыңлаган адәм булган *(тыңламаган әрәм булган)*
- Атасы малаена алма бакчасы үстереп биргән (*малае атасына сыңар алма да бирмәгән)*

**3.Уку мәсьәләсен кую**. Төркемнәргә әйтемнәр өләшенә.

**Әйтемнәр:**

**“Гаилә – бишек”**

**“Туган ягым – яшел бишек”**

Әйтемнәрдә кабатланган сүзне табыгыз?
*(Көтелгән җавап):* Бишек
Димәк, без бүген нәрсә турында сөйләшербез?
Бишек турында.

**Үзбәя**

**II. Уку мәсьәләсен чишү этабы**

**1 нче бирем:**

Бишек төшенчәсе өстендә эш *(укытучы ярдәме белән бишек төшенчәсе тудырыла; яңа яисә аңлашылмаган сүзне без сүзлектән эзләнә)*

Татар теленең аңлатмалы сүзлегендә бишек сүзенә түбәндәгечә аңлатма бирелә:

**Бишек – баланы тирбәтеп йоклату урыны.**

- Укучылар, кечкенә балаларны бүген кайда йоклаталар? (балалар арбасында, караватта)
- Ә бишекләр юкмы? алар кайда?
- Бүген сезнең алда чын бишек бар. Ул – музей экспонаты. Хәзер бишекне якыннан карыйк *(укучылар бишек сиртмәсен һәм бишекне игьтибар белән күзәтә.)*

Тирбәтергә җайлы булсын өчен, бишек сиртмәгә – озын сыгылмалы колгага эленә. Бишек өстенә тукыма ябыла. Тукыма балага яктылык төшмәсен һәм җил тимәсен өчен кирәк.

- Укучылар, шулай итеп, бишек җыры тыңларга әзер.

**2 нче бирем:**

**Аудио язмадан “Бишек” *(*** *Г.Тукай сүзләре, халык көе)* җыры тыңлана.

- Җыр ничек тәэсир итте?
- Җырны кем башкара?(*әни)*
- Бишек җыры ана белән бала арасында башкарыла
- Бишек җыры тынычландыра. Музыканың бу сыйфатын әби, әниләр яхшы белгән һәм баланы юатканда йоклатканда җырлаганнар.
- Без тыңлаган җырның сүзләрен Г. Тукай язган. Көе – халыкныкы. Ә рәссам Т. Хаҗиәхмәтов “Бишек җыры” шигыренә рәсем- иллюстрация ясаган.

**3 нче бирем:**

Т. Хаҗиәхмәтов Г. Тукайның “Бишек җыры” шигыренә иллюстрация.

**а) Дәреслек буенча эш.** Рәсемне күзәтегез. Бишек турында төркемнәрдә бер–берегезгә сөйләгез

**б) -** Рәсемдә кемне күрәсез?
- Әнинең йөзе нинди?
- Колагында, муенында нинди бизәнү әйберләре бар?
- Яулыгы, алъяпкычы,күлмәге ничек бизәлгән?
- Әни кеше баланы ничек үстерә?
- Рәсемгә карап, сез нәрсәләр турында уйланасыз? *(бишектә йоклау балага җайлы, рәхәт)*

- Рәсем буенча белгәннәрегезне үз – үзегезгә сөйләп чыгыгыз.

**III. Рефлексив бәяләү**.

**1.** -Нәрсә белми идек?

- Нәрсә белдек?
- Ничек белдек?

**2. Гомуми үзбәя.**

**3.** - Т. Хаҗиәхмәтов рәсеменә карап үз рәсемеңне ясап кара.

- Бишек җырларын өйрән.

**Әдәбият:**

1) *Ягъфәрова Р.Х. Уку китабы: Дүртьеллык башлангыч рус мәкт. 2 нче сыйныф дәреслеге- Казан:Мәгариф,2009-143 б.*

*2) Шәймәрданов Р.Х., Сибгатуллин Р.Г. Татар милли педагогикасы.- Казан: "Матбугат йорты" нәшрияты, 2004, 374 б.*

*3) Татар теленең аңлатмалы сүзлеге, 3 томда*

## ИСЕМ СҮЗ ТӨРКЕМЕН КАБАТЛАУ

***Баянова Алсу Мулланур кызы,***

*31 нче мәктәпнең I квалификацион категорияле башлангыч сыйныф укытучысы*

**Дәреснең максаты**:

**Белем бирү максаты (предмет нәтиҗәсе):** Исем сүз төркеме буенча белемнәрне тигезләү;

**Үстерү максаты (метапредмет нәтиҗәсе):** Укучыларның логик-фикерләү сәләтләрен үстерү;

**Тәрбия бирү (шәхескә юнәлдерелгән нәтиҗә):** Туган як төшенчәсенә дөрес мөнәсәбәт тәрбияләү.



**Җиһазлау**: эш дәфтәрләре, татар телендәге килешләр таблицасы, билгеләр салынган тартма, һәр укучыда үзбәя өчен таблица, исем турында сораулар һәм таблицалар язылган слайдлар;

**Материаллар**: А.Х. Нуриеваның 3нче сыйныф укучылары өчен татар теле дәреслеге, Ә.З. Рәхимовның "Белем бирү сыйфаты" һәм "Башлангыч сыйныфларда укыту технологиясе" китаплары, В. Казыйхановның "Әхлак дәресләре" китабы.

**Дәрес барышы**:

**I. Ориентлаштыру-мотивлаштыру этабы.**

**1. *Психологик уңай халәт тудыру.***

Исәнләшеп, кәефләрен сорап дәресне башлап җибәрү. (Укучылар чылбыр рәвешендә әдәпле, матур сүзләрне кабатлыйлар, мәсәлән: хәерле көн, ашларыгыз тәмле булсын, хәерле юл этием, рәхмәт әнием, тыныч йокы апам, гафу итегез кирәргә ярыймы, һ.б.).

**2. *Өй эшен тикшерү***. (Ярым иҗади, бу өлешкә 15 минутлап вакыт сарыф ителә).

Өй эше 2 вариантта бирелгән була:

1 вариантка башы бирелгән хикәянең азагын укучылар үзләре теләгәнчә дәвам итәргә тиешләр.

Хикәя: Минә дәресләр дә бетте. Мин бүген татар теле дәресендә "5"ле алдым. Шуңа микән күңелем шат. Сумкамны болгый-болгый, яшь колындай сикерә-сикерә, подъезд ишеге төбенә кайтып җиттем. Ачкычымны алып ишекне ачыйм дигәндә, күрәм, подъезд ишеге төбендә бик матур йөзек ялтырап ята...

2 вариантка юнәлеш, төшем, чыгыш килешендәге исемнәр кергән 2 шәр җөмлә язарга кирәк иде.

Искәрмә: 2 варианттагы өй эше татар телен авыр үзләштерүче укучылар өчен бирелде.

(Өй эше һәрбер төркемнән 1 шәр яки 2 шәр укучыдан вариантлап сорала).

Өй эшенә нәтиҗә ясалып укучылар үзбәя һәм бер-берсенә бәя куялар. (Мәсәлән: укучылар, Адиләнең хикәясен тыңладык, әйдәгез әле бәя куябыз. Бәя куйганда хикәянең эчтәлегенә, тәрбияви моментына да игътибар итәргә онытмагыз).

**Үзбәя**

**3. *Белемнәрне тигезләү***.

Төркемнәргә сораулар бирелә:

1) Нәрсә ул исем? (исем предметны белдерә, кем? нәрсә? сорауларына җавап бирә)
2) Исем нәрсәләргә бүленә? (ялгызлык һәм уртаклык исемнәр була)

3) Исемнәр нинди саннарда килә? Сораулары һәм кушымчалары нинди?( исемнәр берлек һәм күплек саннарда килә, кемнәр? нәрсәләр? дигән сораулар куела, -лар, -ләр, -нар, -нәр кушымчалары ялгана)

4) Татар телендә ничә килеш бар? Аларның исемнәрен атагыз. (Татар телендә 6 килеш бар: баш килеш, иялек килеше, юнәлеш килеше, төшем килеше, чыгыш килеше, урын-вакыт килеше)

**Үзбәя.**

**<u>Яулык уены</u>**. Сүзләрне килешләр белән төрләндерү. Яулык төенен бер-берсенә биреп урман, авыл, шәһәр сүзләрен килешләр белән төрләндерәләр.

Шушы уеннан соң әкрен генә сүз Түбән Кама шәһәре турында сөйләшүгә күчә. Укучылар Түбән Кама турында җөмләләр төзиләр. Мәсәлән: Минем шәһәрем Түбән Кама. Безнең шәһәребез яшь, матур, яшел. Шәһәрдә кибетләр, мәктәпләр, кинотеатрлар күп. һ.б.

Яулык уены дәвам ителә. Мәкальнең башы минем телемдә, ә азагы шушы төендә. Мәкальнең башын бер укучы әйтә, ә азагын икенче укучы дәвам итә. Шул рәвешле 6-7 мәкаль әйтелә. Мәсәлән:

- Илен белмәгән - (игелексез).
- Үз илем - (алтын бишек).
- Туган җирдәй җир булмас, (туган илдәй ил булмас).
- Иле ныкның - (биле нык).
- Оясыз сандугач (сайрамый).
- Ир егет үзе өчен туар, (иле өчен үләр).

Мәкальләрнең нәрсә турында баруы турында сөйләшү. (Туган ил, туган җир турында барды). Безнең мәктәбебез нинди мәктәп әле? (Яшь коткаручылар, илне сакларлык кешеләр тәрбияли торган мәктәп. Без дә мәктәпне бетергәндә туган илебезне сакларлык, якларлык егетләр булып чыгарбыз).

**Нәтиҗә.**

**Үзбәя.**

**<u>Уку мәсьәләсен адымлап чишү.</u>**

***<u>1. Модель төзү.</u>***

Укытучы ярдәме белән төзелә.

**<u>Сүз төркемнәре</u>**

**Исем** **Сыйфат** **Фигыль**

| **Исем** | | | | |
|---|---|---|---|---|
| Кешеләрне, предметларны, хайван, кош исемнәре, җиләк-җимеш, яшелчә исемнәре, үсемлек исемнәре, табигать күренеше исемнәре, тойгы-хис атамалары, вакытны белдерәләр. | Кем? нәрсә? сорауларына җавап бирәләр. | Уртаклык һәм ялгызлык исемнәр була. | Берлек һәм күплек санда киләләр. | 6 килеш белән төрләнәләр.<br>Баш килеш<br>Иялек килеше<br>Юнәлеш килеше<br>Төшем килеше<br>Чыгыш килеше<br>Урын-вакыт килеше |

***<u>2. Дәреслек белән эшләү.</u>***

Укучылар дәреслектәге 182 нче күнегүне игътибар белән укып язмача дәфтәргә мөстәкыйль эшлиләр. Биремдә ноктапар урынына төшеп калган сүзләрне куярга кирәк. Күнегүне язмача эшләп бетергәч телдән тикшерәләр һәм үзбәя куялар.

**Нәтиҗә.**

**Үзбәя.**

**<u>III. Рефлексив бәяләү.</u>**

3. Дәрестә эшләнгән эшкә йомгак ясау.

**Үзбәя.**

**Өй эше.** Исем темасы буенча контроль эшкә әзерләнергә.

# КЫШКЫ УЕННАР ЛГКК

***Бәдгыева Эльза Данияз кызы,***
*31 нче мәктәпнең югары квалификацион категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы*



**Максатлар:**

**Белем бирү максаты (предмет нәтиҗәсе)**

- “Кышкы уеннар” темасына караган лексиканы сөйләмдә куллану;

- яңа лексика: *кар атышлы;*

- “Кышкы һава торышы” темасына караган лексиканы искә төшерү һәм сөйләмдә куллануны камилләштерү;

- инфинитив+яратам төзелмәсен, тартым кушымчаларын, сингармонизм законычалыгын гамәлдә куллану;

- фигыльләрне зат-сан белән төрләндерү;

- җөмләдә сүзләр тәртибен кабатлау.

**Үстерү максаты (метапредмет нәтиҗәсе):**

- мөстәкыйль һәм төркемнәрдә эшли белү, үз-үзләренә бәя куя белү күнекмәләрен,ярдәмлекләр белән эшли белүләрен үстерү.

**Тәрбия бирү (шәхескә юнәлдерелгән нәтиҗә):**

- кышкы уеннар вакытында да үз сәламәтлегеңне ныгыту, тәнеңне чыныктыру күнекмәләре булдыру;

- татар теленә уңай мөнәсәбәт тәрбияләү.

**Материаллар:** Татар теле һәм уку китабы: Рус телендә белем бирүче дүртъеллык башл.мәкт. 3 нче с-фы өчен дәреслек (рус телендә сөйләшүче балалар өчен)/ Р.З.Хәйдәрова. – Казан: Мәгариф, 2009.- 159 б., 1-3 нче сыйныф сүзлек дәфтәрләре, грамматик темалар, модельләр тупланган дәфтәрләр, темага караган сюжетлы рәсем, үзбәя өчен махсус кәгазь битләре.

**Җиһазлау:** ике телефон аппараты, “Кар атышлы уен”ы өчен ак кәгазь битләре һәм кар бөртекләре ярдәмендә бизәлгән чиләк, “Кульяулык” уены өчен чигүле акъяулык, ноутбук, мультимедио проекты һәм экран.

**Дәрес тибы:** Уку мәсьәләсен чишү.

**Дәрес барышы:**

**1. Ориентлашу - мотивлаштыру этабы. (ОМЭ) 10 мин.**

Слайдта тәкъдим ителгән афоризмны татар теле дәресе белән бәйләү.

Знание бывает двух видов. Мы сами знаем предмет – или же знаем, где найти о нем сведения. *Бенджамен Франклин*

Көтелгән җавап: *Если мы что-то не знаем, мы можем воспользоваться словарем, учебником, тетрадью со схемами.*

1. **Өй эшен тикшерү.**

а) Темага караган лексиканы белүләрен тикшерү. Аудирование.

- Артык сүз табыгыз: *Кыш, ап-ак, кар, ява, яшел, салкын, суык, җил, буран.*

Үзбәя. Укучылар билге кую критерийлары белән таныш. Дәрес барышында һәр биремне үтәгәннән соң үзбәяне түбәндәге таблицага кертеп баралар.

ә) Иҗади өй эше тикшерелә. Әзерләнеп килгән укучылар диктор булып һава торышы турында сөйләп күрсәтә. Сөйләм үрнәге: *Мин сезгә һава торышын сөйлим. Казанда 20 градус салкын. Түбән Камада кар ява. Салкын җил исә.*

| | |
|---|---|
| число: | *14.12* |
| укучы | *П.Саша* |
| сыйныф: | *3 А* |
| бирем | билге |
| *№ 1* | *4* |
| *№ 2* | *5* |
| *№ 3* | *4* |
| | |
| | |
| нәтиҗә | *4* |

**Үзбәя.**

2. **Белемнәрне тигезләү. Төркемнәрдә эш.**

Яңа темага күчәр алдыннан үткән дәрес темасы буенча бердәм старт позициясенә басу.

Һава торышы турында телефоннан сөйләшү.

Диалог үрнәге:

- *Сәлам!*
- *Урамда салкынмы?*
- *Әйе, урамда 20 градус салкын.*
- *Кар явамы?*
- *Юк, кар яумый.*
- *Җил исәме?*

- *Җил исә.*
**Үзбәя.**
- *Мин "бишле" куйдым, чөнки үзем җавап бирдем (үзем сөйләдем, хатам юк).*
- *Мин "дүртле" куйдым, чөнки китапка карадым (хата бар).*
- *Мин "өчле" куйдым, чөнки миңа ярдәм кирәк.*

**3.Уку максатын кую.**
- Почему мы любим хорошую зимнюю погоду?- *Мы любим играть.*
- Догадайтесь, чем мы будем заниматься на уроке?
- Давайте вместе поставим перед собой учебную задачу:
Вспомним зимние развлечения и поговорим о них по-татарски.




**II. Белемнәрне адымлап үзләштерү этабы. (БҮЭ) 30 мин.**

1. Уку максатына ирешү өчен укучылар белән берлектә яңа теманы өйрәнү алгоритмын төзү. Слайдта эш планы баскычлар формасында сурәтләнә.
- Вспомним слова, обозначающие зимние развлечения.
- Вспомним необходимые грамматические формы (окончания) для составления предложений.
- Вспомним порядок слов в предложении.
- Поговорим по теме.



2. Уку максатына ирешү өчен күнегүләр системасы.

**Бирем 1**. "Рәссамның хаталарын тап" уены аша темага караган лексиканы туплау. Сюжетлы рәсем буенча *чана, чаңгы, тимераяк* сүзләрен искә төшерү. Темага караган лексиканы сүзлекләр ярдәмендә төркемнәрдә 10га тутырып язу. Һәрбер төркем бүлеп бирелгән сүзләрне сүзлектән табып тәрҗемә итә.

ФИЗМИНУТ. "Кар атышлы уены". Һәрбер бала ак кәгазьне йомарлап, темага караган берәр сүз дөрес әйтә алган очракта гына, укытучы тарафыннан әзерләп куелган чиләккә ташлый.

Нәтиҗә.
Үзбәя

**Бирем 2**. Яраткан кышкы уен турында әйтү өчен *инфинитив+ яратам* тезмәсен кабатлау. (Дәреслектә 20нче бит) Инфинитивның төзү юлларын модельләр дәфтәреннән табып искә төшерү.
- Скажите по-татарски:
Люблю кататься (*шуарга яратам)*
Люблю кататься на санках (*чана шурга яратам*)индивидуаль
Люблю кататься на лыжах (*чаңгы шурга яратам*) һәм
Люблю кататься на коньках (*тимераяк шурга яратам)*парларда
Люблю играть (*уйнарга яратам)*әйттерү
Люблю играть в хоккей (*хоккей уйнарга яратам)*
Люблю играть в снежки *(кар атышлы уйнарга яратам)*
**Үзбәя.**

**III. Рефлексия. 5 мин.**

1. Бирелгән схема буенча төркемнәрдә сөйләшү, һәрбер пункт бунча берәр баланың фикерен әйттерү.

Әйдә пышылдашыйк әле:
- Мин ... кабатладым.
- Мин ... өйрәндем.
- Миңа ... ошады.
- Миңа ... авыр булды.
- Миңа ... кабатларга кирәк.

2. **Дәрескә үзбәя.**
3. **Өй эше.** Өч дәрәҗәдә тәкъдим ителә, укучыларга сайлап алу мөмкинлеге бирелә.
1) Уку стандарты буенча эш:"Кышкы уеннар" темасына караган лексиканы белергә;

2) Программа материалын иҗади куллануга эш (ярымиҗади эш): басма дәфтәрләрдә 28 нче бит, 4 нче күнегү;

3) Иҗади эш: яраткан уеннар турында әйтә белергә.

## ЯХШЫ ДУС - ҖАНЛЫ ХӘЗИНӘ
## (ӘХЛАК ДӘРЕСЕ)

***Габдуллина Гүзәлия Мөбәрәкҗан кызы,***
*31 нче мәктәпнең I квалификацион категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы*



Максатлар:

**Дидактик:**

- Дуслык төшенчәсе өстендә эш.

**Психологик:**

- Төркемнәрдә эшли белүләрен; үз-үзәренә бәя куя белү күнекмәләрен;

ярдәмлекләр белән эшли алуларын үстерү.

**Тәрбияви:**

- кешеләр арасында үзара мөнәсәбәтләрдә дуслыкның иң мөһим сыйфатларның берсе булуына ышаныч тәрбияләү.

**Материаллар:**

1. Казыйханов В.С. Әхлак дәресләре- Чаллы, 2004 ел.
2. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге.- 3 томда. 2007 ел
3. “Чын дустым” җырының фонограммасы. (Гөлсәрвәр сүзләре, В.Усманов музыкасы)

1. Интерактив такта.
2. Әсәрләрдән өзекләр, мәкальләр




**Дәрес барышы:**

**1. Өйгә бирелгән эшне тикшерү.**

- Әти–әниләрегез белән сөйләшкәннән соң нинди фикергә килдегез?

- Сер саклау җиңелме?

**Үз-үзеңә бәя кую.**

**2. Уку мәсьәләсен кую.**

*(Сакля сүзенең мәгънәсен интерактив тактада аңлату)*

Бик биек тауда бер көтүче яшәгән. Бервакыт яңгырлы бер төндә өч кеше аның ишеген шакыган.

-Минем сакля (Кавказда тау халыкларының өе) берегез генә керегез. Сез кемнәр соң? –дип сораган көтүче.

Без - Дуслык, Бәхет һәм Байлык. Иң башлап кайсыбыз керүен үзең хәл ит, дигәннәр алар.




*Төркемнәрдә тикшерү өчен сораулар:*

Көтүче кемне сайлар икән?

**-Дуслыкны.**

-Ни өчен?

-Чөнки **Дуслык** керү белән өйгә Бәхет тә, Байлык та киләчәк.

-Димәк, бүгенге дәрестә без нәрсә турында сүз алып барачакбыз?

**-Дуслык турында.**

**Үзбәя.**

**3. Уку мәсьәләсен чишү.**

Төркемнәрдә тикшерегез:

**1 нче бирем:**

- Нәрсә ул дуслык? Тулы аңлатма бирегез әле.

*(Аңлатмалы сүлекләр белән эшләнелә. Көтелгән җаваплар тыңланыла)*




Дуслык – 1. Ихтыяҗларның, карашларның, фикерләрнең уртаклыгына үзара рухи якынлык, бер – береңне ихтирам итү һәм башка хисләргә нигезләнгән мөнәсәбәт. *Халыклар дуслыгы- Татарстанның иң зур байлыгы.*

2. Берәр нәрсә белән мавыгу, аны ярату хисе.- *Китап белән дуслык урнаштырдым әле.*
*(Көтелгән җаваплар.)*




- Чын сүзен сез ничек аңлыйсыз?
- Нәкъ үзе булган; тиешле теләкләргә җавап бирә торган; эчкерсез, ихлас бирелгән.*Чын дус йөз елдан соң да дус булыр.*

Дуслык сүзенең тамырын табыйк әле.

Дус – кем? соравына җавап бирә. – лык кушымчасы кушылып, нәрсә? соравына җавап биргән сүзгә әйләнә.

Шулай итеп, дуслык дуслар арасында була торган әйбер икән.

Дуслыкны без тотып карый алабызмы?

*Нәтиҗә чыгарыла*. Димәк, Дуслык ул - (анализ-синтез)

**2 <u>нче бирем.</u>**




- Дус, дуслык, чын дус сүзләре белән бәйләнешле нинди мәкальләр,

әйтемнәр беләсез?

(*Төркемнәр үз фикерләрен туплый)*

*Интерактив тактада каплап куелган мәкальләр ачыла.*

- Мин дә сезгә мәкальләр әзерләп килдем.
- Йөз сум акчаң булганчы – йөз дустың булсын.
- Дус көйдереп әйтер, дошман көлдереп әйтер.
- Юләр дустың булудан акыллы дошман артык.




- Дусны ашыкмыйча гына сайла, тапкач – тиз генә алыштырма.
- Дусларыңны рәнҗетсәң, дошманнарың куаныр.
- Игелек эшләүче дуслар бүләк таләп итмиләр.

**Үзбәя.**

**3 <u>нче бирем.</u>**

- Ә менә борынгы кытайлар: “Акыллы кешеләр акыллылар белән дус була”-дигәннәр. Моны ничек аңлыйсыз? (Төркемнәрдә эш. Җаваплар)
- Ни өчен акыллы кеше ахмаклар белән дуслаша алмый?

(Төркемнәрдә эш. Җаваплар)

“Кем арбасына утырсаң, шуның җырын җырларсың”, “Бүреләр белән яшәсәң, бүреләрчә улыйсың ” мәкальләрен ничек аңлыйсыз?

(Төркемнәрдә эш. Җаваплар)

**Үзбәя.**

**4 нче бирем.**

1. Үзегез укыган китаплардан, караган кинофильмнардан нинди
геройларның чын дуслыгын үрнәк итеп ала аласыз? (Көтелгән җаваплар).
2. “Дуслык нигезе - тигезлектә” дигән мәкальне ничек аңлыйсыз? (Көтелгән җаваплар).
3. Дуслык турында нинди җырлар беләсез?
(Көтелгән җаваплар).

***Укытучының үзе башкаруында “Чын дустым ”җыры.***

Кыен чакларымны
Хәбәр итмәсәм дә, үзе белеп килә чын дустым.
Ихластан сөенә, хәлләрем яхшыга
Үз итә ул мине чын дустым.




<u>Кушымта:</u>
Киңәше акыллы иң якын дустымның
Рәхмәт сиңа, рәхмәт, чын дустым.
Яхшымы яманмы, барын да аңлыйсың,
Ярый әле бар син, чын дустым.
Җиңеп кайгыларны, бергәләшеп кенә
Аралашып яшик һаман да.
Тарсынмыйм дөньяны,ниләр кичерсәм дә,
Якын дустым янда булганда.
<u>Кушымта</u>
Мин бәхетсез димим, бу дөньяның әле

Гүзәллеген күрә алганга.
Мин ялгыз да димим, гел шатланып яшим,
Ышанычлы дуслар янымда.
Кушымта.
*Сорау:* Җыр нәрсә турында булды?
**Үзбәя.**
**5 нче бирем.**
4. Дуслыкның нинди төрләрен беләсез? Аларны схемада күрсәтегез.
*Интерактив тактада чыгып язалар.*
Кызлар дуслыгы, малайлар дуслыгы, әти-әни һәм бала арасындагы дуслык, туганнар дуслыгы, дәүләтләр арасындагы дуслык, төрле милләт кешеләре арасындагы дуслык һ.б.
5. Әйтегез әле, чын дуслык булу өчен ни кирәк? (Көтелгән җаваплар).
**Үзбәя.**
6. Ялган дуслык дигән сүзне ничек аңлыйсыз?
7. Икейөзлелек, алдашу, юхалану.
8. Ялган дуслык озак яшиме?
9. Бер фаш ителергә тиеш.
10. Исәп- хисапка корылган дуслыкны ничек аңлыйсыз?
11. Бер якның ышанычын казанып, үзеңә шәхси файда алу.
- Болардан чыгып, нинди нәтиҗә ясап була?
**4. Рефлексия.**
Нәтиҗә чыгарыла.
**Димәк, Дуслык ул –**
Дуслык –
1. Ихтыяҗларның, карашларның,фикерләрнең уртаклыгына үзара рухи якынлык, бер- береңне ихтирам итү һ.б.хисләргә нигезләнгән мөнәсәбәт. *Халыклар дуслыгы - Татарстанның иң зур байлыгы.*
2. Берәр нәрсә белән мавыгу, аны ярату хисе. *Китап белән дуслык урнаштырдым әле.*
**Үзбәя**.
**Рефлексия.**
- Бүгенге дәрестә нәрсә турында сүз барды?
- Үзегезгә нәрсәләр алдыгыз?
**Дәрес өчен үз-үзенә бәя кую.**
**4. Өй эше.** Вариантлап тәкъдим ителә, укучыларга сайлап алу мөмкинлеге бирелә.
1В- “Безнең гаиләнең чын дуслары” дигән темага өйдә әңгәмә үткәрегез.
2В- Чын дуслыкның төшенчәсен үзегез уйлап карагыз әле.
3В- Рәсемнәр ясагыз.

## ФИГЫЛЬ
## 3 нче сыйныф

***Гимадиева Лилия Илсур кызы,***
*31 нче мәктәпнең беренче квалификацион категорияле башлангыч сыйныф укытучысы*



***Максатлар:***
**1.Белем бирү максаты** (дәреснең предмет нәтиҗәсе): фигыль төшенчәсе өстендә эш. 2 нче сыйныфта фигыль турында алган белемнәрне ныгыту.
**2.Үстерү масаты (дәреснең метапредмет нәтиҗәсе):** укучыларның иҗади фикерләү сәләтен, игътибарлылыгын үстерү.
**3.Тәрбияви максат (дәреснең шәхси нәтиҗәсе):** туган як табигатенең матурлыгын тоя һәм саклый белү теләге, үзеңдә матурлык тудырырга теләү омтылышы тәрбияләү.
***Материал:*** дәреслек “Татар теле” 3 сыйныф. А.Х. Нуриева, Ч.М.Харисова; интерактив такта, карточкалар
***Дәрес тибы:*** уку мәсьәләсен кую һәм чишү.
***Методлар:*** модельләштерү, анализ-синтез, иҗади эшчәнлек, рефлексия.

**Дәрес барышы.**

**I. Оештыру – мотивлаштыру этабы. (1 слайд)**
- Хәерле көн, укучылар!

- Кәефләрнең яхшы булуын теләп, дәресне башлыйбыз.

**1.Белемнәрне тигезләү.**

***а) Матур язу* (2 слайд)**

***Укучылар, табышмакны тыңлагыз.**

***Кырлар буш кала,***
***Яңгырлар ява;***
***Җирләр дымлана,-***
***Бу кайчак була?( Көз көне)- төркемнәрдә киңәшләшеп алыгыз.***

- Баш һәм юл Кк хәрефен язабыз. **(3 слайд)**

К   Кк   Ккк   Кккк – дәвам итегез

***б) Исем сүз төркемен кабатлау:***

*****Көз, көзнең, көзгә, көзне, көздән, көздә.

- Бу сүзләр турында нәрсә әйтә аласыз?
- Бу исемнәр,чөнки, килеш белән төрләнгәннәр.

*Бутап бирелгән килешләрне тиз генә тәртипкә сал.

көз**дә** (нәрсәдә?), көз**_** (нәрсә?), көз**нең** (нәрсәнең?), көз**дә** (нәрсәдә?), көзд**ән** (нәрсәдән?), көз**гә** (көзгә?), көз**не** (нәрсәне?), **(4 слайд), (5 слайд)**

(Һәр төркемнән 1 укучы такта янында кушымчаларны билгели һәм сорауларын әйтә)

***2. Өй эшен тикшерү.***

- Сезгә иҗади эш бирелгән иде. Үзегезне шагыйрь ролендә хис итеп карадыгыз.
- Тикшерәбез.

*I –III төркем:   **(6 слайд)**

Сары яфрак ...(коела),
Көннәр кышка ... (авыша).
Кошлар оя ... (калдырып),
Җылы якка ... (ашыга).

**Сүзлек сүзләр: ашыга, авыша, коела, калдырып.*

*II–Iѵтөркем:

Агачлар яфрак ... (коя),
Бакчалар бушап ... (кала).
Сулар боз булып ... (ката),
Кырлар йокыга ... (тала).

**Сүзлек сүзләр: тала, кала, ката, коя.*

- Тикшерәбез. **(7 слайд)**
- Бу эш җиңел булдымы? Әллә кыенмы? (җаваплар)
- Төшеп калган сүзләр нинди сүз төркеменә карый?
- Фигыль.

**3. Уку мәсьәләсен кую:**

- Димәк, бүгенге максатыбыз нинди?
- Бүген дәрестә без фигыль турында сөйләшәбез.

**II. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

- Нәрсә ул фигыль? **(8 слайд)**

***Бирем 1.***

***Фигыль***

| ↙ | ↓ | ↘ |
|---|---|---|
| ***Эш*** | | |
| ***Хәрәкәтне*** | ***нишли?*** | --------------- |
| ***Хәлне*** | ***нишләде?*** | --------------- |
| | ***нишләгән?*** | |
| | ***нишләр?*** | |
| | ***нишләячәк?*** | |

**** Фигыль - эш-хәрәкәтне һәм хәлне белдерә, нишли? нишләде? нишләгән? нишләр? нишләячәк? сорауларына җавап бирә: яза, язды, язган, язар, язачак.***

***Фигыль җөмләдә хәбәр булып килә.***

(Бер-береңә сөйләү, капма-каршы сөйләү, үзеңә сөйләү) **(9 слайд)**

**ҮЗБӘЯ**

**Физкультминут (10 слайд)**

**“Яфраклар җыры” н** җырлау һәм элементлары белән бию.

***Бирем 2: Дәреслек белән эш.***

* 2 нче күнегү. Р.Миңнуллин шигыреннән өзек.

(биремне укучылар укый, эш мөстәкыйль үтәлә)

*Булышам, юышам, ала, кыйный. (1 бала тактада яза) **(11 слайд)**

-Ни өчен шулай уйлыйсыз?

**Нәтиҗә2:** кагыйдәне искә төшерү.

-Бу сүзләр кайсы сүз төркеменә карый?

**ҮЗБӘЯ**

***Бирем 3: Төркемнәрдә иҗади эш.*** **Һәр төркем 1 фигыль соравын әйтә, нәрсә белдерүен кабатлыйлар (12 слайд)**

-Бирелгән сүзләргә фигыльләр өстәргә.

Җил (исә, сызгыра, уйлый, тешли) – 1төркем

Яфраклар (коела, сибелә, саргая, чәчелә, оча) – 2 төркем

Кошлар (сайрый, оча, бала чыгара, җырлый) – 3 төркем

Үләннәр (саргая, кибә, чери, шиңә) – 4 төркем

Агачлар (үсә, яфрак яра, саргая, яфрак коя) – 5 төркем

**Нәтиҗә 3:** Бу сүзләр нинди сорауларга җавап бирә? **(13 слайд)**

**ҮЗБӘЯ**

**III. Рефлексив анализ (14 слайд)** ***1. Уку мәсьәләсе нәрсә иде?Ничек чиштек?***

**1.Модель буенча сөйләгез (15 слайд)**

***Фигыль***

| | | |
|---|---|---|
| ***Эш*** | | |
| ***Хәрәкәт*** | ***нишли?*** | --------------- |
| ***Хәл*** | ***нишләде?*** | --------------- |
| | ***нишләгән?*** | |
| | ***нишләр?*** | |
| | ***нишләячәк?*** | |

**2. Дәрескә үзбәя.**

**3. Өй эше (16 слайд)**

1) 5 нче биттәге кагыйдәне кабатларга.

2) 3 нче күнегү, 5 нче бит

3) фигыльләр кулланып, кроссворд төзеп килергә.

## НӘБИ ДӘҮЛИ “КАЛЕНДАРЬНЫҢ СОҢГЫ БИТЕ”
**2 нче сыйныф**

***Минһаҗева Резеда Галәветдин кызы,***

*31 нче мәктәпнең I квалификацион категоряле башлангыч сыйныф укытучысы*

**Максатлар:**



**Белем бирү максаты (предмет нәтиҗәсе):** Н.Дәүли әсәре белән танышу, ел төшенчәсе өстендә эшләү;

**Үстерү максаты (метапредмет нәтиҗә):**Текст белән эшләү күнекмәләрен үстерү, нәтиҗә ясарга, фикернеәйтергә өйрәнү, үз белемнәрен тикшерү һәм бәяләү күнекмәләрен үстерү;

**Тәрбия максаты (шәхескә юнәлдерелгән нәтиҗә):** Әйләнә-тирәгә үз мөнәсәбәтеңне булдыру.

**Дәреснең тибы :** Уку мәсьәләсен кую һәм чишү.

**Метод, алымнар:** иҗади эш, эзләнү, модельләштерү.

**Материал:** Календарь төрләре, ел фасыллары, ай исемнәре язылган карточкалар, Н.Дәүлинең портреты, календарь сүзенең төшенчәсенә аңлатма язылган плакат, сюжетлы рәсемнәр.

**Дәреснең барышы:**

**I. Ориентлашу-мотивлаштыру этабы.**

**1. Бүгенге көн турында сөйләшү.**

**2. Өй эшен тикшерү.**

**“Блиц-турнир”**

- Шигырьнең авторы кем?
- Шигырьдә сүз нәрсә турында бара? (Кар яуган)
- Нинди образлар аша автор кар явуны шигырьдә күрсәтә алган? (Сөт, он образлары аша.)
- Ә ни өчен бу образларны алган дип уйлыйсыз? (Чөнки сөт тә, он да ак төстә-алар карга охшаган.)
- Ак карны тагын нинди образлар аша чагыштырып була? (мамык, ак шәл, ак юрган, ак җәймә, ак ашъяулык белән чагыштырып була).
- Балалар кыш килгәнгә ни өчен шатланалар? (алар чана, чаңгы шуачаклар, тау ясарлар, кар бабай тәгәрәтеп уйнарлар).

**Нәтиҗә .**

**Үзбәя.**

-Хәзер җавапларыгызга бәя куегыз.

**II. Уку мәсьәләсен кую**.

**1. Табышмак өстендә эш.**

- Игътибар! Мин сезгә табышмак әйтәм. Төркемнәрдә җавап эзлисез

Бер тирәк, унике ботак,
Һәр ботакта дүрт сабак.

- Уйлашып алыгыз. Сез ничек уйлыйсыз? Дәлилләгез.
- (1 ел. 1 елда12 ай, 1 елда дүрт ел фасылы).


**Нәтиҗә.**

- Димәк, без бүген дәрестә нәрсә турында сөйләшербез? (ел, аның фасыллары турында)

**Үзбәя.**

**2. Модель төзү. Модель буенча эш.**

- Сез урыннарда төзисез. Минем янга булышучылар чыга.




- 1 тирәк нәрсә ул? (1 ел)
- Ничә ел фасылы бар? (1елда 4 ел фасылы бар).
- 1 елда ничә ай бар? (1 елда 12 ай.)
- Һәр ел фасылы ничәшәр айга бүленә? (3 айга)
- Көз, кыш айларын бер-берегезгә әйтеп карагыз әле.

**Үзбәя.**

- План, модель буенча сөйли алсагыз,барлык ел фасылларын, ай исемнәрен дөрес итеп әйтә алсагыз, үзегезгә “5” ле билгесе куегыз!

**III. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү.**

**1. Календарьлар белән эш.**

- Елның башын,ахырын нәрсәгә карап әйтеп була? (Календарьга карап).
- Күрәм,сезнең өстәлләрегездә календарьлар бар. Әйдәгез, аларны карап үтик.
- Ел нинди ай белән башланып китә? (Гыйнвар).
- Ел нинди ай белән бетә? (Декабрь).
- Кем соңгы көнен тапты? (31 нче декабрь).

(Тактага бу сүзләр куела.)

| 1нче гыйнвар | 31нче декабрь |
| --- | --- |

- Димәк, без бүген дәрестә нинди көннәр турында сөйләшербез?

**Нәтиҗә.**

- 1. Ел 1 нче гыйнвар белән башланып китә, 31 нче декабрь белән бетә.
- 2. Бу көннәрне без календарьдан карап беләбез.

(Нәтиҗәләр группаларда кабатлана.)

**Үзбәя.**

**2.Календарь төшенчәсе өстендә эш.**

-Татар теленең аңлатмалы сүзлегендә календарь сүзенә түбәндәгечә аңлатма бирелә:

| |
|---|
| Календарь – эзлекле тәртиптә елның барлык көннәр исемлеген биргән таблица яки кенәгә. |

- Белемнәрне төркемдә кабатлыйбыз. Димәк, календарь - эзлекле тәртиптә елның барлык көннәр исемлеген биргән таблица яки кенәгә.

**Нәтиҗә.**

**Үзбәя.**

**3.Әсәр өстендә эш.**

-Мин сезгә Н.Дәүлинең әсәрен укыйм.

(Укытучы әсәрне укый.)

- Хикәя нәрсә турында? (Хикәя Яңа елны каршылау, календарьның соңгы бите турында.)
- Календарьның соңгы бите нинди көн ул? (Календарьның соңгы бите-31 нче декабрь.)
- Әсәрне үзегез укып чыгыгыз!

(Балалар хикәяне үзләре укып чыгалар.)

- Бу әсәрнең жанры нинди? (Хикәя).
- Хикәянең исеме эчтәлегенә туры киләме?
- Бу хикәягә нинди рәсемнәр ясар идегез?

Бер-берегезгә әйтеп карагыз.



**Нәтиҗә.**

**Үзбәя.**

**4. Сорауларга җавап эзләү. Сайланма уку.**

- Яңа ел кайсы айда,кайсы көндә һәм сәгать ничәдә килә?
- Бу бәйрәмне кемнәр белән каршылыйлар?
- Кешеләр бер-берсен ничек тәбриклиләр?
- Яңа елны балалар ни өчен аеруча сагынып көтеп алалар?

**Нәтиҗә.**

**Үзбәя.**

Бу сорауларның барсына да җавап бирүчеләр үзләренә яхшы билге куя алалар.

**III Рефлексив бәяләү.**

1. -Нәрсә белдек?

-Нинди нәтиҗәләр ясый алдык?

**Нәтиҗә.**

1. Елның башы - 1 нче гыйнвар, иң соңгы көне - 31 нче декабрь.
2. Яңа ел –күңелле бәйрәм.
3. Яңа елны балалар сагынып көтеп алалар.

**2. Рәсем буенча эш.**

- Нинди бәйрәм сурәтләнгән?
- Бу бәйрәм турында нәрсә белдегез?

**3. Өй эше**.

1в. Н.Дәүли хикәясен укып килергә, сорауларга җавап бирергә.

2в. Бу хикәянең эчтәлеген сөйләргә.

3в. “Календарьның соңгы көне” хикәясенә рәсем ясап килергә .

**Үзбәя.**

**-Төркемнәрдә киңәшегез һәм дәрестә алынган белемегезгә гомуми билге куегыз.**

## ГЫЙЛЕМ - НУР, НАДАНЛЫК – ХУР.
**(Әхлак дәресе, 4 нче татар сыйныфы)**

***Мөхетдинова Зөлфия Дамир кызы,*** *31 нче мәктәпнең I квалификацион категорияле укытучысы*

**Дәреснең максатлары:**



1. Дидактик:

- төшенчә өстендә эш.

2. Психологик:

- төркемнәрдә эшли белү, үз-үзләренә бәя кую, ярдәмлекләр белән эшли белү күнекмәләрен үстерү.

3. Тәрбияви:

- белемнең кеше тормышындагы роле.

**Дәрес тибы**: Уку мәсьәләсен чишү.

**Җиһазлау**: компьютер, проектор, электрон такта, үзбәя өчен махсус кәгазь битләре, яулык, конвертлар.

**Файдаланылган әдәбият.**

1. Казыйханов В.С. Әхлак дәресләре.
2. К. Насыйриның “ Китаб-әт- тәрбия” китабы.
3. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге.

**Дәрес барышы.**

**<u>I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру этабы.</u>**

1. Психологик уңай халәт тудыру.
2. Уку мәсьәләсен кую.

Тактадагы мәкальләр буенча эш.

**1 нче слайд.**

**Гыйлем - нур, наданлык-хур.**

**Уку - белем орлыгы, белем - бәхет орлыгы.**

У: Бу мәкальләрдә нәрсә турында сүз бара?

Т: Бу мәкальләрдә уку, белем, гыйлем турында сүз бара.

У:Фикерләр бертөрле, димәк без бүгенге дәрестә нәрсә турында сөйләшербез икән?

Т: Бүгенге дәрестә уку, белем, гыйлем һәм аның файдасы турында сөйләшәчәкбез.

У: Әйдәгез бер-беребезгә әйтеп карыйк.

(Тактага өч сүз беркетелеп куела: гыйлем, уку, белем)

**<u>Үзбәя</u>.**

**<u>II. Уку мәсьәләсен чишү.</u>**

Төркемнәрдә тикшерү өчен биремнәр.

**<u>1 нче бирем.</u>**

а) Төшенчә өстендә эш ( аңлатмалы сүзлек белән эш)

У: Әйдәгез әле кабаттан ачыклыйк, нәрсә ул гыйлем? Балалар, сүзлекләрдән гыйлем сүзенең аңлатмасын эзләп табыйк әле.

Көтелгән җавап үрнәге. Гыйлем-1) Белем. - Гыйлем китапның эчендә дә, тышында да. Мәкаль;

2) Фән гыйлеме;

3) Галим, белемле ( кеше). Гыйлем алу. Уку, өйрәнү, белем алу.

Төркемнәрдә әйтеп карау.

**<u>Үзбәя.</u>**

**<u>2 нче бирем.</u>**

У: Балалар, бу нинди китап?

Т: Нәсыйхәт китабы.

У: Без бу китапны икенче төрле ничек әйтәбез?

Т: Бу китапны без акыллы фикерләр китабы дип әйтәбез.

У: Каюм Насыйриның “Китаб-әт-тәрбия” китабының 34 нче нәсыйхәтендә шундый юллар бар **(2нче слайд)**: “Яшь чакта алган гыйлем, ташка чокып ясалган бизәккә охшаш булыр. Кечерәк вакытта күп фәннәргә төшендермәк кирәк.”

Төркемнәрдә тикшерү өчен сораулар:

У: Нәсыйхәттә сүз нрсә турында бара?

Т: Нәсыйхәттә сүз гыйлем турында бара.

У: Гыйлем нәрсә белән чагыштырыла?

Т: Гыйлем ташка чокып ясалган бизәк белән чагыштырыла.
У: Укырга кайчан керешергә кирәк?
Т: Укырга кечкенәдән керешергә кирәк.
У: Үзбәя куяр өчен җавапларны төркемнәрдә үз-үзегезгә кабатлап карагыз да үзбәя куегыз.
**<u>Үзбәя кую.</u>**
У: Ә хәзер әйдәгез мәкальнең икенче өлешенә әйләнеп кайтыйк.
**<u>3нче бирем.</u>**
У: Мәкальнең икенче өлеше буенча эш.
**3 нче слайд**. Наданлык - хур.
Т: Наданлык - хур.
Төркемнәрдә тикшерү өчен сораулар:
У: “Наданлык – хур” дигәнне ничек аңлыйсыз?
Т: Надан кеше оятка калдыра.
Т: Көлкегә калу, оятлы булу.
У: Наданлык нидән килә?
Т: Наданлык тырышмаганлыктан, ялкаулыктан, иренгәнлектән килә.
У: Бу җавапны бер-беребезгә шелтә белән кабатлап карыйк әле .
У: Надан сүзе кемгә карата әйтелә?
Т: Аз белемле кешеләргә.
Т: Үз эшен начар белүчегә.
Т: Аңгыра, акылсыз, кара фикерле кешегә.
Т: Укыганда, язганда хата җибәрүчегә.
У: Г.Тукайның бу турыда нинди шигырь юллары бар?
Б: “Аh, оят, хурлык, түбәнлекләр иренгәннән килә” .
**<u>4 нче слайд</u>** “Ах, оят, хурлык, түбәнлекләр иренгәннән килә”. Г.Тукай.
У: Балалар, надан булырга ярыймы?
Т: Юк, надан булырга ярамый.
**<u>Үзбәя.</u>**
**<u>4 нче бирем.</u> “Төен” уены.**
**5 нче слайд:** Уку - энә белән кое казу.
Уен уйнала.
**<u>Үзбәя.</u>**
**<u>Ш. Рефлексия.</u>**
У: Бүгенге дәрестә нәрсә турында сөйләштек?
Т: Без дәрестә уку, белем, гыйлем, наданлыкның зыяны турында сөйләштек.
У: Дәрестә безгә нәрсә ярдәм итте?
Т: Мәкальләр ярдәм итте.
Т: Нәсыйхәт ярдәм итте.
У: Балалар, сезгә дәрес ошадымы?
**<u>Үзбәя.</u>**
**<u>Өй эше</u>**. Белемле булу, наданлыкны җиңү буенча үз-үзеңне тәрбияләү планын төзеп карарга.

## ИЯРЧЕНЛЕ КУШМА ҖӨМЛӘЛӘРДӘ ТЫНЫШ БИЛГЕЛӘРЕ
### 9 нчы сыйныф, татар төркеме

***Нәфыйкова Зөлфия Нәкыйп кызы,***
***Садыйкова Лидия Хәмдегали кызы***
*31 нче мәктәпнең югары квалифлкацион категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучылары*

**Максатлар:**
**Белем бирү максатлары (дәреснең предмет нәтиҗәсе):**



Иярченле кушма җөмләләрдә тыныш билгеләре турында төшенчәләрне камилләштерү. тыныш билгеләрен гамәлдә куллану; тыныш билгеләрен кую нигезләмәләрен гамәлдә куллану;

**- Үстерү максатлары (дәреснең метапредмет нәтиҗәсе):** мөстәкыйль һәм төркемнәрдә эшли белүләрен үстерү; үз-үзләренә бәя куя белү күнекмәләрен үстерү; аналитик һәм синтетик фикерләү сәләтләрен үстерү.

**<u>Тәрбия бирү (дәреснең шәхси нәтиҗәсе):</u>** <u>аралаша белү сәләтен үстерү</u>

**Җиһазлау***:* интерактив такта.

**Материал:** дәреслекләр (М. Зәкиев, С.М. Ибраһимов, Татар теле, Казан: “Мәгариф”, 2008нче ел), эш дәфтәрләре, тест сораулары (Н.В. Максимов, Татар теленнән тестлар, Казан: “Мәгариф”, 2008нче ел);

**Дәрес тибы:** Уку мәсьәләсен чишү.

**Дәрес барышы:**

**I. Ориентлаштыру - мотивлаштыру этабы.**

**Психологик уңай халәт тудыру.**

**Тирәнлек – диңгездә, зирәклек – гыйлемдә.**

- Диңгез тирәнме? (тирән)

- Ә тапкыр, зирәк кешенең нәрсәсе күп була? (белеме)

**2. Өй эшен тикшерү.** Өч дәрәҗәдә бирелгән өй эшләрне тикшерү

**А).** Уку стандарты буенча бирелгән өй эшен тикшерү.

**Нәтиҗә:** *Без җөмләләрне төзелешләре ягыннан карадык.*

**Ә).** Ярым иҗади эш. Р.Фәйзуллинның шигырен сәнгатьле уку.


(Сәнгатьле укуга бергәләп билге куела.)

**Б).** Тулы иҗади эш.1нче җөмләнең авторы кем? “Татар моңы, татар көе” темасына иҗат ителгән үз уйлануларын берничә укучы укып күрсәтә.

**3. Укучыларның белемнәрен тигезләү.** Төркемнәрдә эш.

Модель төзү.

ТЫНЫШ БИЛГЕЛӘРЕН КУЮ НИГЕЗЛӘМӘЛӘРЕ



Мәгънәсенә карап Төзелешенә карап

- Татар телендә җөмләләрдә тыныш билгеләрен кую нинди өлешләргә бүлеп карала? (- кызыл юл; - җөмлә ахырында: . ! ? ?.. !.. ...; җөмлә эчендә: , : - () “” ;)

**Нәтиҗә:** Без җөмләләрдә ТЫНЫШ БИЛГЕЛАРЕН КУЮ НИГЕЗЛӘМӘЛӘРЕН билгеләдек.

**Үзбәя** (Экрандагы җавап белән чагыштыргач билгеләнә).

**1нче бирем:** блиц-турнир (сайлап алынган бер укучы тактаның артында үзе билгеләгән җавапларны куеп бара, дәфтәрләрдә дә ? тәртибе буенча эшләнә)

1. Хәбәр исем яки сан белән белдерелгәндә хәбәр белән ия арасына нинди тыныш билгесе куела? 1. (-)

2. Аерымланган кисәкләр янында нинди тыныш билгесе куела? 2. (,)

3. Аныклагычлар янында нинди тыныш билгеләре куела? 3. (, - : ())

4. Эндәш сүзләр янында нинди тыныш билгеләре куела? 4. (, !)

5. Тиңдәш кисәкләр янында нинди тыныш билгеләре куела? 5. (, - :)

6. Тезма кушма җөмлә эчендә нинди тыныш билгесе куела? 6. (, -)

**Үзбәя** (Укучы эшен тикшерүдән соң билгеләнә)

**4.Укучылар белән берлектә уку максатын кую.**

**Бирем 1.**

- Эш беткәч, ... (уйнарга ярый)
- Әйтем – сүзнең бизәге, (мәкаль – сүзнең җиләге).
- Амбар төбендә икмәк бар, (картлар сүзендә хикмәт бар).
- Баланы яшьтән бөк, (агачны баштан бөк).
- Җидесендә ни булса, (җитмешендә шул булыр).
- Һөнәрле булып ул үссен, (холыклы булып кыз үссен).
- Яхшы сүз җанга рәхәт, (яман сүз җанга җәрәхәт).
- Эштә булса батырлык, (шунда була матурлык).
- Алтынны алдыңа алсаң, (икмәкне йөрәгеңә кыс).
- Җиреӊ яхшы булса, (амбарың ашлык белән тулар).
- Җирне бер кат туйдырсаң, (ул сине ун кат туйдырыр).
- Аягы пычрак – өй пычратыр, (теле пычрак – кеше пычратыр).

**Үзбәя (**Экрандагы җавап белән чагыштыргач билгеләнә)

**Бирем 2.**

- Мәкальләр төзелешләре ягыннан нинди җөмләләр? (иярчен, тезмә)

- Кайсылары тезмә, кайсылары иярченле кушма җөмләләр? (иярчен: 1, 5, 8, 9, 10, 11; тезмә: 2, 3, 4, 6, 7, 12;)

- Иярчен кушма җөмләләрдә нинди тыныш билгеләре куела? (,)

- Иярчен кушма җөмләләрдә нинди тыныш билгеләре куела? (, : - ())


- Бүгенге дәрес темасын билгелибез. **(Иярченле кушма җөмләләрдә тыныш билгеләре)**

**Үзбәя.**

**II. Белемнәрне адымлап үзләштерү этабы.**

**Бирем 1.** Түбәндәге төшенчәләрдән модель төзергә: теркәгечле тезмә кушма җөмлә, аналитик, җөмлә, гади, тезмә, кушма, иярченле кушма җөмлә, синтетик, теркәгечсез тезмә кушма җөмлә, иярченле.

**ҖӨМЛӘ**




**Үзбәя (**Парлап эшләнә, һәр пар билге куя.)

**2 нче бирем** Тест сорауларына җавап алына.

**Үзбәя** (Экрандагы җавап белән чагыштыргач билгеләнә)

**III. Рефлексия. 5 мин.**

- Татар телендә төзелеше ягыннан җөмләләр ничә төрле була? (2)

- Нindиләр инде алар? (гади, кушма)

- Гади җөмләгә характеристика бирергә? (1. хикәя, өндәү, сорау; 2. җәенке, җыйнак; 3. туры һәм кире тәртипле; 4. тулы һәм ким; 5. бер һәм ике составлы)

- Кушма җөмләләрне төзелешләре ягыннан нindиләргә бүлеп өйрәнелә? (тезмә, иярченле)

- Тезмәләре төзелешләре буенча нindиләргә бүленә? (теркәгечсез, теркәгечле)

- Бүгенге дәрес темасы: (Иярченле кушма җөмләләрдә тыныш билгеләре).

- Иярченле кушма җөмләләрдә нинди тыныш билгеләре куела? (, : - 0)

- Иярченле җөмләләр төзелешләре ягыннан нindиләргә аерыла? (аналитик, синтетик)

**Үзбәя**

**Өй эше.** 1. <u>Уку стандарты буенча</u>: 70нче күнегүнең 1нче өлешендәге тезмә кушма җөмләләрне иярчен җөмләләр итеп үзгәртергә.

2. <u>Ярымиҗади</u>: бирелгән мәкаләләрне тәмамларга: 1. Кыш көне күп итеп кар тотсаң... 2. Сабанда тирләмәсәң... 3. Суган сирәк булса... 4. Иген чәчкәндә еласаң...

3. <u>Тулы иҗади</u>: “Ак кар бөртекләренең сихри көче...” темасына 10 кушма җөмләдән торган хикәя язарга (5се тезмә, 5се иярчен).

**ТЕСТ СОРАУЛАРЫ**

Тыныш билгесе кайсы очракта дөрес куеган?

1. Икесенең дә сүз әйтерлек хәле калмаган (1) күзләре генә көлә дә (2) иреннәре елмая иде (3) (Л.Ихсанова)

А) (1) өтер, (2) тыныш билгесе куелмый, (3) нокта

Б) (1) өтер, (2) өтер, (3) нокта

В) (1) өтер, (2) нокталы өтер, (3) нокта

Г) (1) нокталы өтер, (2) өтер, (3) нокта

2. Бушап калган иген басулары(1)

Җырлар тынган (2) сүнгән учаклар(3) (Р. Низами)

А) (1) өтер, (2) нокталы өтер, (3) нокта

Б) (1) өтер, (2) сызык, (3) нокта

В) (1) сызык, (2) өтер, (3) нокта

Г) (1) өтер, (2) өтер, (3) нокта

3.Юллар буйлап(1)

Очып уйнап(2)

Җәяүле буран йөри(3) (Р. Вәлиева)

А) (1) сызык, (2) сызык, (3) нокта

Б) (1) өтер, (2) нокталы өтер, (3) өндәү билгесе

В) (1) өтер, (2) өтер, (3) нокта
Г) (1) өтер ,(2) нокталы өтер, (3) нокта
4. Кара туфрак имеп үскән алмагачның
Алмалары нидән кызыл (1) шунысы серле (2) (Р. Низами)
А) (1) сызык, (2) нокта
Б) (1) өтер, (2) нокта
В) (1) ике нокта, (2) нокта
Г) (1) нокталы өтер, (2) нокта
5. Гел шулай керәсең төшемә (1)
Кулыңда чәчәкләр бәйләме (2) (Ф. Яруллин)
А) (1) сызык, (2) нокта
Б) (1) ике нокта, (2) нокта
В) (1) нокта, (2) нокта
Г) (1) өтер, (2) нокта
6.Нәкъ шунда (1) мәйдан уртасында (2)
Фонтан булыр (3) бәлки (4) кем белә (5) (Р. Низами)
А) (1) өтер, (2) сызык, (3) өтер, (4) өтер, (5) нокта
Б) (1) сызык, (2) сызык, (3) өтер, (4) өтер, (5) сорау һәм өндәү билгесе
В) (1) өтер, (2) өтер, (3) өтер, (4) өтер, (5) сорау билгесе
Г) (1) өтер, (2) тыныш билгесе куелмый, (3) өтер, (4) өтер, (5) нокта

## БАЛАЧАК – ХӘТЕРДӘ МӘҢГЕ КАЛАЧАК

**(рус төркемендә әдәбият уку дәресе, 5 нче сыйныф)**

***Нәбиуллина Резедә,***
*31 нче урта мәктәпнең беренче квалификацион категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы*



**Максатлар:**

**Белем бирү максаты (предмет нәтиҗәсе):** Г.Тукай “Исемдә калганнар” автобиографик әсәре аша укучыларны аның балачагы белән таныштыруны дәвам итү;

**Үстерү максаты (метапредмет нәтиҗә):** төркемнәрдә ярдәмләшеп эшләргә өйрәтү;

**Тәрбия бирү (шәхескә кагылышлы нәтиҗә):** укучыларда эти-әниләргә карата ихтирам, ятимнәргә булышу хисе тәрбияләү.

***Материал:*** Татар әдәбияты дәреслеге ( рус телендә гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек. 5 нче с-ф. Беренче кисәк / Ә.Р. Мотыйгуллина, Р.Г. Ханнанов, Л.К. Хисмәтова. – Казан: “Мәгариф – Вакыт” нәшер.,2014. – 111б.

***Җиһазлау:*** мультимедия проекторы, экран, презентация, Г.Тукай китаплары күргәзмәсе, балалар ясаган рәсем күргәзмәсе.

***Дәрес тибы:*** уку мәсьәләсен кую, чишү.

**Дәрес барышы**

А. Монасыйповның “Тукай аһәңнәре” исемле вокаль – симфоник поэмасы яңгырый.

**I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру-**

*Уңай психологик халәт тудыру.*

- Хәерле көн, укучылар!

Укучылар:

- Һәр көн диярлек күрешәбез без,
Һәрбер шатлыкны бүлешәбез без.
Мәңгегә шулай дуслык-татулык
Торсын яктыртып, диешәбез без.

1. **Белемнәрне тигезләү** (сораулык)

- Укучылар, без кайсы әсәр өстендә эшлибез?
- Без Г.Тукайның “Исемдә калганнар” әсәрен укыйбыз.
- “Исемдә калганнар” әсәре кем турында? Ул нинди әсәр?
- Нәрсә соң ул автобиографик әсәр?
- Автобиографик әсәр – ул язучының үз тормышы, үткәне турында язган әсәре. Ул узган вакыйгаларны кабат искә төшерүгә нигезләнә.

- Кем русча әйтә?
- Автобиографическое произведение – произведение основанное на описании автором собственной жизни. Автор размышляет о прошедшем, особо подчеркивая самые яркие впечатления давно прошедших дней.
- I бүлек нәрсә турында?
- I бүлек Г. Тукайның *авыр балачагы* турында.
- Ә ни өчен авыр балачагы дибез?
- Чөнки Г. Тукай ятим үсә.
- Төркемнәрдә бүлекләрдән санагыз: Тукай нинди кайгылар, авырлыклар күрә? Ул кайларда яши? Модельне файдаланып сөйләп күрсәтегез.




**2. Уку мәсьәләсен кую**
- Димәк, Г.Тукай тагын кайларда яши?
- Г.Тукайның тормыш юлы белән танышуны без дәвам итәбез.

**II. Уку мәсьәләсен адымлап чишү**

1 нче бирем. Сүзлек белән эш (проекторда)
- Ә хәзер, укучылар, яңа сүзләр һәм сүзтезмәләр белән танышабыз.

арбасына – на телегу
озатырга – провожать
яланаяклы – босоногие
янәшә – рядом

- Укучылар, әйтегез әле *яланаяк* сүзе нинди сүз?
- Кушма сүз, ике сүздән тора *ялан* + *аяк* .
- Ә *ялт иттердем* сүзе ясалыш ягыннан нинди?
- Бу тезмә сүз, чөнки сүзләр бер-берсе белән тезелеп килгән һәм бер мәгънәне аңлата. (Үзбәя)
- Укучылар, текст яңа сүзләргә бик бай, игътибарлы булыгыз.

2 нче бирем. “Исемдә калганнар” әсәренең II бүлеген 94 нче биттән мөстәкыйль уку.
- Тукайны Кырлайга кем алып кайта? соравына җавап бирегез.

(укыганнан соң көтелгән җаваплар)

3 нче бирем. Автор артыннан бару юлы белән укылган өлешне анализлау.
- Укучылар, ә хәзер Г. Тукай тормыш юлы (балачагы) буенча төзи башлаган модельне тәмамларга ярдәм итегез, әле. Тукай тагын кайларда яши?




- Модельгә таянып Г.Тукайның балачагы турында кем сөйләп карый (көтелгән җаваплар). Үзбәя.
- Яхшы. Ә хәзер үзара сөйләп карагыз. (Укучылар төркемнәрдә бер-берсенә сөйләп карыйлар).

4 нче бирем. Бу өзеккә сез нинди исем кушар идегез? Һәр төркем үз вариантын тәгъдим итә. Кем әзер? (“Кырлайда”, “Ачык йөзләр” һ.б.)

**III. Рефлексия**

Модельдән файдаланып, һәркем үз-үзенә әсәрне сөйли.
- Бүген дәрестә нәрсә өйрәндек? ( Җаваплар тыңлана)

**IV. Үзбәя**
- Укучылар, һәрберегез үз эшен ничек бәяли. (Ничәле? Ни өчен?)

**V. Өй эше бирү** (вариантлап бирелә, сайлап алу мөмкинлеге тудырыла).

I вариант (программа буенча): Г. Тукай яшәгән урыннарны белергә.
II вариант (ярымиҗади эш): үз сүзләрегез белән эчтәлекне сөйләргә.
III вариант (иҗади эш): тулы вариантны укырга мөмкин.

# РӘВЕШ ХӘЛЕ
## (7 нче татар сыйныфы)

***Фокеева Елизавета Павел кызы,***
*31 нчемәктәпнең югары квалификацион категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы*



Максат: 1) Белем бирү максаты (дәреснең предмет нәтиҗәсе): рәвеш хәле турында төшенчә формалаштыру.

2) Үстерү максаты (дәреснең метапредмет нәтиҗәсе): иҗади фикер йөртү сәләтләрен үстерү, әңгәмәдәшеңне тыңлый, бәяли белү;

3) Тәрбия бирү максаты (дәреснең шәхси нәтиҗәсе): татар халык авыз иҗаты - халкыбыз педагогикасының асыл өлеше булуына төшенү.

Дәрес тибы: Уку мәсьәләсен кую һәм чишү

Җиһазлау: мультимедиа проекторы

Дәрес барышы:

**I. Мотивлаштыру-ориентлашу этабы.**

1) а) Психологик уңай халәт тудыру.

б) Өй эшен тикшерү. Зиһен сандыгынданиләр бар?

- Бу мәкальләрдә нинди хәлләр кулланылган?
- Ата-анасына игелек күрсәтмәгән, олыгайгач үзе дә игелек күрмәс.
- Сүз күп җирдә эш аз була.

2) Белемнәрне тигезләү.

Тест сорауларына төркемнәрдә җавап бирегез.

(Слайдта тест сораулары күрсәтелә).

1. Хәлләр

а – 7

б – 8

в – 9 төргә бүленә.

2. Хәлләр җөмләнең

а – фигыль белән белдерелгән кисәген;

б – исем белән белдерелгән кисәген;

в – алмашлык белән белдерелгән кисәген ачыклый.

3. **Без урманга җиләк җыярга бардык** җөмләсендә

а – 1 төрле мәгънәдә 2 хәл бар;

б – 2 төрле мәгънәдә килгән 2 хәл бар;

в – 3 төрле мәгънәдә килгән 2 хәл бар.

4. **Бала кичтән тикмәгә еламаган** җөмләсендә астына сызылган хәл

а – вакыт хәле

б – максат хәле

в – сәбәп хәле.

**Нәтиҗә.**

Модель буенча**УМ билгеләү.**

**Хәл**

| В.х. | У.х. | С.х. | М.х. | Р.х. | К.-ч.х. | Ш.х | Н.х. |
|---|---|---|---|---|---|---|---|

(Көтелгән җавап: 4 төрен, ә бүген 5нчесен өйрәнәчәкбез.Бүгенге уку мәсьәләсе -Рәвеш хәле ).

**Үзбәя.**

**II. УМ адымлап чишү.**

**Бирем 1.**

Мисал язу, җөмлә кисәкләре ягыннан тикшерү.

(Тактада модель-Сорау куеп, җөмлә кисәкләрен ачыклыйбыз.

Нәрсә белән белдерелүен ачыклыйбыз.

и. а. б.с. с и. б.с. хәл ф. х.ф.

Малае аның янында кырыкмыштай төсле уйнаклап йөрде.

Сүзлек өстендә эш.

Слайдта:

Кырыкмыш тай – яллары, койрыклары тигезләп кыркылган 1 яшьлек тай (колын).

Җөмләне тикшерү.

Нәтиҗә1: Димәк,
- рәвеш хәле *ни рәвешле?* (тай төсле) соравына җавап бирә;
- эшнең ни рәвешле үтәлүен белдерә;
- исем+бәйлек белән белдерелә;
- фигыльгә бәйлек аша ияргән;
- Уйнаклап-фигыльгә хәл фигыль кушымчасы (Ітөре) аша ияргән.
**Үзбәя.**
**Бирем 2.**
*и. Б, и. р. х.ф.*
Эш беләнвакыттизүтә.– үзлектән эшләү.
Нәтиҗә2:
Димәк,
- рәвеш хәле-җөмләнең иярчен кисәге;
- ничек? ни рәвешле? соравына җавап бирде;
- эшнең ничек, ни рәвешле үтәлүен белдерде;
- исем+бәйлек, рәвеш белән белдерелде;
- фигыльгә бәйлек, янәшәлек аша иярде.
**Үзбәя.**
**Физкультминут**
**Бирем 3.** Модельләштерү. Төркемнәрдә эш.

**Рәвеш хәле**

| | | | |
|---|---|---|---|
| Җөмләнең иярчен кисәге,эш-хәрәкәтнең ничек, ни рәвешле үтәлүен белдерә. | Ничек? ни рәвешле? | Белдерелә: Исем+бәйлек, бәйлек сүз; рәвеш, Хәл фигыль-I, II төре. | Бәйләүче чаралар: хәл фигыль формасы(1, 2);-дай,-дәй,-ча,-чә кушлары;-бәйлекләр,бәйлек сүзләр; -янәшәлек юлы. |

(Слайдта чыга) Модельне уку, бер–берләренә сөйләү.
**Бирем 4.**
1) 105 нче күнегүдәге схемага нигезләнеп, җөмләләр төзү.
Карточканың берсендә җөмләнең кар- буранны күзәтәм - башы, икенчесендә ахыры.
2) Җөмләләрдә рәвеш хәлен табу.
Бәйләүче чараларны билгеләү.

Күзләремне шардай ачып,
Зарыгып, кышкы каникулны көтәм.
Күбәләк кебек очкан кар бөртекләренә сокланам.

**Гомуми нәтиҗә ясау.**
**Үзбәя.**

**III. Рефлексия.**

1. Дәрескә нинди УМ куелды? Ничек чиштек?
2. **Үзбәя.**
3. **Өй эше** өч вариантта тәкъдим ителә, укучыларга сайлап алу мөмкинлеге бирелә.

1) 105 нче күнегүдәге 2, 4 формасына җөмлә язарга.
2) Мәкальләрне кабатларга.
3) Рәвем хәле кулланып, “Кышкы тамгатҗ” телемасына инша язарга.

# “ЯШЕЛЧӘЛӘР ҺӘМ ҖИЛӘК-ҖИМЕШЛӘР” ТЕМАСЫ БУЕНЧА ЛЕКСИК КҮНЕКМӘЛӘРНЕ НЫГЫТУ ӘДӘБИ УКУ ДӘРЕСЕ
## 2 сыйныф ( рус төркеме)

***Һадиева Сиринә Әсхәт кызы,*** *31 нче мәктәпнең I квалификацион категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы*



**Максатлар:**

**Белем бирү максаты (предмет нәтиҗәсе):** 1.“Яшелчәләр һәм җиләк-җимешләр” темасы буенча өйрәнелгән төшенчәләрне искә төшерү һәм, аларны кулланып, аралашуга күнектерү.

2. Нинди? соравына җавап биреп , әйбернең билгесен белдерү.

3. “Базарда” темасы буенча диалогик-монологик сөйләмгә чыгару.

4. Аерым рәсемнәр яки әйберләрне сурәтләп биргәндә, исем, сыйфат, фигыльләрне дөрес куллану.

**Үстерү максаты (метапредмет нәтиҗә):** төркемнәрдә ярдәмләшеп эшләргә өйрәнү.

**Тәрбия бирү (шәхескә юнәлгән нәтиҗә):** фәнгә карата кызыксыну хисе уяту.

Җиһазлау: интерактив такта, дәреслек, сүзлек, эш дәфтәре, яшелчәләр һәм җиләк-җимешләр, аларның рәсемнәре, тарату өчен кроссвордлар, җимлек.

**Дәрес барышы**

**I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру этабы.**

**1. Психологик уңай халәт булдыру.** Дәресне, башкалардан аермалы буларак, татарча иң яхшы сөйләшкән укучы башлап җибәрә (укытучы ролендә). Әңгәмә.

**2. Белемнәрне тигезләү:**

*Лексика өстендә эш*

Яшелчәләр һәм җиләк-җимеш исемнәрен искә төшерү (кроссвордларны парларда эшләү, дөреслеген тикшерү), (*1, 2 нче слайдлар*).







*Үзбәя№1.*

**3. У*ку мәсьәләсен кую*.**Ребусны чишү, (парларда эш), (*3,4нче слайдлар*)







- Без нинди тема буенча сүзләр өйрәндек? По какой теме мы изучали слова?
- Яшелчәләр һәм җимешләр-җимешләр.
- Да, слова теперь мы знаем и что дальше? Что можем делать дальше?
- Составлять предложения, разговаривать.
- Значит, что мы будем делать на этом уроке? (отвечают, повторят хором-проговаривание):
- Составлять предложения, разговаривать на тему «Яшелчәләр һәм җиләк-җимешләр».
- Да, мы будем учиться употреблять эти слова в речи.

**II. Уку мәсьәләсен чишү этабы.**

1. Бу яшелчәләр һәм җиләк-җимешләр нинди? (*5 нче слайд*)




*<u>Сусыл</u>* сүзе белән сүзлек эше; говорим через левое плечо, через правое плечо, работаем над произношением: [сусыл], составляем словосочетания

- Чия нинди?
- Чия түгәрәк, кызыл, баллы, тәмле, сусыл, йомшак (бер-берсен кабатламыйча).

2. Үрнәк диалогтан соң төркемнәрдә эш. Һәр төркемдә төрле әйбер.

3. Уен аша лексиканы ныгыту: күзләрне яулыклар белән бәйләп, сораулар ярдәмендә (тәфсилле билгеләре буенча предметларны тану) яшелчә яки җиләк-җимешне белү. Мәсәлән:

- Ул нинди?
- Түгәрәк.
- Ул нинди?
- Каты.
- Ул нинди?
- Сары.
- Ул нинди? Тәмлеме?
- Юк, тәмле түгел.
- Ул нинди?
- Әче.
- Суган!

Башта үрнәк уен, соңыннан төркемнәрдә, әйберләр төрле: кишер, суган, кабак, алма, банан һ.б. ***Үзбәя №2.***

4. *Ял ( хәрәкәтләр белән күрсәтеп):*

Без чәчәбез яшелчә:
Кишер, кыяр, кәбестә.
Су сибәбез, су сибәбез,
Алар үсә дә үсә.

Күктә кояш елмая,
Җылы яңгырлар ява,
Рәхәт кенә җил исә,
Яшелчәләр зур үсә.

***Үзбәя №3.***

5.- Яшелчәләр һәм җиләк-җимешләр кайда сатыла?

-Базарда, кибеттә *(6нчы слайд)*




*Ситуатив күнегү:*

Позови друга на рынок. Спроси, куда он идёт. Скажи, что ты идёшь (идёшь на рынок, с мамой идёшь на рынок). Поздоровайся. Поздоровайся с продавцом. Спроси, есть ли арбуз, огурец, яблоко. Спроси, сколько стоит арбуз, огурец, яблоко. Попроси одну дыню, капусту, 1 кг лука, 2 кг картошки, чеснока, моркови. Скажи спасибо, попрощайся.

1)- Әйдәгез, базарга барабыз һәм җиләк-җимешләр, яшелчәләр сатып алабыз.

Кто готов идти на рынок? Кто кого позовёт? Кто будет продавцом, кто покупателем?

2) Төркемнәрдә эш: һәр төркем берәр әйбер сатып ала. Тыңлыйбыз. *Үзбәя №4.*

**III. Рефлексия**

- Безнең бүген максатыбыз нәрсә иде?
- Какая у нас была цель?
- Нинди яңа сүз булды?
- Син нинди яшелчә, җиләк-җимешләр яратасың?
- Мин алма яратам, чөнки алма тәмле, *сусыл*, баллы.

**IV.*Үзбәя***

**V. Өй эше:**

1.Кроссворд.

2. Написать 2-3 предложения об овоще или фрукте, не называя его (1 на выбор). Например, Ул бакчада үсә. Ул түгәрәк, кызыл, йомшак, сусыл, тәмле, зур. (помидор)

3.Кто хочет, можете и нарисовать.

## КОММУНИКАТИВ ТЕХНОЛОГИЯ НИГЕЗЕНДӘ ДӘРЕС ПЛАНЫНА ҮРНӘК («ТАТАР ТЕЛЕ», 3 НЧЕ СЫЙНЫФ, 42-44 НЧЕ ДӘРЕСЛӘР)

***Г.Ф. Нәҗметдинова*** - *«Аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнүле 11 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе, 1 нче категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

Түбәндәге текстны өйрәнү өчен циклда 3 сәгать бирелгән:

1 нче дәрес – ЛКФ,

2 нче дәрес – ГКК,

3 нче дәрес - Д/М сөйләм дәресе.

**Текст «Ашханәдә».**



Безнең мәктәптә ашханә бар. Пешекче апалар бик тәмле пешерәләр. Без көндезге ашны ашханәдә ашыйбыз. Безгә ашханә ошый.

Меню төрле-төрле була. Безгә кәбестә ашы да, токмачлы аш та пешерәләр.

Ә боткалар котлет белән тәмле була. Аннан соң без чәй, компот, кесәл эчәбез. Без пешекче апаларга рәхмәт әйтәбез.

**Лексик күнекмәләр формалаштыру (ЛКФ) дәресенең үрнәк планы**

**Тема: “Ашханәдә**” текстындагы яңа лексика.

**Дәрес тибы: ЛКФ**

**Дәрес максатлары: (Укытучы өчен)**

I.1) “Ашханәдә” текстындагы яңа сүзләр белән таныштыру;

2) Хәзерге заман хикәя фигыльнең 1,3 нче зат берлек сан формалары;

3) Ашханәдә нәрсә ашаганыңны, нәрсә пешергәннәрен әйтә белү.

II. 1) Фикерләү сәләтен үстерү;

2) Укытучының күрсәтмәләрен аңлап үти белү;

3) Парларда һәм күмәк эшли белү.

III. Пешекче хезмәтенә хөрмәт тәрбияләү.

**Җиһазлау:** Р.З. Хәйдәрова “Күңелле татар теле”, (47-48 нче битләр); методик ярдәмлек (20 нче бит), дәрескә әзерләнгән презентацион материаллар; Р.З. Хәйдәрова, “Татарский язык в таблицах”.

**Дәрес барышы.**

**I. Оештыру.**

1) уңай психологик халәт тудыру;

2) дежур укучы рапорты;

3) укучыларның бер-берсенә комплиментлар әйтүе.

**II. Өй эше тикшерү.**

1. 1-24 кадәр саннарны кабатлау.
2. Экрандагы сәгать рәсеме белән вакытны әйтү.
3. Укытучы сораулары:

- сәгать ничә?

**4.** Парларда эш: бер-берсеннән сәгатьне сорау һәм җавап бирү.

**III. Яңа сүзләр белән таныштыру.**

Тактада транскрипция билгеләре белән язылган яңа сүзләр:

***ашханә - [ашхәнә]***

***кәбестә - [кәбэстә]***

***аш - [аш]***
***ботка - [бŏтка]***
***токмачлы - [тŏкмачлы]***
***кесәл - [кэсәл]***
***пешекче – [пэшэкчэ]***
***- ]***

1. Тактада язылган яңа сүзләрнең мәгънәсен ачыклау (семантизацияләү).

2. Яңа сүзләрнең әйтелеше өстендә эш (укытучы артыннан хор белән һәм аерым-аерым кабатланыла):

- яңа сүздәге үзенчәлекле авазларны әйтү;
- сүзне кабатлау;
- сүзтезмә әйтү: *кәбестә ашы, токмачлы аш, баллы кесәл, баллы чәй, пешекче пешерә һ.б.;*
- 2-3 сүздән торган, ләкин яңа сүз кергән җөмләләр әйтү: 1) А*шханә матур. 2) Ботка тәмле. 3) Пешекче аш пешерә. 4) Мин баллы чәй эчәм.*

3. Яңа сүзләр кулланып, ситуатив күнегүләр белән эшләү:

Р.З. Хәйдәрова Методик кулланма, 3 сыйныф, 20-21нче битләр, 3 нче бирем.

4. Аудирование:

*Прослушайте и укажите слова, в которых есть звук* ***[ŏ].***

**Дөге, кәбестә, ботка, аш, пешекче, тәмле, токмач.**

5. Яңа сүзләрнең язылышы өстендә эш:

- хаталар профилактикасы үткәрү;
- хәтер диктанты язу.

6. Яңа сүзләрне тәрҗемәсе белән дәфтәргә язу; метапредмет нәтиҗәләрен үстерү йөзеннән, берничә сүзне татарча-русча сүзлектән карау.

7. Сүзләрне дөрес укы. Дәреслек, 47 бит, 2 нче күнегү.

**IV. Яңа сүзләрне сөйләмдә куллануны ныгыту.**

1. “Тәрҗемәче” уены. Балалар парларда бер-берсеннән сүзләрнең тәрҗемәсен сорыйлар.

2. Физкультминут. (яңа лексиканы кертеп).

Ризык кергән сүзләргә торып басалар, булмаса – кул чабалар.

3. Презентацион материал белән эш. Җөмләләрне җәенкеләндереп уку: Ашханәдә ашыйм. Пешекче пешерә. Без рәхмәт әйтәбез. (Җөмләләрне хәзерге заман хикәя фигыльнең 1 һәм 3 зат берлек санда куеп әйтү).

4. Ишетеп аңлау күнегүләре белән эш.

1. Прослушайте и скажите что добавлено ко второму предложению каждой пары:

1) Аш. – Токмачлы аш.
2) Мин кәбестә ашы яратам. – Мин дөге ашы яратам.
3) Котлет бик тәмле. – Котлет белән бәрәңге бик тәмле.

5. Чагыштырма грамматик таблица аша хәзерге заман хикәя фигыльнең зат-сан белән төрләнешен кабатлау. Р.З. Хәйдәрова “Татарский язык в таблицах” (2005 ел), 22 нче бит.

6**.** Презентацион материал белән эш. Рәсемнәргә туры килгән җөмләләрне табу.

Мин ашханәдә **токмачлы аш** ашыйм.
Син **кесәл** эчәсеңме?
Алсу **ботка** ашый.
Безнең мәктәптә **ашханә** бар.

7.Диалогка төшеп калган репликаларны өстә.

- Сезнең мәктәптә ашханә бармы?
-.... .
-... .
- Әйе, мин ашханәдә көндезге ашны ашыйм.
- Син нинди боткалар яратасың?
-... .
- Мин дә карабодай боткасын яратам.

8. Диалогны дәфтәргә язу.

9.Иң яхшы диалог сөйләүче парга конкурс.

**V. Өй эше.**

**а)** Дәреслек, 47 бит 1 нче күнегү сүзләрне ятларга. **б)** Дәфтәрдәге диалог үрнәгендә яңа диалог төзү.

# 8 НЧЕ СЫЙНЫФНЫҢ ТАТАР ТӨРКЕМЕНДӘ ТАТАР ТЕЛЕ ДӘРЕСЕ “ҖӨМЛӘ КИСӘКЛӘРЕН КАБАТЛАУ”

***Ч.С. Харисова*** - *«Аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнүле 11 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе, татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

Туган оясыннан аерылган кош
Канатына мәңге ял тапмый,
Туган телен яратмаган кеше
Башкаларның телен яратмый.

*Ә. Ерикәй.*

Максат: 1) Укучыларның җөмлә кисәкләре буенча өйрәнгәннәрен ныгыту, аларны таный, аның төрләрен дөрес билгели белү.



2) Текстта күтәрелгән проблеманы таба белергә өйрәтү.

3) Туган тел кешенең – мәңгелек юлдашы.

Җиһазлау: текст, бланклар, компьютер.

Кулланылган материал: Татар халык мәкальләре, М.Юныс әсәреннән өзек.

Дәрес төре: ныгыту дәресе.

Методлар: әңгәмә, мөстәкыйль эш, биремнәрне үтәү, өлешчә эзләнү, биремнәр үтәү, индивидуаль,парлап эш.

Дәрес барышы:

I. Оештыру. Исәнләшү. Бер укучы шигырьне укый, шуннан чыгып дәреснең темасы билгеләнә. (укучылар 2 командага бүленә, аларга һәр укучының дөрес җавабын билгеләргә кушыла).

II. Яңа материалны өйрәнү.

Туган тел

(1) Якшәмбе көнне Мәскәү татарлары Измаил паркына җыелалар. (2) Өч ел буе шушы паркка мин дә йөрдем.

(3) Йөз яшьлек юкә агачлары урап алган мәйданда, өздереп, тальян гармун уйный. (4) Яшь егетләр, яшь кызлар гармунга кушылып җырлыйлар, әйлән-бәйлән уйныйлар, бииләр. (5) Авылда чакта уен җырларын күп тыңладым мин. (6) Авыл җирендә күбрәк мәхәббәт, яшьлек турында, аның заяга үтүе, бәхетнең кыска гомерле булуы турында җырлыйлар иде. (7) Бу бакчада исә авылны сагыну, туып-үскән җирләрне юксыну моңнары өстенлек итә. (8) Югыйсә минем милләттәшләрем Мәскәүгә үзләре теләп килгәннәр. (9) Әйе, шәһәрдә тормыш уңайлырак. (10) Эше-хезмәте дә җиңелрәк. (11) Монда - музейлар, театр, концерт заллары. (12) Ә шулай да татарлар һәр атна менә шушында җыела. (13) Туган телдә сөйләшә, җыр тыңлый.

(14) Туган тел! (15) Үзәкнең иң түренә кереп утырган әрнүле, татлы бер тылсым! (16) Синең гармун ыңгырашуы аша колакка килеп бәрелгән бер сүзең яшәүнең мәгънәсен көчәйтеп җибәрә, күңелне пакьләндерә, хыял-өметләрне тергезә, тормыштагы авырлыкларны, гаделсезлекләрне җиңеп чыгарга көч өсти. (17) «И туган тел, и матур тел, әткәм-әнкәмнең теле!» - дип, юкка гына әйтмәгән бөек шагыйрь. (154 сүз)

*(М. Юныстан)*

1. Укучылар текстны укыйлар. Сүзлек белән эш. Башта инт. тактада сүзләр тәҗемәсез күрсәтелә, соңыннан тәрҗемә ителә.

Өздереп-
Әйлән-бәйлән-
Заяга үтү-
Юксыну-
Әрнүле –
Чакта-
Пакьләндерү-
Гаделсезлек-
Өздереп - 1) четко, ясно, внятно 2) выразительно
Әйлән-бәйлән- хоровод
Заяга үтү - впустую, попусту, понапрасту
Юксынырга - тосковать
Әрнүле – 1) ноющий, щемящий 2) горестный, скорбный
Авылда чакта - в деревне

Пакьләндерү - облагородить, очистить

Гаделсезлек - несправедливость

2. Текст буенча сораулар бирү

- М.Юныс нәрсә әйтергә теләгән?
- Автор безне нәрсәгә чакыра, өнди?
- Бүгенге көндә татар теленең тоткан урыны?
- Телне онытмаска безгә нәрсәләр ярдәм итә?
- Туган телнең кадере кайчан сизелә?
- Читкә киткәч, туган тел (җырлар, татар көйләре) кешегә ничек тәэсир итә?
- «И туган тел, и матур тел, әткәм-әнкәмнең теле!», - дип кем әйткән?
- Бу шигырьне искә төшерә аласызмы?

III. Белемнәрне барлау, ныгыту, кабатлау.

3.Укучыларга текстлар һәм бланклар өләшенә. Текстларда җөмләләрнең саны һәм сүзләр кара хәрефләр белән бирелгән була. Һәр укучы үз бланкында билгеләнгән сүзләрне координаталар яссылыгында нокталар белән билгели.(х-сүзләр саны, у- җөмлә кисәкләре). Соңыннан, нокталарны тоташтырып, графигын күрсәтә. График интерактив тактада күрсәтелә, бергәләп тикшерелә.

(1) **Якшәмбе көнне** Мәскәү татарлары Измаил паркына **җыелалар.**

(2) Өч ел буе **шушы** паркка **мин** дә йөрдем.

(3) Йөз яшьлек юкә агачлары урап алган мәйданда, өздереп, тальян **гармун уйныйлар.**

(4) Яшь егетләр, яшь кызлар **гармунга кушылып** җырлыйлар, әйлән-бәйлән уйныйлар, бииләр.

(5) Авылда чакта уен **җырларын** күп **тыңладым** мин.




***Физкультминутка.*** Укучылар дөрес раслауга урыннарыннан торып басарга тиеш.

-Аергыч фигыль сүз төркеме белән белдерелә.

-Туры һәм кыек тәмамлыклар була.

-Ия һәм хәбәр- җөмләнең баш кисәкләре.

-Хәлнең 5 төре бар.

-Вакыт хәле кайда? соравына җавап бирә.

-Ия һәм хәбәр чыгыш килешендә килсә, алар арасында сызык куела.

4. Җөмләләрнең схемалары бирелә. 1нче абзацтан шушы схемаларга туры килгән җөмләләрне табып дәфтәргә язалар.(Дәфтәрдә эш).

Хәл аергыч хәл ия хәбәр.(2 җөмлә)

(Җавап: Өч ел буе шушы паркка мин дә йөрдем.)

Хәл аергыч тәмамлык хәл хәбәр ия. (5 җөмлә)

(Җавап:Авылда чакта уен җырларын күп тыңладым мин.)

Аергыч тәмамлык хәбәр тәмамлык хәбәр (13 җөмлә)

(Җавап: Туган телдә сөйләшә, җыр тыңлый.)

5. Тактада җыйнак җөмләләр языла, укучыларaларны җәенке җөмлә итеп әйтергә тиеш.

- Укучылар, җыйнак җөмләләргә иярчен кисәкләр өстәп җәенке җөмлә итеп әйтегез.

***Мин яратам. Шагыйрь әйткән. Яшьләр җырлыйлар. Татарлар җыела***.

6. 6 һәм 16 җөмләләрне үзгәртеп әйтергә, яки берничә гади җөмләгә таркатырга.

***Авыл җирендә күбрәк мәхәббәт, яшьлек турында, аның заяга үтүе, бәхетнең кыска гомерле булуы турында җырлыйлар иде***. (Җаваплар: Авыл җирендәге җырларның күбесе яшьлек, мәхәббәт турында. Авылда яшьлекне, мәхәббәтне сагынып җырлыйлар. Авылда башка төрле җырлар җырлана. Авылда мәхәббәт, бәхет турындагы җырларны яраталар. Авылдагы җырларның эчтәлеге бүтән.)

***Гармун ыңгырашуы аша колакка килеп бәрелгән бер сүз яшәүнең мәгънәсен көчәйтеп җибәрә, күңелне пакьләндерә, хыял-өметләрне тергезә, тормыштагы авырлыкларны, гаделсезлекләрне җиңеп чыгарга көч өсти***. (Җаваплар: Гармун тавышы күңелне сафландыра. Татар җырлары яшәргә

көч бирә. Гармун тавышын ишетү- тормышта яшәргә көч бирә. Кешегә мәгънәле яшәү өчен туган телен белергә кирәк. Татар җырлары кешене тынычландыра. Туган телдәге җырларны ишеткәч, кеше хыялларга бирелә. Татар моңы татарларга бик якын.)

7. Татар халык мәкальләре интерактив тактада бирелә.

-Кайсы мәкальләр текст эчтәлегенә ача, туры килә?

-Бу мәкальләр белән килешәсезме?

***Туган телне кадерләгән халык кадерле булыр.***

*Туган тел үзем өчен, башка тел көнем өчен.*

*Телең белән ашыкма, эшең белән ашык.*

*Татлы тел тимер капканы ачар.*

*Усал тел кыш кебек, яхшы тел яз кебек.*

***Алтыда белгән ана телен алтмышта онытмас.***

Текст эчтәлеге белән тәңгәл килгән 2 мәкаль аерылып алына һәм парларда эш эшләтелә. (һәр укучы эчтәлек буенча 1-әр җөмлә яза).

IV. Өй эше.

- Укучылар, дәрестә өйрәнелгәннәрдән чыгып, өйдә “Туган тел” темасына инша язып килегез.

V. Йомгаклау. Билгеләр кую.Үзбәя.

## СӘЛӘТЛЕ БАЛАЛАР БЕЛӘН ЭШ – ЗАМАН ТАЛӘБЕ.

***Яруллина Г.С.,***

*ТР Түбән Кама муниципаль районы 35 нче лицейның милли эшләр буенча директор урынбасары.*

Кешегә бетмәс-төкәнмәс иҗат чыганагы салынган. Менә шул чыганакны ачарга, ирекккә чыгарырга, кешегә иҗтимагый тормышта урынын табарга булышырга, аңа үсү өчен тиешле шартлар тудырырга кирәк.

*Л.Н. Толстой*



Белгәнебезчә, укыту өлкәсендә сәләтле балаларны табу һәм аларның эшчәнлеген үстерү – хәзерге көндә төп бурычларның берсе булып тора. Без баланың сәләтен никадәр тизрәк күреп алабыз, үстерәбез, уңай шартлар тудырабыз, шул очракта гына көтелгән уңышларга ирешә алабыз.

Сәләтле балалар белән эшләү, аларны үстерү, киләчәккә юнәлеш бирү - лицей эшчәнлегенең иң мөһим юнәлешләре. Сәләтле балалар һәр мәктәптә дә бар. Без аларны һәрвакыт игътибар үзәгендә тотабыз һәм аларның бу сыйфатларын тагын да үстерергә тырышабыз. Сәләтле балалар белән эшләүнең төп максаты - һәр укучының сәләтен, иҗади башлангычын күрү һәм аны киләчәктә үстерү. Мондый укучылар белән эшләгәндә, эзләнергә, яңа мөмкинлекләрдән файдаланырга туры килә.

Олимпиадалар уздыру укучыларның иҗади һәм танып белү сәләтен активлаштырырга, талантлы балаларны ачыкларга мөмкинлек бирә, белем туплау белән кызыксынуны арттыра. Олимпиадаларга әзерләнгәндә, төрле эш алымнары кулланыла. Укытучы белән укучы арасындагы әңгәмәләр, фикер алышулар, тест биремнәрен үтәү, яңа чыккан фәнни китаплар, методик кулланмалар белән танышып, өйрәнеп бару зур әһәмияткә ия. Дәресләрдә бу укучыларга, темаларны үткән вакытта, өстәмә чыганаклардан файдаланырга, иҗади эзләнергә кушыла.

Лицейда укучыларны төрле дәрәҗәдәге олимпиадаларга әзерләүгә зур игътибар бирелә. Мәсәлән; 2013-2014нче уку елларында 29 укучы, 2014-2015нче уку елында 31 укучы район күләмендә үткәрелгән татар теле һәм әдәбияты бәйгеләрендә җиңүгә ирештеләр. 2015-2016нчы уку елында безнең укучыларыбыз республика олимпиадаларында да зур уңышлар яулады. Татар әдәбиятыннан: Миңнегулова Зәринә – җиңүче, Әхметова Эльвина, Минхаерова Диана, Сабанова Алина – призер, укытучылары - Хуҗанбердиева Ч.Т., ә рус төркемнәрендә татар теленнән Лахомова Инна, Андрющенко Елена (җитәкчеләре: Локманова С.Р., Хуҗанбердиева Ч.Т.) призер булдылар.

«Күп белдерүгә караганда, әз белдереп, эзләнү орлыгын салу һәм эзләү юлларын табарга өйрәтү-мөгаллим бирә ала торган хезмәтләрнең иң зурысы», - дигән әдәбият галиме Г.Ибраһимов. Татар теле һәм әдәбияты укытучыларының мөһим бурычларының берсе - укучыларны мөстәкыйль рәвештә иҗади фикер йөртергә һәм нәтиҗә ясарга өйрәтү, укучыларның эзләнү, тикшерену һәм иҗади фикерләү эшчәнлеген активлаштыру. Һәр сыйныфта татар теле һәм әдәбияты фәненнән сәләтле, иҗади фикерләүче бар, ләкин һәркайсына юл табарга, кызыксындырырга гына кирәк. Бу шулай ук

укучыларны фәнни-гамәли конференцияләргә әзерләүнең бер этабы булып тора. Лицейда башлангыч алган С.С.Молодцов исемендәге фәнни-гамәли конференциядә укучылар тәҗрибә туплап, алга таба “Яшьләр-фәнни эзләнүдә”, “Мин - эзләнүче”, Н.И. Лобачевский исемендәге Идел буе фәнни конференциясе, Тукай укулары һәм башка күп бәйгеләрдә катнашып, призлы урыннарны яулыйлар.

Баланың сәләтен дөрес юнәлештә үстергәндә, ул берничә өлкәдә үзенең талантын күрсәтә ала. Укучы баланың тормышын тулысы белән иҗадилык биләп алганда гына талантлар җиңелрәк табыла һәм ачыла.

Сүземне йомгаклап шуны әйтәсем килә: тырышып, үз эшеңне чын күңелдән яратып, вакытыңны кызганмыйча эшләсәң, сәләтле балалар тагын да зур уңышларга ирешәчәк һәм калган укучылар арасында сәләтле балалар саны, һичшиксез, артачак.

## СӘЛӘТЛЕ БАЛАЛАР БЕЛӘН ЭШ ТӘҖРИБӘСЕННӘН

***Галиева Г.И.,***

*ТР Түбән Кама муниципаль районы 35 нче лицейның татар теле һәм әдәбияты укытучысы*



Хәзерге заман шартларында сәләтле балалар белән эшләү системасы зур җаваплылык сорый. Ни өчен дигәндә, һәрбер кеше үзенең мөмкинлекләреннән, кызыксынуларыннан чыгып, үзенә һөнәр сайлый, олы тормыш юлына аяк баса. Без баланың сәләтен никадәр тизрәк күреп алабыз, үстерәбез, уңай шартлар тудырабыз икән, шул очракта гына көтелгән уңышларга ирешә алабыз.

Сәләтле балалар белән эшләү безнең лицей эшчәнлегенең иң мөһим юнәлешләреннән берсе булып тора. Сәләтле балалар һәр мәктәптә дә бар. Без аларны һәрвакыт игътибар үзәгендә тотабыз һәм аларның бу сыйфатларын тагын да үстерергә тырышабыз. Мондый укучылар белән эшләгәндә, эзләнергә, яңа мөмкинлекләрдән файдаланырга туры килә.

V сыйныфтан ук татар теле һәм әдәбияты белән кызыксынган балаларны күреп алырга кирәк. Аларның татарча китаплар укулары аеруча мөһим. Дәресләрдә күренекле шәхесләрне, Бөек Ватан сугышында катнашкан һәм һәлак булган язучыларны, шәхес культы корбаннарын һәм аларның әсәрләрен, тарихи темага багышланган материалларны яхшылап өйрәнәбез. Юбиляр язучылар, шагыйрьләр, хәзерге көн язучылары, шагыйрьләре, драматурглар, аларның әсәрләре турында да мәгълүмат туплыйбыз. Укучылар белән дәресләрдә, дәрестән тыш чараларда, тәрбия сәгатьләрендә үзебезнең данлы, бай тарихлы татар милләте вәкилләре булуыбызны, халкыбызның элекке заманнардан бирле аңлы, белемле, югары мәдәниятле, зур мирaслы булуын аңлатырга, татар халкының данлы, шанлы, олпат кешеләре: Габдулла Тукайлары, Кол Галиләре, Каюм Насыйрилары, Шиһабетдин Мәрҗаниләре барлыгына басым ясап, укучыларда соклану, горурлану хисләре уятам. Милләтебезнең бөек бер милләт икәнлеген, татар халкының башка милләт халыклары белән янәшә торырлык абруйлы, дәрәҗәле, мәртәбәле халык булуын, аның бөек телчеләре: Җамал Вәлиди, Гыйбад Алпаров, Латыйф Җәләйләре, сынчы Бакый Урманче, рәссамнәре Харис Якупов, Эрот Зариповлары, гомумән, дөнья мәдәниятына татар халкы биргән олуг затлары булуына аеруча зур басым ясап игътибар иттерергә кирәк.

Аларга багышлап, укучылар альбомнар эшлиләр, тормыш юлларына, иҗатларына кагылышлы материалларны туплыйлар һәм иҗади эшләрен дәрестә яклыйлар. Мондый эшләрне башкарганда, сәләтле балалар авыр үзләштерүче балаларга ярдәм итәләр. Бу чорда укучыларга грамматик материалны яки әдәбият теориясен артык катлауландырырга кирәкми, ә, бәлки, баланы җәлеп итүнең, кызыксынуларына бәйле рәвештә, яңа ысулларын табу максатка ярашлы булачак. Укучылар белән класстан тыш чараларга әзерләнү, иҗади эшләр башкару, балалар өчен булган газета-журналлар белән хезмәттәшлек итү яхшы нәтиҗә бирәчәк.

Укучыларны, әгәр дә сәләте күренә икән, иҗат эшенә дә тартырга кирәк. Шигырь, әкият, хикәя язган баланың теле дә сафрак, чистарак, образлырак була. Ул, үзе дә сизмәстән, телнең төрле катламнарына үтеп керә. Разил Вәлиев премиясенә яшь иҗатчылар, «Алтын каләм» республика бәйгесе, «Казан утлары» журналы оештырган «Ак җилкән», шулай ук Бөтенроссия «Илһамлы каләм» бәйгеләрендә катнашырга мөмкин. 2013 нче елда «Алтын каләм» республика бәйгесендә минем укучым Газизова Эльза җиңүче дәрәҗәсенә ия булды. 2015 нче елда “Укучыларны шигырь язу серләренә өйрәтү” темасына авторлык программасы яздым һәм бу программа КФУның Алабуга филиалында расланды. Бу программаны дәрестән тыш эшчәнлектә 5-7 нче сыйныф укучылары белән тормышка ашырам. Әлеге укучылар белән төрле шигырь бәйгеләрендә актив катнашабыз.

Олимпиадаларда, төрле бәйгеләрдә катнашучы укучылар белән еш кына фәнни-гамәли конференцияләрдә дә катнашырга була. VII сыйныфка җиткәндә, баланың кайсы якка көчле икәнлеге ачыкланып бетә. Кемдер әсәргә анализ ясарга ярата, кемнедер җөмлә төзелеше җәлеп итә. Конференциягә әзерләнгәндә, шуларга игътибар итәм. Лицей тарафыннан уздырылып килүче С.С. Молодцов исемендәге конференциягә ел саен берничә укучы әзерлим. Мәсәлән, быел катнашкан ике укучымның берсе – Габделбаров Илфат – җиңүче, ә 6 нчы сыйныф укучылары Галимова Адилә һәм Зарипова Илдана 2 нче урынга лаек булдылар. Шулай ук республика күләмендә үткәрелә торган конференцияләрдә дә актив катнашабыз. Мәсәлән, 2013 нче елда Заһиров Айназ "Яшьләр – фәнни эзләнүдә" конференциясендә, Голуб Марина республикакүләм "Кирилл һәм Мефодий фәнни укуларында" призер булдылар. Шәһәребезнең 32 нче гимназиясе үткәрә торган конференциядә дә ел саен диярлек катнашабыз һәм уңышлы нәтиҗәләргә ирешәбез. Укучылар әзерләнү эшен үзләре башкара. Балаларны мондый конференцияләргә катнаштыру кирәк. Ул мондый аралашуларда башкаларны күрә, күп нәрсәгә өйрәнә ала.

Фәнни конференцияләргә әзерләнүнең дә укучылар сәләтен үстерүдә зур әһәмияте бар. Бирелгән тема буенча укучы өстәмә чыганаклардан файдаланып әзерләнә. Үзен кызыксындырган сорауларга җавап эзли. Теманы тулысынча ачып бирү өчен, берничә чыганактан файдалана. Үзенең дәлилләрен берничә галимнең фикерләре белән ачыклый. Монда укучының мөстәкыйль фикер йөртүен, эзләнүен, нәтиҗә ясавын билгеләп үтәргә кирәк.

Сәләтле балалар тәрбияләүдә киң кулланыла торган тагын бер нәтиҗәле чара - сыйныфтан тыш эшләр. Менә шул вакытта бала тулысынча ачыла. Балада теге яки бу темага кызыксыну уянып, әлеге тема буенча укучыда фәнни эш темасын сайлап алу мөмкинлеге туа. Бу чараларда укучы үзен иркенрәк тотарга, укытучы белән якыннанрак аралашырга,үз фикерен курыкмыйча әйтергә өйрәнә. Бары тик сәләтле балалар белән эшләгәндә генә, мөгаллим үзе дә күп нәрсәгә өйрәнә, белемен тирәнәйтә, тәҗрибә туплый. Дәресләрдәге мәгълүмат – белемгә, ә белем күнекмәгә әверелә. Укытучы һәм укучыларда үз көченә ышаныч туа, алар үзләрен туплаган тәҗрибәләре белән көчле итеп сизәләр. Әгәр дә без җәмгыятьнең алга таба үсүен теләсәк, һәр укучының, һәр шәхеснең үсешен тәэмин итәргә тиешбез.

Хәзер мин сезнең игътибарыгызга Г. Тукайга багышланган КВН-викторина тәкъдим итәм.

**Уен-викторина "Тукайны яратабыз"**

**Максат:** Шагыйрь Г.Тукай турында белемнәрне тирәнәйтү; шагыйрь иҗатына, тормышына карата кызыксыну, горурлык хисе тәрбияләү;

телебезгә, әдәбиятыбызга мәхәббәт хисе тәрбияләү;

**Җиһазлау:** Габдулла Тукай портреты, әкият, шигырьләренә ясалган рәсемнәр, аудиоязмада "Туган тел" җыры.

**Викторина барышы.**

**Алып баручы:** Бар күңеллек бөтен дөньяда,
Бар бер ямь бүген:
Нәрсәдән бу?
Мин беләм: бәйрәм бүген, бәйрәм бүген!

Г. Тукайның бу шигъри юллары, нәкъ менә безнең бүгенге кичәбезгә килешеп тора. Кадерле балалар, хөрмәтле кунаклар! Бүген без сезнең белән «Тукайны яратабыз» дип аталган УЕН-ВИКТОРИНАга җыелдык. 21 нче февраль көнне Татарстаныбызда Халыкара Туган тел көне билгеләп үтелә. Ә 26 нчы апрель көнне сөекле шагыйребез Г. Тукайның тууына 130 ел тулды. Безнең яраткан шагыйребез Г. Тукай - татарларның гимнына әверелгән "Туган тел" җырының авторы.

Әйдәгез хәзер без аны тыңлап үтәбез.

***"Туган тел" җыры***

Халкыбызның сөекле шагыйре Г. Тукайның гомере бик иртә өзелә. Әмма аның күркәм образы, әсәрләре халык күңелендә яши. Тукайның шигырьләре бик күп телләргә тәрҗемә ителгән. Ул татар халкының гына түгел, башкорт, казах һәм үзбәк, кыргыз һәм украин халыкларының да яраткан шагыйренә әйләнгән.

Үзенең кыска гына гомеренең һәр минутын Тукай халыкка багышлады. Шагыйрь халык иҗатына, халык теленә – туган телгә тирән мәхәббәт белән карады һәм аның бөеклегенә дан җырлады. Шуңа күрә халкым аны үз җырчысы, үз шагыйре итеп кабул итте.

Бүген безнең 6 нчы б һәм в сыйныфларының татар төркемнәре көч сынашачаклар, алар Г.Тукайны ничек яратуларын, аның тормышын, иҗатын белүләрен күрсәтәчәкләр. Ә кемнең күбрәк дөрес җавап бирүен безгә хәбәр итү өчен, әлбәттә, жюри әгъзалары кирәк.

**Алып баручы:** Әйдәгез, инде командалар белән танышып китик, һәр команда үзенең исемен, девизын әйтә, ә жюри бәя биреп утыра. Беренче сүз 6 Б сыйныф укучыларына бирелә:

*1.* 1 нче команда - **«Шүрәле» командасы**. Капитаны - **Илдана**. **Безнең девизыбыз**:

*2. Без һәммәбез тапкырбыз,*
*Шүрәленең дусты без.*
*Җиңүгә юл табарбыз,*
*Ташка кадак кагарбыз.*

3. 2 нче команда: «**Су анасы».** Капитаныбыз – **Эльвина**. **Девизыбыз:**

*Су анасы балачакның*
*Онытылмас истәлеге.*
*Тукайны сөюебез*
*Безне монда китерде.*

**Алып баручы:** Ә хәзер **беренче бәйге**гә күчәбез. “Табышмак әйтеш” бәйгесе. Мин табышмак әйтәм, ә сез җавабын әйтәсез.:

1) Үземне көтеп алалар, күрендемме, качалар. **(яңгыр, “Яңгыр”)**
2) Туннарга киендерә, җылыта, сөендерә.
Тоягы була ярык, исеме аның - **(сарык, “Кәҗә белән сарык”)**
3) Чуар, йомшак күлмәге, тотсаң, уңа бизәге.
Тоттырмый, китә очып, я кала җирдә посып. **(күбәләк, “Бала белән күбәләк”)**
4) Соскы борын бакылдык, күп сөйләшә такылдык. **(үрдәк, “Үрдәк”)**
5) Кулы юк,балчык ташый, балтасы юк, өй ясый. **(карлыгач, “Карлыгач”)**
6) Нәкъ кеше кебек үзе, маңгаенда - мөгезе.
“Былтыр кысты”,-дип акыра, туганнарын чакыра. **(шүрәле, “Шүрәле”)**
7) Кешенең якын дусты, йортның тугры сакчысы.
Аннан гел игелек көт, ә исеме ничек? **(эт, “Кызыклы шәкерт”)**
8) Җәен соры, кышын ак, аңа шулай яхшырак. **(куян, “Бичара куян”)**

**Алып баручы:** Бу бәйгене дә ерып чыктык, ә хәзер **3 нче бәйге**гә күчәбез. Бу бәйгедә сез аның тормыш юлы һәм иҗатына кагылышлы сорауларга җавап бирерсез.

1. Г. Тукай ничәнче елда һәм кайда туган? (1886 нчы елның 26 нчы апрелендә, Арча районы Кушлавыч авылында)
2. Әти-әнисе үлгәндә аңа ничә яшь була? (әтисе үлгәндә 5 ай, әнисе үлгәндә 4 яшь була)
3. Әтисе үлгәч, әнисе кайсы авыл кешесенә кабат кияүгә чыга? (Сасна авылы кешесенә)
4. Әнисе кияүгә киткәндә, Тукайны асрамага алган карчыкның исеме ничек? (Шәрифә)
5. Әнисе үлгәч, Тукай кайда, кем тәрбиясендә кала? (Өчиледә, Зиннәтулла бабасында)
6. Габдулланы печән базарыннан кемнәр үзләренә уллыкка алалар? (Мөхәммәтвәли һәм хатыны Газизә)
7. Габдулла бу гаиләдән соң кабат кайсы авылга кайта? (Өчиле авылына)
8. Өчиледән соң, кемнәр гаиләсенә эләгә? (Сәгъди абзыйлар гаиләсенә)
9. Сәгъди абзый кайсы авыл кешесе? (Кырлай авылы кешесе)
10. Тукай кайсы авылда бернче тапкыр укырга бара? (Кырлай авылында)
11. Тукайны кемнәр Җаекка (Уральскига) алдыра? (Әтисе белән бертуган Газизә апасы һәм җизнәсе)

**Алып баручы:** Бик яхшы. Шигырьләрен дә беләләр икән! Ә рәсем ясый беләләрме икән?

**4 нче бирем**. Ә хәзер «Шүрәлеләр» тактада «Су анасы»н ясыйлар, ә «Су анасы» командасы «Шүрәле»не ясый.

(Жюри рәсемгә бәя бирә)

**5 нче бирем**. Алып баручы: Ә хәзер инде өй эшегезне тикшереп китик: сезгә өйдә Габдулла Тукайның әкиятләрен сәхнәләштереп килергә кирәк иде.

Шүрәлеләр “Шүрәле” әкиятен, Су аналары “Су анасын” сәхнәләштереп күрсәтә.

**5. Алга таба “Игътибарлымы сез?” бәйгесе**

**Электрон тактада рәсемнәр күрсәтелә, укучылар сорауларга җавап бирәләр.**

1. 1 нче рәсемдә ничә гөмбә үсеп утыра?
2. 2 нче рәсемдә малай аягына нәрсә кигән?
3. 3 нче рәсемдә ничә тычкан сурәтләнгән?
4. 4 нче рәсемдә су анасын ничә эт куа?
5. 5 нче рәсемдә малайны ничә эт куа?
6. 6 нчы рәсемдә ничә мендәр өелгән?

**6. Сүз ясауда ярышу.**

Габдулла Тукай сүзендәге хәрефләрдән сүзләр төзү һәм командаларның бер-берсенә сүзләр әйтешүе.

**7. Йомгаклау.** Ә хәзер викторинабызга нәтиҗә ясар өчен сүзне жюрига бирәбез.

**А. Б.** Шуның белән, укучылар, безнең бәйрәмебез ахырына якынлашты. Әйтегез әле, без бүген Г. Тукаебыз турында нинди белемнәребезне кабатлап киттек? Нәрсәләрне кабат искә төшердек?

Бәйгебездә, һәрвакыттагыча, дуслык җинде.

## ГИМНАЗИЯДӘ ДӘРЕСТӘН ТЫШ ЭШЧӘНЛЕКНЕ ОЕШТЫРУ

***Минһаҗева Алинә Фәнис кызы,***
*Бакый Урманче исемендәге 2 нче гимназиянең милли мәгариф директор урынасары*

"Өйрәнү – тәрбия дигән чәчәкнең бер таҗы, монда барысы да мөһим – дәрес тә, дәрестән тыш эшчәнлектә балаларның һәрьяклап кызысынуы да, тәрбияләнүчеләрнең коллективта үзара аралашуы да"

*В.А.Сухомлинский.*



Безнең гимназиядә гомуми белем бирүнең федераль дәүләт стандартының икенче буыны (ФГОС) тормышка ашырылу дәвам ителә. Анда дәрестән тыш эшчәнлек мәҗбүри компонент булып тора. Бу яңалык безнең укучыларның сәламәтлеген арттыруда ярдәм итәргә тиеш. "Дәрестән тыш эшчәнлек" балаларның яшь үзенчәлекләрен исәпкә алып төзелергә һәм үткәрү формасы буенча укытуның дәрес системасыннан аермалы булырга тиеш. Физик тәрбия дәресләрендә алган күнекмәләр, белемнәр укучының мөстәкыйльрәк формадагы эшчәнлегендә ныгытылырга тиеш. Мәсәлән; иртәнге зарядка, саф һавада хәрәкәтле уеннар, физминуткалар, дәрестән тыш өстәмә шөгыльләр вакытында. Башлангыч сыйныфта физик тәрбия гомуми үсеш бирүче хәрәкәт эшчәнлеге белән тыгыз бәйләнгән. Башлангыч класс укучысында хәрәкәтле уеннар, шөгыльләр вакытында физик сыйфатлар гына түгел, акыл, иҗади мөстәкыйльлек тә үсеш ала.

Гимназия эшчәнлеге тулысынча шәхескә, аны формалыштыруга юнәлтелгән. Шәхесне формалаштыру турыдан-туры укытучыга, аның педагогик һәм методик осталыгына бәйле. Укытучы эшчәнлегенең төп юнәлешләренең берсе – дәрестән тыш чараларда да укучыга шәхес итеп карау, аның сәләтен күрә белү, аны үстерүгә ярдәм итү, иҗади баскычка күтәрү. Укытучы дәрестән тыш эшләрдә үз укучысын күбрәк ача, аларның мөмкинлекләрен, сәләтләрен күрә. Шунлыктан игътибарны татар теле һәм әдәбияте дәресләренә генә түгел, ә дәрестән тыш эшләргә дә юнәлтелә.

Класстан тыш эшләр исеменнән үк күренгәнчә, дәрес кысаларына бикләнмәгән, әмма шул ук вакытта балаларның белемен дә, зиһенен дә үстерә торган, аларның гамәли шөгыльләренә, зәвыкларына, сәләт мөмкинлекләренә уңай тәэсир иткән, әлеге файдалы чараларның һәммәсен ял һәм төрле уеннар белән бергә бик тә оста бәйли алган тәрбия сәгатьләре ул. Һәр укучының үзенчәлекле характерын, омтылышын, нәрсәләргә сәләте барлыгын ачыклау өчен, иң беренче чиратта, аның белән мәктәптән һәм дәресләрдән тыш вакытларда аралашырга, тәрбия эшен шул рәвешле дәвам итә белергә кирәк. Мондый чараларны үткәрүдә, гадәттә, укытучылар үзләре дә, ата-аналар да, мәктәпкә шефлык итә торган оешма вәкилләре дә катнашырга мөмкин. Тик шунысы бик тә мөһим: укучыларның мәктәптә тыш тәрбия сәгатьләрендә үз эшен, үз һөнәрен яхшы белгән, тәрби эшенең барлык нечкәлекләрен тирән тойган кешеләр катнашырга тиеш.

Уку-укыту процессының бу мөһим ягы укучы шәхесен формалаштыру җәһәтеннән дә нәтиҗәле чара булып тора, чөнки класстан тыш эшләрдә катнашу, бердән, ихтыяри булса, икенчедән, укучыларга мөстәкыйльлек һәм иҗади активлык күрсәтү өчен дә зур мөмкинлекләр тудыра. Күп очракта нәкъ класстан тыш эшләрдә укучылар үзләрен ныграк танытталар. Дәрес кысалары, дәресләр өчен кабул ителгән катгый тәртипләр (парта арасында гына утыру, сөйләү өчен укытучы чакырганын көтү, һәрчак билге куелу мөмкинлеге, тынлык саклау, укытучының гына җитәкчелек роле, чикләнгән вакыт, ягъни, дәрес ялыктыргыч булса да, 45 минут үткәнен көтү һәм, кызык үтсә дә, шуңа риза булу һ.б) яшүсмергә хас булган хәрәкәтчәнлек, кызыксыну, барысына да онытылып катнаша алу мөмкинлеге табу, шаяру-көлешү кебек гаять кирәкле эмоциональ ихтыяҗларның тәэмин ителүенә кайбер киртәләр тудыра. Нәтиҗәдә, дәрестә укучының мөмкинлекләре ачылып бетерелмәскә мөмкин. Дөресен әйтергә кирәк: соңгы елларда татар телен укыту кыенлашканнан-кыенлаша бара. Яшьләр күбрәк физика, математика, техника өлкәсендәге белемнәр белән кызыксына, рус, инглиз телен өйрәнергә тырыша. Болар – тормыш агымы, фән-техника революциясе, җәмгыять үсеше нәтиҗәләре.

Димәк, укытучыга, дәресләрне сыйфатлы һәм нәтиҗәле итеп алып бару өстенә, класстан тыш эшләргә дә зур өметләр бagларга туры килә: мәктәп балаларында туган телгә мәхәббәт, аны өйрәнүгә кызыксыну тәрбияләү һәм тирәннән белергә, омтылыш тудыру; сөйләшкән һәм язган чакта һәр әйтелгән һәм язылган сүзең өчен җаваплылык хисе тоярга күнектерү; туган тел турында күп белү, аны олылауның, фикерне аңлаешлы, күңелдәге хисләрне матур һәм үтемле итеп әйтеп бирә белүнең һәрбер культуралы кеше өчен зарури икәнлеген төшендерү.

Класстан тыш эшләр юнәлешенә килсәк, үткәрелгән чараларыбыз да милли тәрбия үсешенә омтылып башкарыла. Бу максаттан һәрберебез вакытлы матбугатны, радио-телевидение тапшыруларын, килгән киноспектакльләрне карау һәм әңгәмә оештыру кебек чараларны куллана. Төрле яшьтәге укучылар белән үткәрелгән һәм ел саен үткәрелә торган “Көзге уңыш”, “Сөмбелә”, “Нәүрүз”, “Озын толым”, “Сабантуй”, “Нәсел шәҗәрәсе”, “Әти, әни һәм мин – спорт яратучы гаилә” һ.б. чаралар нәкъ менә милли гореф-гадәтләребезгә нигезләнеп, алардагы нәфислекне, күңел сафлыгын, әдәп –тәрбия дәрәҗәсен аңлату, кире кайтару максаты белән эшләнә.

Татар теленнән класстан тыш эшләр, нигездә, дәрес алдына куелган белем һәм тәрбия, бирү мәсьәләләрен чишүне күз алдында тоталар, һәм аларның төп максаты – укучыларда туган телне тирәнрәк өйрәнү, аның байлыкларыннан мөмкин кадәр тулырак файдалануга омтылыш тудыру. Шуның өчен дә укытучы, класстан тыш эшләрне оештырганда, укучыларга күбрәк гамәли тормышта кирәк булган күнекмәләрне бирергә тырыша: тиешле темага материаллар тупларга куша, сүзлекләрдән файдаланырга өйрәтә, укучылар ата-аналар алдында һәм радио яки скайп аша чыгыш ясыйлар; стена газетасы чыгарыла, күрсәтмә материаллар ясала, стендлар һәм күргәзмәләр җиһазлана, кичәләр, конкурслар үткәрелә.

## ТЫЛСЫМЛЫ СУ

*(дәрестән тыш эшчәнлек )*

***Хәкимова Лидия Хәсәншәеховна,***
*Бакый Урманче исемендәге 2 гимназиянең*
*беренче квалификацион категорияле башлангыч сыйныф укытучысы*



**Максат:**

1. Экологик белемнәр аша сөйләм телен үстерү;
2. Су турында белемнәрне туплау, суны рәссам, кешенең дусты, байлык, гүзәллек төшенчәләре белән бәйләү;
3. Парлап, төркемнәрдә эшләү алымнарын ныгыту;
4. Күзаллау, бәйләнешле сөйләм телен үстерү, сүзлек запасын баету;
5. Сөйләм телен үстерүдә халык авазы иҗаты әсәрләрен куллану;
6. Табигатькә, әйләнә-тирә мохиткә сакчыл караш тәрбияләү, үзара дустанә мөнәсәбәтләр тәрбияләү

**Эшчәнлек төрләре:** төркемнәрдә эшләү, фронталь эш, әңгәмә, шәхси карточкаларда эш, уен һәм иҗади эш алымнары.

**1.Уку эшчәнлегенә мотивация.**

- Хәерле көн, укучылар һәм килгән кунаклар!!!

Бүгенге дәрестән тыш эшчәнлегебезне табышмаклар әйтешүдән башлыйбыз.

1. Үзе су, үзе каты. (боз)
2. Ак ашъяулык таптык,
Җир өстенә яптык. (кар)
3. Җиде сөлге җиде төстә,
Җидесен дә элдем күккә. (салават күпере)
4. Сикереп төшә,бозны тишә. (тамчы)
5. Җәйге эссе көннәрдә,
Мине сагынып көтәләр.
Мин аз гына күренсәм
Качып -посып бетәләр. (яңгыр)
6. Йолдыз-йолдыз вак кына
Ак мамык сымак кына.
Өс киемеңә куна,
Тәнгә тисә, су була. (кар)

- Җавапларны тагы бер кат укып чыгыйк әле.
- Бу җавапларны нәрсә берләштерә?

- Су.

**2. Эшләп карауда туган шәхси кыенлыкларны ачыклау һәм актуальләштерү.**

- Димәк бүгенге дәрестән тыш эшчәнлек темасын аңлагансыздыр инде.

Бүген без нәрсә турында сөйләшәчәкбез?

-Су турында.

-Балалар, карагыз әле. Белмәмештән хат килгән. Укыйк әле.

**“ Исәнмесез, балалар! Мин бер көнне китаптан су турында шундый сүзләр укыдым. Су - рәссам. Су - гүзәллек. Су - байлык. Су - кешенең дусты. Ләкин мин бернәрсә дә аңламадым. Булышыгыз, зинһар!”**

- Булышабызмы соң?
- Әйе.

**3. Кыенлыкларның урынын һәм сәбәбен ачыклау.**

- Белмәмеш нинди сүзләрне аңламаган?
- Су - Рәссам, Байлык, Гүзәллек, Кешенең дусты.

| | |
|---|---|
| Рәссам | ? |
| Байлык | ? |
| Гүзәллек | ? |
| Дус | ? |

- Ә сез бу сүзләрнең мәгънәсен аңлыйсыйзмы сон?
- Юк.

**4. Кыенлыктан чыгу проектын төзү.**

- Димәк, безнен бүгенге дәрестән тыш **эшчәнлекнең максаты** ничек була инде?
- Бирелгән сүзләрнен мәгънәләрен ачу.
- Ә соңыннан булган белемнәребезне Белмәмешкә тапшырырбыз.
- Ә сез су турында нәрсәләр беләсез? Әйдәгез әле булган белемнәребезне кабатлыйк.
- Суны табигатьтә кайларда очратырга мөмкин?

| | | |
|---|---|---|
| ЕЛГА | ДИҢГЕЗ | ЧИШМӘ |
| САЗЛЫК | ИНЕШ | ОКЕАН |
| СУЛЫК | | |

**5. Төзелгән проектны тормышка ашыру.**

СУ-РӘССАМ.

-Кем сон ул рәссам?
- Художник, рәсем ясаучы, бизәкләр төшерүче…
- Ә су ничек инде рәссам була алсын?
- Кыш көне табигатьтә кайларда матур рәсемнәр күрергә мөмкин?
- тәрәзәдә
- кар бөртекләре
- Экранга карагыз әле, ниди матур бизәкләр төшерелгән.

СУ – ГҮЗӘЛЛЕК.

- Гүзәллек сүзен ничек аңлыйсыз? Икенче төрле ничек әйтеп була?
- Матурлык, чибәрлек....
- Экранга карагыз әле, нинди матур күренешләр!
- Суның роле монда нинди?
- бәсләр
- сыннар
- үсемлекләрдә чык тамчылары

СУ – КЕШЕНЕҢ ДУСТЫ.

- Кем соң ул дус?
- Якын кеше, авыр вакытта ярдәм итүче.
- Күз алдыны китерегез әле, өйдә бер көн су булмаса, нәрсә булыр икән?
- юына алмыйбыз
- өйне җыештыра алмыйбыз
- ашарга пешереп булмый
- киемнәр пычрак була

- Су безгә шулай ярдәм итә.

СУ – БАЙЛЫК.

- Байлык сүзен ничек аңлыйсыз? (Акча)
- Су – ул байлыкмы?
(Байлык,чөнки су булган жирдә матурлык, яшәеш бар)
- Ә су акча бирә алмый бит.
- Су безгә нәрсәләр бирә?
(үсемлекләр,балыклар, тоз,яңгыр)
Хәзер эшне төркемнәрдә дәвам итәбез. Һәр төркемдә конверт, эчендә алгоритм, алгоритм буенча эшлибез

**1 төркем.**

СУ – РӘССАМ

1. Кар бөртекләре кисү.
2. Плакатка беркетү.

- Кар бөртеге нинди?

Матур
Алты таҗлы
Салкын
Вак

- Бик матурлар. Бик яхшы, тырышып эшләгәнегез күренә.

**2 төркем**

СУ – ГҮЗӘЛЛЕК.

-Бирелгән күлне матурларга. Чәчәкләр, камышлар белән.
- Ә сез үзегездә шундый матур әйберләрне ясый аласызмы?
-Менә мин берничә үрнәк ясадым, карагыз әле, матур ясалганмы?
- Өйдә үзегезгә дә ясап карарга киңәш итәм.

**3 төркем.**

СУ – КЕШЕНЕҢ ДУСТЫ.

- Әйе, балалар, сусыз без 1 көн дә тора алмыйбыз. Ул безгә һәрвакыт кирәк.

Су – безнең дустыбыз дибез, ә без аны саклый беләбезме соң?

-Карточкаларда бирелгән җөмләләрнең дөресен генә сайлап алыгыз, аерым биткә ябыштырыгыз. Эмблемалар ясагыз.

1. Суга ни теләсәң, шуны ташларга ярый.
2. Елга-күлләрне пычратырга ярамый.
3. Елгага чүпләр ташларга ярамый.
4. Елгага пыяла, тимер кисәкләре ташларга ярый.
5. Елга буенда чүп-чар калдырырга ярамый.
6. Өйдә краннарны ябып йөрергә кирәк.

Тикшерү

СУ – БАЙЛЫК.

- Әйтегез әле, сулыклар нинди байлыклар бирә?

Бу сорауга җавапны үзегез табарсыз. Конвертта рәсемнәр бар,шулар арасыннан артык предметларны алып куегыз. Плакатка ябыштырыгыз.

| | | |
|---|---|---|
| ТОЗ | КУРЧАК | БАЛЫК |
| ДӘФТӘР | ДИҢГЕЗ КӘБЕСТӘСЕ | КРАБ |

Тикшерү – экран буенча, 4 рәсем кала.

**6. Белемнәрне системалаштырып кабатлау.**

- Димәк, җир йөзендә иң кыйммәтле нәрсә булды инде?
- Су.
- Белмәмешнең сорауларына җавап бирә алдыкмы инде?
- Суның гүзәллек, рәссам, байлык, кешенең дусты дигән төшенчәләрне ача алдыкмы инде?
- Балалар, бәс, су ничек кар бөртегенә, тәрәзәләрдәге бизәкләргә әйләнәләр, әвереләләр икән? Уйлап караганыгыз юкмы? Киләсе дәресләрдә шул сорауларга җаваплар әзерләрбез.

**9. Дәрестә уку эшчәнлегенә рефлексия.**

- Бүгенге дәрестән тыш эшчәнлеккә бирелгән план буенча нәтиҗә ясыйк.

| | |
|---|---|
| МИН | УЙЛАНДЫМ. |
| МИНЕ | КЫЗЫКСЫНДЫРДЫ. |
| МИНА | ОШАДЫ. |
| МИН | ТУРЫНДА УЙЛЫЙМ. |

## Х. ТУФАННЫҢ ТУУЫНА 115 ЕЛ ТУЛУГА БАГЫШЛАНГАН

***“Кулыңдагы китабымда, чордаш,***
***Шигырьләрдә минем йөрәгем,”*** – дип исемләнгән әдәби-музыкаль кичә *(дәрестән тыш эшчәнлек).*

***Зарипова Әнисә Газизулла кызы,***
*Бакый Урманче исемендәге 2 гимназиянең югары квалификацион категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы*



**Тема:**

**Максат:** 1. Х. Туфанның тормыш юлы, ачы язмыш сынавының шигъриятендә, җырларында чагылышын, һәр чорны иңләгән, тематикасы буенча гаять лирик эчтәлекле шигырьләрендәге төп идеяне тамашачыга җиткерү.

2. Х.Туфанның “Халык рухының илчесе”, татар поэзиясенең горурлыгы икәнен укучыларга төшендереп, иҗатына карата олылау, хөрмәт һәм мәхәббәт хисләре уяту.

3. Балаларда сәнгатьле сөйләм, сәхнәдә үзеңне тоту күнекмәләре үстерү.

**Җиһазлау:** “Кулыңдагы китабымда, чордаш,
Шигырьләрдә минем йөрәгем”, – дигән плакат, мультимедия, Х.Туфанның портреты, язучының тормыш һәм иҗат юлын чагылдырган фотосурәтле слайдлар, Х.Туфанның тормышын һәм иҗатын чагылдырган мәгълүматлардан торган газеталар.

**Кулланылган әдәбият:**

1. Х.Туфан Сайланма әсәрләр. Казан: Татарстан Республикасы “Хәтер” нәшрияты (Тарих), 2002.
2. Х.Туфан лирик шигырьләр. Казан: Татарстан китап нәшрияты, 198.5
3. Х.Туфан Гүзәл гамь. Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1990, һ.б. китаплары.

**Әдәби-музыкаль кичәнең барышы.**

1 а.б.

- Исәнмесез, хөрмәтле кунаклар, укучылар, укытучылар! Х.Туфанның тууына 115 ел тулуга багышланган әдәби-музыкаль кичәбез язучының тормыш һәм иҗат юлына багышлана.

- Ничек икән синең йөрәк? – дисең,
Ничек икән гомер көннәрең?
Кулымдагы китабымда, чордаш,
Шигырьләрдә минем йөрәгем.

2 а.б

- Ничек икән йөрәк тибешең? – дисә
Хәлне сорап әгәр берәр кем
Гасырдашлар, сезнең үзегез биргән
Җырларымда минем йөрәгем.

Х.Туфанның “Яшьлек килә яшәргә” шигыре башкарыла. (Курайда “Тәфтиләү” көе уйнала.)

1 а.б.

- “Х.Туфан искиткеч намуслы, иманлы, кешелекле шагыйрьләрнең берсе иде”, – дип язды аның турында Сибгат Хәким. Нәкъ Тукайча халыкның язмышын уртаклашкан, аның чын мәгънәсендә йөрәге аша үткәргән Туфан. Нәкъ Такташча яңа хисләр белән, зур идеаллар белән рухланган, аның якын дусты булган Туфан.

2 а.б.

- “Иҗат – гүзәл гамь ул, иң югары дәрәҗәдәге изге тынгысызлык ул. Иҗат ике канатлы: яхшыны исбат итү, яманны инкарь итү, яхшылыкка мәхәббәт, яманлыкка нәфрәт ул!” – дип, иҗатка шулай бәя бирә Х. Туфан.

Х.Туфан сүзләре, Сара Садыйкова музыкасы “Казан кичләре” җыры башкарыла.

1а.б.

- Яшьлек, иҗат, мәхәббәт дөньясында кайнап яшәгән Х.Туфанга ил язмышының кара җилләре дә килеп кагыла. “Ант” поэмасында сурәтләүләре өчен, сәяси гаепләр ташлана. Х.Туфан 15 ел гомерен тоткынлыкта үткәрергә мәҗбүр була.

2 а.б.

- Бередә дә ул җан дусты - поэзиядән аерылмый - тоткын шагыйрьнең кичерешләрен сурәтләгән шигырьләр иҗат итә.

Х.Туфанның “Кайсыгызның кулы җылы?” шигыре башкарыла.

1 а.б.

Туфан шигырьләрендә йөрәгеннән ургылып чыккан моң, сагыш, шатлык хисләрен чагылдыра.

2 а.б.

Туфан – мәхәббәтнең олылыгына, тугрылыкка дан җырлаучы моң, сагыш чишмәсе.

Х.Туфан сүзләре “Юксындырсаң, нишләрмен” җыры башкарыла

1а.б.

- Шагыйрь Туфан һәм артистка Луиза Салиаскарованың таң калырлык легендага әйләнгән мәхәббәте авыр сынауларга да сынмаслык тугрылыкка нигезләнгән.

2 а.б.

- Иренә тугры калып, аның соңгы тамчы канына кадәр көрәшкән Луизаның Туфан лирикасы үлемсезлегендә өлеше шагыйрьнең үзенеке кебек зур. Туфан драмасы хатынына багышланган шигырьләр циклында үзенең иң тирән кичерешләре белән ачыла, өзгәләнүле хисләр, кайтарып булмаслык югалту тойгысының шагыйрь җанын телгәләве Таһир-Зөһрә мәхәббәтенә тиң сөюнең кайнарлыгын, зурлыгын дәлилли.

Х.Туфан белән Луиза Салиаскарованың бер-берсенә булган шәфкатьлелеге, мәхәббәте ”Тамчылар ни диләр?” шигырендә сурәтләнә.

Х.Туфанның “Тамчылар ни диләр?” шигыре башкарыла.

1 а.б.

- Хәсән-Луиза сөюенең таң калырлык зурлыгы, мәхәббәткә өлге булырлык ихласлыгы XXI гасыр яшьләренә гыйбрәт алырлык дәрәҗәдә. Бары тик чын ярату, ихлас тугрылык кына кешене кеше итә, онытылмас истәлекләр белән баета – шагыйрьнең фаҗигале мәхәббәт тарихы әнә шуны раслый.

2 а.б.

- Мәхәббәт турында язганда кешенең йөрәк хисләре, табигый моң шигъри юллардан саркый башлый, әле хис җырларында ачык чагыла.

Х.Туфан сүзләре, Ә.Бакиров музыкасы “Әйткән идең…” җыры башкарыла.

1 а.б.

- Шагыйрьнең тоткынлык чоры 1940-1956 нчы елларга туры килә. Бөек Ватан сугышы чоры. Х.Туфан үзенең иле өчен сугышта катнаша алмавын бик авыр кичерә.

2 а.б.

- Үз халкын ярату, киләчәккә ышанычлы булу, туганнарының һәм якыннарының күңел җылысын тою, күңелдә туган хисләрен шигырь юлларына салу аның рухын сындыра алмаган.

Х.Туфанның “Сугыш” шигыре башкара.

1 а.б

- Х.Туфан Г.Тукайны – татар галәмендә иң якты йолдыз дип саный һәм шигырияте аша гүя ки Г.Тукай белән сөйләшә, киңәш-табыш итә, аны олылый.

2а.б.

- Х.Туфан Г.Тукай кебек туган телебез, аның алдагы язмышы турында уйлана.

Х.Туфанның “Чәчәкләр китерегез Тукайга” шигыре башкарыла.

- Без бөек шәхесләребез турында уйлыйбыз да: “Алар каян көч алган? – дип әйтеп куябыз. Ул көч – халыкта, туган җирдә, туган телдә, халык моңнарында.

2 а.б - Иң җылы хисләр, иң матур тойгылар татар җырлары, татар моңнары аша безнең күңелләребезгә үтеп керә. Туфанның туган телгә, туган җиргә багышланган җырлары бер бәйләм.

Татар халык җыры “Сарман”

1 а.б

- Төп нигезем минем Татарстан,
Синең язмыш, безнең гомерләр.
Төп нигезем, аерма син мине
Әткәм-әнкәм биргән телемнән.

2а.б

- И минем җандай, кадерлем,
И җылы, тере телем!
Кайгылар теле түгел син,
Шатлыгым теле бүген.

Х.Туфанның “Туган тел турында җырлар” шигыре башкарыла.

Татар халык биюе “Печәндә”.

1 а.б.

Һәр галимнең,
Һәр шагыйрьнең сүзе
җитсен иде

һәрбер күңелгә,
Җилләр, сулар тавышы шикеле үк,
Үзләренең асыл телендә.

Х.Туфан турында Гомәр Бәширов болай ди: “Шагыйрьләр турында сүз чыкканда, гадәттә, поэзия өчен яши, диләр. Х.Туфанны исә мин, ул үзе шигырь булып яши, дияр идем. Чөнки Туфанны – шигърияттән, шигырьне Туфаннан башка күз алдына китерү мөмкин түгел. Ул - шигъри образга, шигърият дөньсына гашыйк кеше. Шигырьнең теләсә нинди киртәләрне җимерерлек тылсымлы көче барлыгына Туфан кебек чын күңелдән ышанган башка кешене белмим”.

2 а.б

Шагыйрь “Шагыйрьләр, әдипләр күңеле киеренке кыллы арфаны хәтерләтә. Тормыш аның тере, җанлы, сизгер кылларына бармак очы белән аз гына кагыла да яңгырый башлый”, – дип яза. Бу сүзләр шагыйрьнең үзенә туры килә, ул гомере буе халык тормышындагы вакыйгаларны, йөрәге аша кичереп иҗатында яңгырата.

- Хөрмәтле, мөхтәрәм кунаклар, сөекле укытучыларыбыз, кадерле укучылар Х.Туфанның тууына 115 елга багышланган әдәби-музыкаль кичәбез тәмам. Игътибарыгыз өчен рәхмәт!

## ТЕМА: ӘКИЯТЛӘР ИЛЕНӘ СӘЯХӘТ

*(дәрестән тыш эшчәнлек)*

***Петрунина Нәзилә Рәсим кызы,***
*Бакый Урманче исемендәге 2 гимназиянең беренче квалификацион категорияле башлангыч сыйныф укытучысы*



**Максат:** Балаларның әкиятләр турында булган белемнәрен искә төшерү, ныгыту, тирәнәйтү.

**Бурычлар:** 1.Әкиятләр белүнең әһәмиятенә төшендерү.

2. Балаларның иҗади хыялларын үстерү, сөйләм байлыкларын арттыру, балаларның туган телдә матур, дөрес, сәнгатьле итеп сөйләүләрен булдыру.

3. Әкиятләрнең нигезендә акыллылык, тапкырлык, зирәклек кебек сыйфатлар ятканына төшендерү.

4.Әкиятләр аша балаларда әхлак сыйфатлары тәрбияләү, бер-береңне хөрмәт итәргә, дус, тату булырга өндәү, китап уку, белем алуга кызыксыну хисләре уяту, балаларның әкиятләр белән кызыксынучанлыгын үстерү.

**Эшчәнлек төрләре:** әңгәмә, фронталь, иҗади һәм төркемнәрдә эш.

**Эшчәнлек барышы.**

**1. Оештыру моменты. Уку эшчәнлегенә мотивация.**

*Әкрен генә музыка уйный.*

Хәерле көн, кадерле балалар, килгән кунаклар. Исәнмесез! Кәефләрегез ничек, әйбәтме?

Сез игътибар белән тыңларга, тулы җаваплар бирергә әзерме? *(Балаларның җаваплары)*

Әйдәгез әле, бер-беребезгә карап елмаешабыз, уңышлар телибез, тыныч кына утырышабыз. (*Бер - берләрен сәламләү)*

**2.Эшләп караудa туган шәхси кыенлыкларны ачыклау һәм актуальләштерү.**

Бүгенге шөгыльнең девизы: Тырышлык булса, уңышлар да булыр!

Уңыш булсын өчен ничек эшләргә кирәк соң?

Ә хәзер игътибар белән барыбыз да экранга карыйбыз. *Музыка уйный, сихри мизгел тудырыла. “Әкияттә кунакта” дан өзек күрсәтелә, бераздан туктый. Мин сөйли башлыйм.*

Борын-борын заманда яшәгән, ди, булган, ди, бер бабай белән әби. Аларның булган, ди, бик матур кызлары. (сөйләүдән туктыйм )

- Балалар, менә шушындый матур, тылсымлы сүзләр белән нәрсәләр башланып китә әле? (әкиятләр)

- Әкиятләр тагын нинди сүзләр белән башланырга мөмкин соң? *(җаваплар)*

Бик дөрес, яшәгән, ди, булган, ди, әүвәл заманда һәм башка шундый сүзләр белән әкиятләр башланып китәләр.

**3. Кыенлыкларның урынын һәм сәбәбен ачыклау.**

Балалар, сез ничек уйлыйсыз, ә ни өчен әкиятләр нәкъ менә шундый матур сүзләр белән башлана икән ул? *(балаларның фикерләре тыңлана)*

- Әйе, бик дөрес, әкиятләр безне тылсым дөньясына алып керәләр, кызыксындыралар. Шулай бит.

- Димәк, безнең бүгенге шөгыльнең темасы ничек яңгырар икән?

- Әкиятләр иленә сәяхәт.

Димәк, нәрсәләр турында сөйләшербез икән?

- Әкиятләр турында сөйләшербез.

Ә шөгыль барышында нәрсәләр эшләрбез дип уйлыйсыз? *(әкиятләр укырбыз, ә бәлки, рәсем ясарбыз)*

- Ә шөгыльнең максаты: әкиятләр турында булган белемнәрне искә төшерербез, ныгытырбыз, әкиятләр дөньясына чумарбыз.

**4. Кыенлыктан чыгу проектын төзү.**

- Балалар, ә сез әкиятләр яратасызмы? *(әйе)*

Әйе, бала кечкенәдән үк әкиятләр тыңлап, әкиятләр укып үсә.

Әкиятләрне безгә кемнәр сөйли, кемнәр укый соң?

- Бик дөрес, әби-бабайлар, әти-әниләр, абый- апалар.

Балалар, ә хәзер игътибар белән мине тыңлагыз. Мин һәр төркемгә әкиятнең бер өзеген укыйм, ә сез кайсы әкияттән икәнлеген белергә тиешсез. Беренче өзек - беренче төркемдәге балаларга. Алар уйлашалар, үзара фикерләшәләр. Аннан соң төркемдәге бер бала экраннан дөрес әкиятне сайлап ала. *(ТАКТАДА КҮРСӘТӘЛӘР!!!)*. Алар белмәсәләр, башка төркем балалары җавап бирә.

<u>1 нче өзек - 1 нче төркемгә:</u> Беркөнне куян үзенең кызына өр-яңа киез итекләр алып кайтып биргән. Мә, бәбкәм, аякларың туңмасын, сызламасын, дигән. Бу кайсы әкияттән өзек? “*Куян кызы” әкиятеннән.*

<u>2 нче өзек - 2 нче төркемгә:</u> Бик авырта кулларым, дустым, җибәр, зинһар, җибәр. Шүрәлене рәнҗетүдән нәрсә бар сиңа, ни бар? “*Шүрәле” әкиятеннән.*

<u>3 нче өзек - 3 нче төркемгә:</u> Як-ягымда һич кеше юклыгын белдем дә мин, чаптым авылга, таракны тиз генә элдем дә мин.... “*Су анасы” әкиятеннән*

<u>4 нче өзек - 4 нче төркемгә:</u> Тиен тәрәзә шакыган чагында, кече кызның камыр баскан чагы булган. Ул камырлы кулларын да сөртеп тормаган, чыккан да әнисе янына йөгергән. И сөекле бала, дигән тиен.... “*Өч кыз” әкиятеннән*

- Булдырдыгыз, балалар.
- Ә сезнең әкият тыңлыйсыгыз киләме?
- Менә тыңлагыз әле, мин сезгә бер кызык әкият сөйлим.

Борын-борын заманда,<br>
Булган, ди, бер патша,<br>
Ул ясаттырган, ди,<br>
Би-и-ик матур бер бакча.<br>
Бакчаның коймасы,<br>
Булган ди таштан,<br>
Сөйлимме кире баштан? *(әйе, әйе)*

- Юк, балалар, мин шаярттым гына. Бүген мин сезгә әкият сөйләмим. Без бүген барыбыз бергәләп әкиятләргә багышланган кечкенә проект эше эшләп китәрбез.

Һәрбер төркем үзенә бирелгән әкиятнең эчтәлеген, аның геройларын искә төшереп проект эше эшли. Сезнең өстәлләрдә кирәкле материаллар бирелгән. *(Ак кәгазь бите, клей, төсле карандашлар, ә конверт эченә әкиятнең геройлары һәм исеме салынган.)*

Сез иң башта әкият геройларын игътибар белән тикшереп чыгасыз, ә аннан соң әкиятнең исемен туры китерәсез, ягъни дөрес исемен табасыз. Менә шушы ак кәгазь битенә дөрес, билгеле бер тәртиптә әкият геройларын ябыштырасыз. Иң мөһиме, геройларның тәртибен бутамагыз.

- Балалар, эшне башлаганчы, без сезнең белән төркемнәрдә эшләү кагыйдәләрен искә төшереп китәрбез. *(Кагыйдәләр слайдта чыга, тактада эленеп тора.)*

1. Төркемдә җаваплы кеше булырга тиеш.
2. Төркемдә һәрбер бала да эшләргә тиеш.
3. Бер кеше сөйли, ә калганнар тыңлый.
4. Үз фикереңне әдәпле итеп әйт.
5. Аңламасаң кире сора.

Шулай итеп, төркемдәге балалар барысы да эшли. Эшне бүлешеп аласыз, кем нәрсә эшли, кемгә булыша. Эшне тәмамлагач, һәрбер проект эшен төркемнән бер бала менә бу тәртип буенча яклый. *(тәртибе слайдта чыга)*

1. Әкиятнең исеме.
2. Төп геройлар кемнәр?
3. Әкият безне нәрсәгә өйрәтә?

Сезнең белән бергә шөгылебез кунаклары да бераз эшләп алырлар. Алар үзләре белгән әкиятләрне онытып бетермәделәр микән? Алар өстәлендә дә кирәкле материаллар бар. Проект эшен эшләү өчен сезгә 7 минут вакыт бирелә. Рәхим итеп эшне башлагыз.

1 нче төркем - Йомры икмәк

2 нче төркем – Сертотмас үрдәк

3 нче төркем – Шалкан

4 нче төркем – Теремкәй.

*(Кунаклар өчен Шалкан һәм Теремкәй әкияте буенча материаллар бирелә)*

Эшли башлыйлар, 5 минуттан соң әйтәм:

- Балалар, вакыт 2 генә минут калып бара.
- Бик яхшы, булдырасыз. Эшләрне төгәлләргә кирәк. Сезнең вакытыгыз бетте. *(Вакыт бетте дигәч сөйләшмибез, өстәлдә тәртип булдырабыз, җавап бирергә әзерләндек). (Кунакларның проектын барып алам!!!)*

**5. Төзелгән проектны тормышка ашыру.**

Хәзер, үзләренең проект эшен яклар өчен, сүзне 1 нче төркем укучыларына бирәбез. *(Бала сөйли)*

-Рәхмәт. Бик яхшы.

-2 нче төркем балаларына бирәбез.

- 3 нче төркем балаларына.

Бик яхшы, балалар. Ә менә бу проект - “Шалкан” әкияте буенча безнең кунакларыбыз эше.

4 нче төркем балаларына сүз бирәбез.

- Булдыргансыз, балалар. Ә менә бу эш тә “Теремкәй” әкияте буенча –кунакларыбыз эше.
- Рәхмәт, балалар, кунакларга да рәхмәт.

**6. Сөйләмдә әйтеп карап, беренчел ныгыту.**

Менә карагыз әле, нинди матур әкияти проектлар килеп чыкты бит. Без сезнең белән бергәләп искиткеч матур эшләр эшләдек. Сез минем белән килешәсездер бит? *(балаларның җаваплары)*

- Ә ни өчен шундый матур эшләр килеп чыкты соң, сез ничек уйлыйсыз?

- Әйе, чөнки без бер-беребезне тыңлап, киңәшләшеп, дус, тату эшләдек. Барлык төркемнәр дә шулай эшләде микән? *(төркем җитәкчеләре үз эшләренә бәя бирәләр)*

- *Азат, менә сиңа аеруча кайсы проект ошый һәм ни өчен?*

*Мансур, ә син аеруча кайсы эшне мактап китәр идең? Чөнки чиста. Матур итеп эшләнгән....*

**7. Рефлексия.**

Тормышыбызда бик күп матур әкиятләр бар безнең. Язучылар һәм төрле милләт халыклары безгә шундый матур әкиятләр язып калдырган.

- Ә сез ничек уйлыйсыз, хәзерге вакытта да әкиятләр иҗат ителә микән? *(әйе, юк)*

Балалар, киләсе шөгыльләрнең берсендә без сезнең белән нәкъ шул турында сөйләшербез, ягъни үзебез әкият иҗат итеп карарбыз.

- Балалар, әкият безне нәрсәгә дә булса өйрәтә. Әкиятләрдәге кебек дус, тату булыгыз. Шөгыльдә алган белемнәрегез алдагы тормышыгызда сезгә ярдәм итсен.

- Шөгыль тәмам. Сау булыгыз.

## ӘНИЛӘР КӨНЕ

**(дәрестән тыш эшчәнлек)**

**Хәйруллина Рәмзия Әхәтовна,**

*Бакый Урманче исемендәге 2 нче гимназиянең югары квалификацион категорияле башлангыч сыйныф укытучысы,*

**Сабитова Альбина Хәнифовна,**

*Бакый Урманче исемендәге 2 нче гимназиянең беренче квалификацион категорияле башлангыч сыйныф укытучысы.*





**1 алып баручы:** Әни, әнием, әнкәй! Кадерләп назлап әйтәбез, күңелебездәге бөтен рәхмәтне шушы гади сүзгә салабыз, һәрвакыт яныбызда булган, уңышларыбыз өчен шатланып, кайгыларыбызны уртаклашып яшәгән газиз әниебезгә дәшәбез.

**1 укучы** Балагызның берәве сез,
Гаиләнең йөрәге сез,
Иминлекнең терәге сез.
Һәркемнең кирәге сез.

**2 укучы** Сез чаялар, сез батырлар
Сез дөньяда иң матурлар.
Сез булганга тормыш ямьле,
Сез булганга яшәү гамьле.

**2 алып баручы**: Хәерле көн, безнең өчен иң кадерле кунакларыбыз - әниләребез ! Сезне барыгызны да бүгенге бәйрәм - Әниләр көне белән тәбрик итәбез!

**Концерт номеры: "Целую твои руки" җыры.**

**3 алып баручы:** Бәйрәмнең кайсы да тәнгә җиңеллек, рәхәтлек, җанга ял бирә. Шушы бәйрәм көне күңелегезгә шатлык, тәнегезгә сихәтлек, өегезгә иминлек алып килсен.

**1 алып баручы:** Тормышларыгыз матур, йөзләрегез көләч булсын, сәламәтлек һәрдаим юлдашыгыз булсын.

**3 укучы**: Ана назы - җирдә ул мәңгелек,
Мәңгелек жыр - бишек жырыгыз.
Без узасы юлда маяк булып
Гомер буе балкып торыгыз.

**4 укучы:** На свете добрых слов немало,
Но всех добрее и важней одно:
Из двух слогов простое слово: «мама»
И нету слов дороже, чем оно.

**5 укучы:** Без сна ночей прошло немало,
Забот, тревог не перечесть.
Земной поклон вам все родные мамы
За то , что вы на свете есть !

**6 укучы**: Елмайса, йөзеннән аңлыйм
әнкәемнен теләген.
Дөнья кинлегенә тиңлим
әнкәемнен йөрәген.

**7 укучы**: Әнкәй, сина бүләк итәм
Бөтен дөнья гөлләрен.
Юллар кебек озын булсын,
әнкәем, гомерләрең.

**8 укучы**: Ай нурыннан да нурлырак
әнкәемнен йөзләре.
Монлы көйдәй күңелемдә
әнкәемнен сүзләре.

**9 укучы:** Айдан, кояштан кадерле - син ул, әнием.
Иң ягымлы, иң сөйкемле - син ул, әнием

**2 алып баручы:** Слова Мама, мать - одни из самых древних на Земле. Все люди уважают и любят матерей. Словом «Мать» называют и свою Родину, чтобы подчеркнуть, что она по-матерински относится к своим детям. Во многих странах отмечается «День Матери». Люди поздравляют своих матерей и приезжают к ним в гости, дарят подарки, устраивают для них праздник. И мы сегодня собрались здесь, чтобы поздравить своих мам.

**3 алып баручы:** Мәхәббәте һичбер киртәләрне белми торган, күкрәк сөте белән хәят биргән… ананы олылыйк! Дөньяның бөтен матурлыгы анада. Анадан башка шагыйрь дә, анадан башка батыр да булмый.

**1 алып баручы:** Бүген әйтеләсе теләкләребез, җыр, биюләребез – барысы да чын йөрәктән, күңелебезнең иң - иң түреннән - сезнең өчен. Кабул итеп алыгыз, рәхәтләнеп тыңлагыз, ял итегез.

***Концерт номеры:*** скрипкада уйнау

**2 алып баручы**: Әнием! Әнкәем! Синнән дә якынрак, кадерлерәк кем бар соң дөньяда?! Күкрәк сөтен имезеп, көнен-төнгә, төнен-көнгә ялгап, күз карасыдай үстерәсең бит син балаларыңны.

**3 алып баручы:** Мама! Мамочка! Сколько тепла таит это магическое слово. Материнская любовь греет нас до старости. Мама учит нас быть мудрыми, дает советы, заботиться о нас, оберегает нас.

Младенец старательно складывает по слогам «Ма-ма» и, почувствовав удачу, смеется счастливый.

Мама! Вслушивайтесь, как гордо звучит этот слово! В народе живет много добрых слов о матери.

**При солнышке - тепло , при матери – добро.**

**Ана өчен баладан газиз нәрсә булмас.**

**Нет лучшего дружка, чем родная матушка.**

**Баланың бармагы авыртыр, ананың йөрәге авыртыр.**

**10 укучы:** Әйе, Ана – бөек исем,
Нәрсә җитә ана булуга!
Шуңа күрә
Зур горурлык белән
Без сөйлибез АНА турында.

**Концерт номеры: "Иң матур җыр" җыры**

**11 укучы**: Ана күңеле кебек җылы, нурлы
Күк йөзендә кояш, йолдыз юк.
Ана сөюе кебек чиксез тирән
Җир йөзендә һичбер диңгез юк.

**1 алып баручы**: Синең өчен кайгыртучы әниең булуы нинди зур бәхет ул. Аны ярату гына җитми, аның кадерен белергә, сүзен тыңларга, яхшы укуың, үзеңне үрнәк тотуың, эшкә өйрәнеп үсүең белән аны шатландырырга кирәк.

**12 укучы:** Люблю тебя мама, за что не знаю.
Наверно за то, что дышу и мечтаю.
И радуюсь солнцу и светлому дню,
За это тебя, я родная люблю.
За небо, за ветер, за воздух вокруг.
Люблю тебя мама, ты лучший мой друг!

**2 алып баручы:** Алексей Максимович Горький писал: «Без солнца не цветут цветы, без любви нет счастья, без женщины нет любви, без матери нет ни поэта, ни героя. Вся радость мира - от матерей!.»

Если вы хотите сделать маму самым счастливым человеком, поступайте так, чтобы она радовалась и гордостью могла сказать: «Знаете, какие у меня хорошие дети!»

**13 укучы**: Бер ягымда – әтием,
Бер ягымда -әнием.
Уңымда да, сулымда да
Таянычым бар минем.

**14 укучы:** Канатлар кирәк түгел
Пар атлар кирәк түгел.
Аякларым җиргә тими
Очар кош минем күңел.

**15 укучы:** Бала гына димәгез,
Сүзләремнән көлмәгез.
Күз яшенә, кайгыларга
Берүк мине бирмәгез.

**16 укучы:** Бер ягымда - әтием,
Бер ягымда - әнием.
Уңымда да, сулымда да
Яклар кешем бар минем.

**17 укучы:** Ана булу - изгелекнең тажы,
Дөньяда иң олы дәрәҗә.
Ана кеше һәрбер баласының
Бәхетенә ача тәрәзә.

**18 укучы:** Ана сиңа гел яхшылык тели,
Гаепләрең булса - кичерә..,
Турылыклы калыйк гомер буе
Ана дигән күркәм кеше.

***Концерт номеры: "Мамочка милая, мамочка моя" җыры***

**3 алып баручы:** Мама! Самое понятное слово на земле. Оно звучит на всех языках мира одинакого нежно. У мамы самые ласковые и нежные руки, они все умеют. У мамы самое доброе и чуткое сердце. Оно ни к чему не остается равнодушным. И сколько бы ни было человеку лет 5 или 50, ему всегда нужна мама…

**2 алып баручы:** Руки мамы качали детей в колыбели, когда они были маленькими. Это мама согревала их своим дыханием и убаюкивала своей песней.

**Солнца ярче для меня - мама!**
**Мир и счастье для меня - мама!**

**Шум ветвей, цветы полей - мама!**
**Зов летящих журавлей - мама!**
**В небе яркая звезда-мама!**
**19 укучы:** Пусть звенят повсюду песни
Про любимых наших мам.
Мы за все, за все родные
Говорим «Спасибо Вам!»
**Концерт номеры:** курайда уйнау
**20 укучы:** Пусть день твой будет
Солнечным, прекрасным.
И розами твой будет устлан путь.
И каждый вечер – звездным,
Чистым, ясным.
**21 укучы**: Газиз әнкәй!
Иң сөйкемле сүзләр - синеке!
Йомшак, җылы куллар - синеке!
Иң-иң татлы сүзләр - синеке!
Жан изрәткеч җырлар - синеке!
**22 укучы:** Синсез дөнья күрмәс идек, Синсез берни белмәс идек,
Синсез берни кылмас идек,
Синсез кеше булмас идек!

**1 алып баручы:** Пусть этот день станет своеобразным днем благодарения нашим дорогим и любимым мамочкам, за их неоценимый труд, за их всемогущую любовь.

**2 алып баручы:** Чәчәк букетлары бүләк итсәк,
Чәчәк букетлары корыр ул.
Йөрәк җылыбызны бүләк итсәк,
Югалтмассыз, мәңге торыр ул.
Ходай Сезгә җан тынычлыгы, тән сихәтлеге, озын гомер насыйп итсен.
Мең-мең рәхмәт Сезгә, кадерле әниләр!

**3 алып баручы:** Мы еще раз поздравляем Вас, милые мамы! И пусть не покидает вас терпение, которое такнеобходимо сейчас вам всем. И пусть все восхищаются вашей красотой. Ведь вы - самое прекрасное, что есть. Бәйрәм белән!

**Концерт номеры:**Җырлы бию “Мама, будь всегда со мною рядом”

## ФОНЕТИКА ҺӘМ ОРФОЭПИЯ
## 5 нче сыйныф татар сыйныфы

***Ибраһимова Эльмира Гомәр кызы,***
*31 нче мәктәпнең I квалификацион категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы*



**Тема**: Фонетика һәм орфоэпия иленә сәяхәт

Максатлар:

1. **Белем бирү максаты (предмет нәтиҗәсе):** Фонетика, орфоэпия буенча үткәннәрне гомумиләштереп кабатлау.
2. **Үстерү максаты (метапредмет нәтиҗәсе):** Укучыларның белемнәрен тикшерү, мөстәкыйль эшләү күнекмәсен булдыру.
3. **Тәрбия бирү максаты (шәхси нәтиҗәләр):** Туган телгә аңлы мөнәсәбәт тәрбияләү.

**Дәрес тибы**: Белемнәрне тигезләү аша үзбәя кую дәресе.

**Материаллар:** Татар теле: Татар урта гомуми белем бирү мәктәбенең 5 нче сыйныфы өчен дәреслек/ Р.А. Юсупов, К.З. Зиннәтуллина, Ч.М. Харисова, Т.М. Гайфуллина, - Төзәтелгән һәм тулыландырылган дүртенче басма. – Казан: Мәгариф, 2009.- 159 б.


**Җиһазлау**: мультимедиа аппараты, карточкалар, үзбәя кую өчен битләр, кульяулык.

**Дәрес барышы:**

**I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру этабы**
1. Уңай психологик халәт тудыру
2. Белемнәрне тигезләү

а) Фонетика фәне нәрсәне өйрәнә?
б) Орфоэпия фәне нәрсәне өйрәнә?
в) Авазларны без язуда ничек күрсәтәбез?
г) Авазлар нинди ике зур төркемгә бүленә?
д) Татар алфавитында ничә сузык һәм тартык аваз бар?
е) Татар алфавитында ничә хәреф бар?
ж) Нәрсә ул сингармонизм?
з) Нәрсә ул иҗек?
Әйдәгез тикшерик, зиһен сандыгынданиләр бар икән?
Әдәп төбе-............... (тел)
Тел-.......................... (Түмәнгә илтә)
7 кат үлчә,................ (1 кат кис)
Һөнәрле үлмәс,................... (һөнәрсез көн күрмәс)
Кем эшләми,....................... (шул ашамый)
Яңа мәкаль өстендә эш: Кешенең белемен сүзеннән аңларсың.
**Үзбәя**
3. Уку мәсьәләсен кую:

Укучылар ярдәмендә тактада модель төзибез:




- Модель бенча өйрәнмәгән тармакны ачыклагыз.

Көтелгән җавап: Без барлык тармакларны да өйрәндек, димәк, бүген кабатлау дәресе, ягъни *белемнәрне системага салу дәресе* була.

**II. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Фонетика һәм орфоэпия иленә сәяхәт.
Укытучы: Укучылар, без бүген фонетика һәм орфоэпия иленә сәяхәт кылырбыз
1. Сәяхәтнең маршруты белән танышу:
- Фонетика шәһәре
- Авазлар тавы
- Сингармонизм урманы
- “Йолдызчык” кафесы (физкультминутка)
- Тартыклар сазлыгы
- Иҗек чишмәсе
- Орфоэпия шәһәре




2. Сәяхәткә чыгу.
Табышмакның җавабын табу.
Дүрт тәгәрмәчле әрҗә,
Үзе зур көчкә ия.
Олы юлдан йөгерә,
Максатка тиз җиткерә. (Автобус.)
- Димәк, без автобуста сәяхәт итәчәкбез. Юлга кузгалыйк, дуслар!

**Бирем 1. ФОНЕТИКА ШӘҺӘРЕ**
- Фонетика сөйләм авазларын өйрәнә. Авазлар ничек күрсәтелә? ([ ])
Түбәндәге сүзләрдәге авазларны күрсәтергә.
Яшьлек, мәктәп, болыт, туганкай
- Барлык хәреф тә аваз белдерәме? Аваз һәм хәреф составлары туры килмәгән очраклар бармы? Мисаллар китерегез.
**Нәтиҗә 1**: Барлык хәрефләр дә аваз белдерми.
**Үзбәя**.

**Бирем 2. АВАЗЛАР ТАВЫ**
- Авазлар нәрсә ярдәмендә ясала?
- Нинди авазлар тавышлы дип аталалар? (сузык авазлар)
- Нинди авазларны шаулы диләр? (саңгырау тартыкларны)
- Нинди авазлар ясалганда, тавыш та, шау да катнаша? (яңгырау тартыклар)
**“Кайсы артык?” уены**.

Бирелгән төркемнәрдән артык авазларны табарга, ни өчен артык булуын аңлатырга.
I в. – [б], [к], [м], [з], [ж], [а], [ш]. (сузык)
II в. – [ф], [с], [л], [п], [х]. (яңгырау тартык)
**Нәтиҗә 2:** Авазларны әйткәндә, сөйләм органнары катнаша
**Үзбәя**
**Бирем 3. СИНГАРМОНИЗМ УРМАНЫ**

- Сингармонизм нәрсә ул? (Сузыкларның, бер-берсенә йогынты ясап, үзара охшашланулары сингармонизм яки сузыклар гармониясе дип атала.)
- Аның нинди төрләре бар? (I төре – сузыкларның калынлыкта-нечкәлектә ярашуы, II төре – иренләшү күренеше.)

**“Кайсы артык?” уены.**
Сингармонизм законын истә тотып, бирелгән сүзләр арасыннан артык сүзне табарга.
I в. – шәһәр, ишек, йөзем, чана, чәчәк. (сингармонизмның 2 нче төренә карый)
II в. – томан, үгез, кылыч, рәсем, китап. (сингармонизм законына буйсынмаган)
**Нәтиҗә 3:** Сузыкларның, бер-берсенә йогынты ясап, үзара охшашланулары сингармонизм яки сузыклар гармониясе дип атала




**Үзбәя**
**“Йолдызчык” кафесы**
Физкультминут
**Бирем 4. ТАРТЫКЛАР САЗЛЫГЫ**
- Тартыклар нинди төрләргә бүленәләр? (яңгырау, саңгырау)
1) [к]-[къ], [г]-[гъ] авазлары язылган сигнал карточкалары ярдәмендә эшләү.
Бирем: укытучы әйткән сүздә булган авазны сигнал карточкасы ярдәмендә күрсәтергә. Әгәр 2 аваз булса, икесен дә күрсәтергә.
Кыйммәт, кеше, көймә, карга, гомер, тәнкыйть, зәгыйфь, дикъкать, гөмбә, кәгазь, китап, җәмгыять, кагыйдә, гасыр, гөл, гадәт.
**Үзбәя.**
**Бирем 5. ИҖЕК ЧИШМӘСЕ**
- Иҗек нәрсә ул? (иҗек - әйтелешнең иң кечкенә кисәге)
- Иҗекләрнең нинди төрләре бар? Мисаллар әйтегез. (ачык һәм ябык иҗекләр була)
- Татар телендә басым гадәттә кайсы иҗеккә төшә? (соңгы)

Сүзләне иҗекләргә бүлегез, төрен әйтегез.
Дан-
Аерма-
Аваз-
Бакчачылык-
Өлеш-
Авылдашларыбыз-
Ефәк-
Туп-




**Үзбәя.**
**Бирем 6. ОРФОЭПИЯ ШӘҺӘРЕ**
- Сүзләрне дөрес әйтергә орфоэпия өйрәтә.

Фонетик зарядка.
Зәңгәр, казан, кымыз, һава, шәһәр, гөнаһ, чиләк, мәчет, күмәч, дәү, адым, съезд, хәтер, ахыр, оҗмах, тәэмин, Коръән, җир, гаҗәп.
Төшеп калган хәрефләрне куй:

| | |
|---|---|
| (һ,х) | (н,ң) |
| ил.ам | иртә.ге |
| бә.ет | мә.ге |
| әйкәл | ча.гы |
| ава | боры.гы |
| мә.әббәт | бәрә.ге |
| әзер | |

**Нәтиҗә.**
**Үзбәя.**

Фонетик анализ тәртибен искә төшерү.

**III. Рефлексия**

- Без бүген нәрсәгә өйрәндек?
- Ничек кабатладык?

**Дәрескә үзбәя.**

**Өй эше**. 1. Гомер, дикъкать сүзләренә фонетик анализ ясарга.
2. Карточкаларда төшеп калган хәрефләрне куеп язарга.
3. “Фонетика илендә сәяхәт” темасына әкият язып килергә.

## ИЯРЧЕН ТӘМАМЛЫК ҖӨМЛӘ
### 8 нче сыйныф

***Ганиева Рузилә Фәвәдис кызы,***
*31 нче мәктәпнең I квалификацион категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы*



**Максатлар:**

**Белем бирү максаты (предмет нәтиҗәсе):**

- иярчен тәмамлык җөмлә төшенчәсе өстендә эш;
- “Җөмлә кисәкләре”, “Иярченле кушма җөмлә”, “Иярчен җөмләләрнең төрләре” темалары буенча белемнәрне камилләштерү;

**Үстерү максаты (метапредмет нәтиҗә):** мөстәкыйль һәм төркемнәрдә эшли белүләрен, үз-үзләренә бәя куя белү, ярдәмлекләр белән эшләү күнекмәләре өстендә эшләү.

**Тәрбия бирү (шәхескә юнәлдерелгән нәтиҗә):**

- татар теленә уңай мөнәсәбәт тәрбияләү.

**Материал:** М.З. Зәкиев авторлыгындагы дәреслек, мультимедиа системасы, чигүле кулъяулык.

**Дәрес тибы:** уку мәсьәләсен кую һәм чишү.

**Дәрес барышы:**

**I. Ориентлашу - мотивлаштыру этабы.**

***Җилкәнеңне җилләр екса, йөрәгеңне җилкән итеп күтәр. Нинди генә очракта да җиңәргә өйрән. Көчле рухлылар гына максатларына ирешәләр.*** **(Ф. Яруллин)**

**- Укучылар, сез бу сүзләрнең авторын, һичшиксез, беләсез. Ничек аңлыйсыз сез аларны?**

Көтелгән җавап: Ничек кенә авыр булса да, без куйган максатыбызга ирешергә тиеш. Бүгенге тормышта бу бик кирәкле сыйфат. Без моңа кечкенә вакыттан ук, мәктәп елларыннан өйрәнәбез. Авыр темалар өйрәнгәндә дә, начар билгеләр алганда да, без төшенкелеккә бирелергә түгел, ә киресенчә, тагын да тырышыбрак өйрәнергә тиеш.

Дәреснең бу минутлары халкыбызның бөек шагыйре, Г.Тукай һәм М.Җәлил исемендәге премияләр лауреаты, драматург, язучы, публицист һәм, гомумән, көчле рухлы чын кеше Ф.Яруллинның якты истәлегенә багышлана.

**1. Өй эшен тикшерү.**




1 нче вариант - стандартлар буенча кагыйдәләрне белергә,

2 нче вариант – 87 нче күнегү,

3 нче вариант – схемалар буенча җөмләләр төзергә.

[] : ( )


[шунда, (шул), (шундый)] : ( ).

**Үзбәя.**

**2. Укучыларның белемнәрен тигезләү. Төркемнәрдә эш.**

I төркем **иярчен ия җөмлә турында модель төзеп сөйли,**
(экрандагы модель белән чагыштырып, дәреслеге тикшерелә, бәяләнә)

II төркем **иярчен хәбәр җөмлә турында модель төзеп сөйли,**
(экрандагы модель белән чагыштырып, дәреслеге тикшерелә, бәяләнә)




III төркем **җөмләгә анализ ясый һәм синонимик вариантларын яза.**

***1)*** ***<u>Теләге бартик тормас</u>. (М.)***

*(* *)*[]. Иярчен җөмлә – синтетик ия җөмлә.

Синоним вариантлары :

***Кемнең <u>теләге бар, шул тик тормас</u>.***

Ivтөркем **җөмләгә анализ ясый һәм синонимик вариантларын яза.**

1) ***<u>Хикмәт шунда</u>: 2)аларның бай җирләрне <u>кулларыннан ычкындырасылары килми.</u> (Г.Б.)***

[шунда]: ( ). Иярчен җөмлә – аналитик хәбәр җөмлә.

Синоним вариантлары :***1) <u>Хикмәт шунда ки</u>, 2)аларның бай җирләрне <u>кулларыннан ычкындырасылары килми.</u>***

***2)*** ***<u>Хикмәт</u> аларның бай җирләрне <u>кулларыннан ычкындырасылары килмәүдә.</u> (гади җөмлә)***

**Үзбәя**

- Алия, (Нияз, М.Нияз, Раил) ничәле куйдың?

- *Мин “бишле” куйдым, чөнки үзем җавап бирдем (хатам юк).*

- *Мин “дүртле” куйдым, чөнки китапка, кагыйдәләр җыентыгына карадым. (хата бар).*

- *Мин “өчле” куйдым, чөнки миңа ярдәм кирәк.*

**Зиһен сандыгында ниләр бар? (“Кульяулык” уены)**

Сорауларга җавап.

- Иярчен җөмләләрнең мәгънәләре буенча тагын нинди төрләре бар?

(иярчен тәмамлык, иярчен аергыч, иярчен хәл (аның 8 төре бар), иярчен аныклагыч).

- Алар нинди җөмлә кисәкләре белән тәңгәл килә?

( иярчен кисәкләр белән: тәмамлык, аергыч, хәл, аныклагыч)

- Шулардан искә төшереп китик әле, тәмамлык нинди сорауларга җавап бирә?

(Тәмамлык – килеш сорауларына һәм кем белән? нәрсә белән? кем турында? нәрсә турында? сорауларына җавап бирә )

**Үзбәя**

**1.** **<u>Укучылар белән берлектә уку максатын кую.</u>**

- Без тәмамлык турында беләбез, ә иярчен тәмамлык җөмлә турында нәрсә беләбез соң? (Сорауларын әйтергә мөмкиннәр)

- Димәк, без бүген **иярчен тәмамлык җөмләләр** турында өйрәнәчәкбез.

*( Дәфтәрләрдә число, тема языла).*

- Иярчен җөмләләрнең төрен билгеләү өчен, без нишлибез?

(Сорау куябыз, бәйләүче чараларын табабыз, баш җөмләгә мөнәсәбәтен билгелибез).

- Хәзер мисаллар өстендә эшләп карыйк инде.

II. **Белемнәрне адымлап үзләштерү этабы.**

*3.* *Уку максатына ирешү өчен яңа теманы өйрәнү алгоритмын төзү.*

***1)*** **<u>Кем сораса</u>, 2)шуңа <u>сатарга тора</u>. *(Г.И.*)** җөмләсе ярдәмендә

- Җөмләнең хәбәрлек үзәген табып, чикләрен билгелибез.
- Бәйләүче чараларны табып күрсәтәбез.
- Баш җөмләне табып, иярчен җөмләгә сорау куябыз.
- Схеманы төзибез, иярчен җөмләнең төрен билгелибез.

(кем), [шуңа]. И.ж. – аналитик тәмамлык җөмлә.

- Баш җөмләгә мөнәсәбәтен билгелибез. Баш җөмләдәге мөнәсәбәтле сүз белән бирелгән тәмамлыкны ачыклый.

***1)Сез <u>килгәнгә</u> 2)<u>без</u> бик <u>шат</u>.***

- Җөмләнең хәбәрлек үзәген табып, чикләрен билгелибез.
- Бәйләүче чараларны табып күрсәтәбез.
- Баш җөмләне табып, иярчен җөмләгә сорау куябыз.
- Схеманы төзибез, иярчен җөмләнең төрен билгелибез.

(-гә), []. И.ж. – синтетик тәмамлык җөмлә.

- Баш җөмләгә мөнәсәбәтен билгелибез. Баш җөмләнең тәмамлыгын ачыклый.

**Нәтиҗә:**И.т. җөмлә нәрсәгә? соравына җавап бирә, төзелеше буенча төре синтетик, б.ч. булып юнәлеш килеше кушымчасы килә, тыныш билгесе куелмый.

*Уку максатына ирешү өчен күнегүләр системасы.*

**Бирем 1**. Төркемнәрдә эшләү.

I төркем: 1) Күрде Гази**: 2)**яр инде әллә кайда калган. (М.Х.)

II төркем: 1) Игенчеләр 2) чәчү беткән**не** 1) хәбәр иттеләр.

III төркем: 1 )Без беләбез **ки,** 2) Тукай – милләтебез горурлыгы.

IV төркем: 1) Алдагы уку елына аны 2) Хәрби Академиягә җибәрәбез **дип 1**) кисәтеп куйганнар иде.

**Нәтиҗә:** Сораулары: кемгә? нәрсәне? нәрсә дип? һ.б.;

Бәйләүче чаралары: парлы мөнәсәбәте сүзләр, көттерү паузасы,

килеш кушымчасы, **ки** теркәгече, **дип** бәйлек сүзе;

Төзелеше буенча: аналитик һәм синтетик;

Баш җөмләгә мөнәсәбәте: я б.ж-нең тәмамлыгы урынында килә,

я мөнәсәбәтле сүз белән бирелгән тәмамлыкны ачыклый;

Тыныш билгеләре: өтер, ике нокта. Кагыйдәләре әйтелә.

**Үзбәя**

**Бирем 2**. Шушы нәтиҗәгә таянып, теманың моделен төзибез. Төркемнәрдә эш.

4. Модельне төркемнәрдә төзиләр,
5. бер-берсенә сөйлиләр (парларда эш)

Модель

**Иярчен тәмамлык җөмлә**

**Сораулары: Төзелеше буенча: Бәйләүче чаралар: Тыныш билгеләре**
**кемне? Аналитик мөнәсәбәтле сүзләр, өтер,**
**нәрсәне? Көттерү интонациясе, ике нокта**
**кемгә? *ки* теркәгече**
**нәрсәгә? синтетик юнәлеш, төшем килеше кушымчалары,**
**нәрсә дип? *дип* бәйлек сүзе**
**Баш җөмләгә мөнәсәбәте:**
**я баш җөмләнең тәмамлыгы урынында килә,**
**я баш җөмләдәге мөнәсәбәтле сүз белән бирелгән тәмамлыкны ачыклый.**
**Үзбәя**
**Бирем 3. Парларда эш. 94 нче күнегү (бирем буенча)**
**Нәтиҗә.**
**Үзбәя**

**III. Рефлексия. Үз-үзең белән сөйләшү. 5 мин.**

1. Бирелгән схема буенча төркемнәрдә сөйләшү:

- Иярченле кушма җөмләләр турында кабатладым.
- Иярчен тәмамлык җөмлә турында - белдем.

**2. Дәрескә үзбәя**

3. **Өй эше**. (Вариантлап, сайлап алу мөмкинлеге белән бирелә)

1) программа буенча эш: кагыйдәне кабатларга;

2) программа материалын иҗади куллануга эш (ярымиҗади эш): 94 нче күнегү

3) Иҗади эш: **Мин автобус килгәнне озак көттем.**

**Минавтобус килүен озак көттем.**

Бирелгән җөмләләрне анализлап, аермалары нәрсәдә икәнен күрсәтергә.

## 21 НЧЕ ФЕВРАЛЬ – ХАЛЫКАРА ТУГАН ТЕЛ КӨНЕ

***Чевачина Розалия Вакыйф кызы,***
*29 нчы мәктәпнең татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

Туган телдә җырлый чишмә,
Туган телдә шаулый таллар.
Туган телдә дәшсәм генә,
Туган җирем мине аңлар.

21 нче февраль – Халыкара туган тел көне. Тарихка күз салсаң, беренчеләрдән булып Халыкара туган тел көнен билгеләп үтү теләге белән Бангладеш Республикасы чыга. Анда 1957 нче елның 21нче февралендә, туган телдә белеем алу хокукын даулап, биш студент һәлак була. 2000 нче елда Берләшкән Милләтләр Оешмасы, ЮНЕСКО инициативасын хуплап, күптеллелекне яклау йөзеннән, 21 нче февральне "Халыкара туган тел көне" итеп үткәрү турында карар кабул итәләр.

Татарстанда да туган телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү юнәлешендә зур күләмле эш алып барыла.




Безнең Түбән Камабыз да бу чаралардан читтә калмый. Беренче тапкыр Халыкара туган телләр көне Түбән Кама шәһәренең Илдус Харис улы Садыков исемендәге "Балалар һәм яшьләр сарае"нда үткәрелде. 2015 нче елда бу бәйрәм тантанасы шәһәребезнең 2 нче номерлы татар гимназиясендә уздырылды. Ә быел бу матур традицияне 29 нчы мәктәп дәвам итте.

Мәктәпкә аяк басуга, кунакларны гармун моңы, курай аһәңе, укучыларыбызның елмаюлары каршы алды, бәйрәмгә килгән халык күтәренке рух, яхшы кәеф белән мәҗлесләр залына юл алды.

Тантаналар залы янында оештырылган милләтләр почмагы искиткеч зәвыклыгы белән, җанга ятышлыгы белән җәлеп итте. Һәр милләт вәкиле үз халкының күренекле шәхесләрен, истәлекле урыннарын, милли киемен һәм ризыгын тәкъдим итте.



Бәйрәмне милләт өчен җан атып йөрүче, яшь талантларга юл күрсәтүче, төпле киңәшләрен бирүче директорыбыз Шакиров Равис Мөҗәһит улы ачып җибәрде. Укытучылар коллективы башкаруында яңгыраган "Ты Россия моя!" җыры залны чын дәрәҗәсендә дулкынландырды. Мөгаллимнәр хорында дистәдән артык ир-егет катнашуы, күпләрне гаҗәпләндерде дисәк тә, артык булмас.

Бәйрәмебезнең төп кунаклары - Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты вәкилләре, мәгариф идарәсе җитәкчеләре, «Аксакаллар» шурасы әгъзалары, "Кама таңнары" әдәби берләшмәсе әһелләре халыклар дуслыгына кагылышлы фикерләрен тамашачыларга җиткерделәр. Түбән Камабызда эшләп килүче Халыклар дуслыгы йорты җитәкчесе Хафизов Васил Фаиз улы үзенең чыгышында туган телләрне саклап калуда милли җәмгыятьләрнең күп хезмәт куюларын ассызыклады, аларга зур рәхмәт белдереп, уңышлар һәм эшләренең дәвамлы булуын теләде.

Тантанада катнашучы кунаклар арасында Татарстан Республикасының танылган сәнгать эшлеклесе, Абдулла Алиш исемендәге премия лауреаты, балалар шагыйрәсе Шәрәпова Йолдыз Әдип кызының булуы ямь өстенә ямь өстәде.

Бәйрәмдә шәһәребезнең 11 милләт вәкиле җитәкчесе катнашты, һәр милләт әһеле тамашачыларга үзенең чыгышын тәкъдим итте. Татар, рус, әзербәйҗан, үзбәк, чуаш биюләре белән берләттән, кунакларыбыз таҗик, немец, керәшен, әрмән җырларын тыңлап ләззәтләнделәр. Украин телендә яңгыраган шигырь шулай ук беркемне дә битараф калдырмады. Ә "Башкорт җәмгыяте берлеге" оешмасы җитәкчесе Хәсәнов Гали Әхтар улының милли уен коралларындагы чыгышын тамашачылар көчле алкышларга күмделәр.

Бәйрәмебезнең мөхтәрәм кунагы - Бөтендөнья татар конгрессының Түбән Кама муниципаль районы бүлеге рәисе, шәһәр советы депутаты, “Шинник” спорткомлексы директоры Ганиев Рөстәм Мәҗит улы эчкерсез чыгышы белән тамашачыларны үзенә җәлеп итте. Рөстәм Мәҗит улының чыгышыннан соң Татарстан дип аталган уртак йортыбызда бергә дус һәм тыныч тормыш итүнең зур бәхет икәнлегенә тагын бер кат инандык.

Алдагы көннәребездә дә бергә - бергә, иңгә - иң куеп, дус - тату яшәргә язсын, һәр туган таңыбыз безгә иминлек, шатлык алып килсен!

Төп нигезем минем – Татарстан,
Синең язмыш – безнең гомерләр.
Төп нигезем, мине аерма син,
Әткәм - әнкәм биргән телемнән.

## РАЗИЛ ИСМӘГЫЙЛЬ УЛЫ ВӘЛИВ ПРЕМИЯСЕНӘ ЯШЬ ЯЗУЧЫЛАР БӘЙГЕСЕ

***Гәрәева Гөлчәчәк Шәрәфетдин кызы,***
*Кама Аланы 1 нче мәктәбенең милли мәсьәләләр буенча директор урынбасары*



Классик язучыбыз Аяз Гыйләҗевнең: «Яхшы кешенең даны күпләрне бик озакка кадәр, кайчагында гомер буе җылытып килә», дип язып калдырган юллары бар. Якташыбыз, халык шагыйре, күренекле дәүләт һәм җәмәгать эшлеклесе Габдулла Тукай бүләге иясе Разил Исмәгыйль улы Вәлиев Түбән Кама каласында инде 18 ел рәттән шәһәр һәм район күләмендә мәктәп яшендәге балалар арасында иҗади бәйге үткәреп, тантаналы төстә үз премиясен тапшыра. Аның бу гамәле, беренчедән, язучының яхшы кеше булуын искәртсә, икенчедән, Разил абыйлары премиясенә ия булган укучыларның милләтебезнең зыялы улы кулыннан диплом, истәлекле бүләк, йә булмаса акчалата премия алулары күңелләрен киләчәктә иҗатка рухландыру, җаннарын җылыту булып тора.

Иҗади бәйгене оештыруны (быел 18 нче ел!) күркәм традициягә әверелдергән әдибебез үзенең бер чыгышында: «Бу дөньяда кешене ике төрле байлык яшәтә - матди һәм рухи байлыклар. Матди байлык турында без көн саен сөйлибез, анысы да мәгъкуль, ансыз тормыш бармый, әмма рухи байлык турында кайгыртмасак, матди байлык белән генә беркая да китеп булмый. Матди белән рухи байлык - һәр халыкның, һәр милләтнең, һәр кешенең ике канаты кебек ул. Әгәр дә без матди байлык турында гына уйласак, бер канат белән генә әллә ни ерак барып булмас иде. Бүген иң зур бурычларыбызның берсе - ошбу бәйгене оештыру мисалында икенче канатны ныгытып, яшьләребезне иманлы, итагатьле, тәрбияле итеп тәрбияләп, рухи кыйммәтләребезне киләчәк буыннарга илтеп тапшырырга тиешбез», - дип әйткән иде.

Шушы максат белән, бәйгегә 1998 нче елда нигез салына. Монда беренче елларда Ташлык, Шәңгәлче һәм шагыйрь укыган 1 нче мәктәп укучылары гына катнаша. Аларның аяклары җиңел була: бәйгенең колачы киңәя, ул шәһәр һәм район күләмендә үткәрелә башлый. Шушы дәвер эчендә Разил Исмәгыйль улы 1682 баланың күңеленә иҗат оеткысы сала. Бәйгегә укучылар тарафыннан шигырьләр, әкият, хикәя, парча һәм башка жанрда язылган әсәрләр тәкъдим ителә. Аларның иҗатында туган якка мәхәббәт тә, яшьлекнең сихри мизгелләре дә, башкаларга кычкырып әйтә алмаган самими йөрәк хисләре дә чагылыш таба. Шунысы куанычлы: бәйгедә төрле милләт балалары катнаша. Җиңүчеләр арасында журналист, тел белгече, иҗади һөнәрләр сайлаучы укучыларыбыз шактый.

Түбән Кама муниципаль районы мәктәпләрендә мәдәниятебезне, телебезне, сәнгатебезне үстерү, сәләтле балаларыбыз күңелендә булган иҗат чаткысын ялкын итеп дөрләтү максаты эзсез калмый: Разил Вәлиев бәйгесе бүгенге көндә Бөтенрәсәй күләмендә зурлап үткәрелә торган “Илһам” яшь язучылар бәйгесенә дә җан өрә. Әлеге бәйгене Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Казан (Идел буе) федераль университеты, Татарстан Республикасы Язучылар берлеге, Г. Тукай исемендәге Арча педагогика көллияте оештыра. Бу уку елында анда Казан, Яр Чаллы, Саба, Арча, Түбән Кама һәм Актаныш районнары активлык күрсәтте. Башкортостан Республикасы, Пенза, Киров һәм Әстерхан өлкәләре, Ханты-Манси автономияле округы, Пермь крае укучылары үз әсәрләрен тәкъдим итте. 2877 укучы арасыннан 300 ләп укучының эше бәйгенең йомгаклау турына сайлап алынды, шуларның 10 сы Түбән Кама шәһәре һәм районы мәктәпләреннән булуы бик сөенчле хәл.

Каләм тибрәтеп, иҗади бәйгедә катнашып уңышка ирешкән балалар алга таба Разил Вәлиев премиясенә лаек булулары белән горурланырлар, аның нәтиҗәсен тоярлар әле. Күренекле шагыйрь Разил Вәлиев үзе әйтмешли: «Һич кенә дә бәйгедә катнашкан һәрбер бала язучы, шагыйрь булыр дип уйламыйм, өметләнмим дә, әмма аларның әдәбиятка, сәнгатькә гашыйк булуы, аларның рухи дөньясының баюы киләчәктә аларны шәхес итеп тәрбияләү юлында бик зур адым дип саныйм». Әйе, безнең балаларыбыз халкыбызның акыллы фикерләрен, киләчәген, иманыбызның төзеклеген, күңелебезнең сафлыгын каләм тибрәтеп, иҗат ялкыны белән саклап калырга әзерләнәләр. Инде 18 ел элек, шушы «уйнап түгел, уйлап» башлаган игелекле эшен алып баручы күренекле әдибебезнең кылган изге гамәле һәр хәлле милләттәшебезгә өлге булырлык... Бик зур рәхмәт Сезгә, Разил Исмәгыйлович!



## МИН ТАТАРЧА СӨЙЛӘШӘМ!

***Фаттахова Илсия Илһам кызы,***
*13 нче гимназия – интернатның татар теле һәм әдәбияты укытучысы*




Һәркем өчен дөньядагы барлык телләр арасында иң кадерлесе - тәүге кабат сөйләшә башлаган ана теле. Бу - безнең балачагыбыз, гаиләбез, җәмгыятьтәге беренче тапкыр аралашуыбыз теле. Бүгенге көндә барлык телләр дә тигез дип таныла, чөнки аларның һәркайсы кеше язмышы өчен җавап бирә, һәркайсы табигый мирас булып тора һәм без аны, һичшиксез, сакларга тиешбез. Безнең туган телебез - татар теле. Халкыбыз үз телебезне саклаcа гына, үзенең яшәешен тәэмин итәчәк. Ә милләт үзенең теленнән башка ничек яши алсын соң? Шуңа күрә бүген республикада татар теленең кулланылыш даирәсен киңәйтү мәсьәләсе көн кадагында тора. Быел да, инде унберенче тапкыр, республикабызда “Мин татарча сөйләшәм” акциясе старт алды. Бу акция – татар телен популярлаштыра торган иң танылган чараларның берсе. Аның төп максатлары –татар теленә игътибарны җәлеп итү, телебезне шәһәр яшьләре арасында популярлаштыру, ягъни шәһәр мохитендә татар теленең кулланыш даирәсен киңәйтү, заманча татар башкаручыларын киң җәмәгатьчелеккә таныту, шәһәрдә яңа татар мәдәниятын формалаштыру эшендә ярдәм итү. Чыннан да, “Мин татарча сөйләшәм!” акциясе татар телен популярлаштыруның иң үзенчәлекле һәм халыкта зур кызыксыну уяткан чараларның берсе. Әлегә ул бердәнбер гражданлык инициативасы күрсәткече булып тора. Гомумән, хәзер татарларда, аеруча шәһәрдә туып үскән буында, шундый бер күренеш күзәтелә: алар үзләре татар булып та, урысча сөйләшәләр һәм үз туган телләрен үстерүне кирәк дип тә санамыйлар. Ә инде “Мин татарча сөйләшәм! “ул” менә бит, татарча сөйләшү оят түгел, әйдәгез, бергәләп аралашыйк” дип, татарларны үз телләрен онытмаска чакыра. Без дә, мәктәп укучылары, моннан читтә калмадык, бу акциягә бик актив кушылдык. Татарча сөйләшү бит ул әле көнкүрештә аралашу гына түгел, ул сөйләмеңне аңлаешлы, төгәл һәм аһәңле итеп оештыру, туган телеңнең тәмен, нечкәлекләрен белеп сөйләшү дә. Мәктәплярдәге укучыларның туган илгә, туган телгә булган ихтирамы, игътибары, мөнәсәбәте безне бик сөендерә. Бу акция кысаларында үткәрелгән чараларда укучыларыбыз гына түгел, мәктәп хезмәткәрләре дә кызыксынып катнашты. Пешекчеләребез “Татар халык ашлары” көнендә безне тәмле-тәмле ризыклар пешереп сыйлады. “Мин татарча укытам” дип исемләнгән чарада башка фән укытучылары татар телендә мастер-класслар күрсәтте. “Татар радиосы” көнендә башка милләттән

булган укучыларыбыз һәм хезмәттәшләребез дә татар телендә сәламнәр тапшырдылар, котлау сүзләрен җиткерделәр, җырлар җырладылар, татар теле турында үз фикерләрен белдерделәр**.** Әгәр дә без татарча сөйләшүне гамәлгә кертсәк, бу акциянең төп максаты тормышка ашар дип уйлыйбыз. Чөнки барыбыз да аңлыйбыз - бүгенге көндә әле татарча сөйләшүче буын бар икән, 50-100 елдан соң татар телендә сөйләшүче булыр микән? Шуңа күрә үзебез дә даими аралашып сөйләшмәсәк, телне саклый алмаячакбыз. “Мин татарча сөйләшәм!” акциясе - ул бер тамаша гына түгел, ул бөтен җирдә һәм һәркөнне татарча сөйләшү дигән сүз.

Тел - халык күңеленең кыңгыравы. Ә кыңгырау кагылмасаң чыңламый. Әйдәгез әле, әнә шул кыңгырауны ешрак чыңлатыйк, аның чыңы ерак-еракларга яңгырасын! Телебез киләчәктә дә яшәсен, үссен, чәчәк атсын!

## “КӨЙЛЕ, МОҢЛЫ ТАТАР ҖЫРЫ” БӘЙГЕСЕ



50 еллык юбилеена якынлашучы Түбән Каманың үз татар җыры «фестивале» бар. Ул - мәктәп укучыларыннан торган хор һәм ансамбль коллективларының «Көйле, моңлы татар җыры» бәйгесе. Бәйгенең төп масаты – укучылардан сәхнә йолдызлары ясау түгел, ә җыр аша туган телгә, (башка милләт балалары өчен татар теленә) мәхәббәт тәрбияләү, сәнгать аша телне саклау һәм рухи байлыкны яшь буынга җиткерү.





Уку елы башында старт алып, 4 этапта узган бәйгегенең финал өлешенә бары тик иң яхшы коллективлар гына барып җитә ала. Ә гала-концертта иң-иңнәргә тамашачы алкышлары белән бергә акчалата премияләр дә тапшырыла. Чөнки монда барысы да бик җитди. Ел саен финанс мәсьәләләрен Бөтендөнья татар конгрессының Түбән Кама бүлеге үз өстенә ала. Бәйге - мәктәпләрне милли киемнәр белән тәэмин итү мөмкинлеге биргән бердәнбер чара.

Әлеге бәйгегенең тарихына күз салсак, ул 2008 нче елга барып тоташа. Бөтендөнья татар конгрессының Түбән Кама муниципаль районы бүлеге рәисе, шәһәр советы депутаты, “Шинник” спорт комплексы директоры Ганиев Рөстәм Мәҗит улы, Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең урынбасары, мәгариф идарәсе башлыгы Равис Мөҗәһит улы Шакиров, мәгълүмати методик үзәк методисты Шәфыйкова Мәхтүмә Сәлахетдин кызы инициативасы белән кыюсыз гына беренче адымнарын ясаган бәйгенең гомере озын булды. Ул быел сигезенче мәртәбә үткәрелә.

Соңгы 5 елда үткәрелгән бәйге нәтиҗәләре:

| урыннар | 2011-2012 | 2012-2013 | 2013-2014 | 2014-2015 | 2015-2016 |
|---|---|---|---|---|---|
| I | 12, **16**, гим. №2 | **16**, **35**, 8, 10 | **14,** Кама Аланы – 2, **35** | 21, 32, 26 | 7, **35**, **14**, 29 |
| II | 10, 31, 16 | 17, 12, 31, гим. №1, 32,18 | 32, 26, 10, 15, 18 | Шәңгәлче, 14 | 32, 19, 21, 35, гим.№2 |
| III | 14, 25, 18, 33, 35 | 9, 29, 26, 3, 15, 25, 5 | 27, гим. №1, 6, 7, 1, гим.№2 | 22, 32 | 21, гим №1, 18, Каенлы |

Шәһәребездә мондый чаралар булганда, милли традицияләребез, буыннан-буынга күчеп килүче җыр-моңнарыбыз киләчәк буыннарга җиткерелер дип ышанып калабыз.

# ОБРАЗОВАНИЕ
## НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

**УЧРЕДИТЕЛЬ**
Управление образования Исполнительного комитета
Нижнекамского муниципального района

**ПРЕДСЕДАТЕЛЬ РЕДАКЦИОННОГО СОВЕТА**
Матюшин В.Н.- начальник управления образования Исполкома НМР РТ

**ГЛАВНЫЙ РЕДАКТОР**
Офицерова А.М. - заместитель начальника управления образования НМР РТ

**РЕДАКЦИОННЫЙ СОВЕТ**
Сабирова Г.М. - методист управления образования НМР РТ
Исмагилова Р.Р. - методист управления образования НМР РТ
Кирпичонок М.А. - директор МАОУ «Межшкольный учебный комбинат» НМР РТ
Минабутдинова Г.С. - методист МАОУ «Межшкольный учебный комбинат» НМР РТ
Гимашева А.Х. - методист МАОУ «Межшкольный учебный комбинат» НМР РТ

**МАКЕТ, ДИЗАЙН И ВЁРСТКА**
Бормотов Д.Н. - дизайнер МАОУ «Межшкольный учебный комбинат»
Телефон: 30-85-66
E-mail: muk-nk@yandex.ru.

**КОРРЕКТОРЫ**
Гараева Г.Ш. - заместитель директора по национальному образованию МБОУ «Камскополянская СОШ №1» НМР РТ
Мубаракшина Р.Р. - учитель татарского языка и литературы МБОУ «Гимназия №32» НМР РТ
Хафизова И.М. - учитель татарского языка и литературы МБОУ «Гимназия №32» НМР РТ
Шамсиева З.М. - учитель татарского языка и литературы МБОУ «Гимназия №32» НМР РТ
Шайхетдинова Х.Х. - учитель татарского языка и литературы МБОУ «Гимназия №32» НМР РТ

**АДРЕС РЕДАКЦИИ**
423570, Республика Татарстан,
Нижнекамск, ул. Бызова 9а
Телефон: 30-85-66
Электронная почта: muk.nk@tatar.ru; muk-nk@yandex.ru